# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2025 4 (48)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан нәшер ителә.***
***Елына кәгазь һәм электрон форматта 4 сан чыгарыла.***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ МӨХӘРРИР**

Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

НАДЫРШИНА Л.Р., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы сәркатип)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ДӘҮЛӘТШИНА Л.Х. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

АБДУЛЛИНА Н.Т., ЧУГУНОВ А.С.

Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., К. Маркс ур, 12.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Тел.: (843) 590-61-11
E-mail: f_tatarstan@mail.ru
Сайт: https://ft.antat.ru/

## БУ САНДА


### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә фигыль сүзтезмәләр *(Мөслиминең «Тәварихе Болгария» әсәре мисалында)* . . . . . . . 7

*Галимова О.Н.* К. Насыйриның «“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлек» хезмәте терминографик аспектта . . . . . . . . 15

*Лутфуллина Г.Ф.* Татар теле вәкилләренең тел аңы үзәге лексик берәмлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

*Сәфәров Р.Т.* Аңлатмалы сүзлекнең микроструктурасын параметризацияләү принциплары . . . . . . . . . . . . . . . . 34

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Ганиева А.Ф.* Татар совет прозасы: төп үсеш этаплары һәм тенденцияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

*Надыршина Л.Р.* Г. Бәшировның әдәби-публицистик эшчәнлегенең төп принципларын ачуда аның шәхси фондының әһәмияте . . . . . . . . . . . . . . . . 55

### ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛЛЫКНЫ КАРШЫЛАП

*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Әмирхан публицистикасы: кыйблалар алмашынган чакларда (1913–1925). . . . . . . . . . . 62

*Галимҗанова Э.М.* Фатих Әмирхан көндәлекләре ни сөйли? . . 80

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Миңнуллин К.М.* Халык иҗатында Хуҗа Насретдин образы *(Хуҗа Насретдин мәзәкләренең Казанда басылуына 180 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Юсупов А.Ф.* Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте: татар халкының рухи мәдәниятен һәм этник төркемнәрен өйрәнү эшчәнлеге. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

*Әхмәтов Д.И., Мөхәммәдиева Л.Г.* Керәшен вакытлы мәгълүмат чаралары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ 80 ЕЛ

*Макарова В.Ф.* Хәзерге татар прозасында Бөек Ватан сугышын күзаллау *(Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..» романы мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

## МИЛЛИ МӘГАРИФ


*Мөхәрләмова Г.Н.* Мәктәптә туган (татар) телдәге әдәбиятны укыту барышында укучыларның эмоциональ интеллектын үстерү юллары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

*Һадиева Г.В.* «Татар язучылары һәм шагыйрьләре саннарда» инфографикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

*Сәлахов А.М.* XIX – XX гасыр башында татар мәдрәсәләрендә кулланылган гарәп телен өйрәнү буенча уку әсбаплары . . . . . 129

*Гайнуллина Г.Р., Мәннанова Р.Р.* Гобәйдулла Нигъмәтуллин Фәйзи-Бубиның мәктәп-мәдрәсәләр өчен төзегән дәреслекләренә күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135


## СӘНГАТЬ


*Улемнова О.Л.* Рәссам Р.Г. Заһидуллин иҗатында татар халкы тарихы һәм мәдәнияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

*Гулиев Р.А.* Борынгы Азәрбайҗан скульптурасында хатын-кыз символизмы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150


## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ


*Насипов И.С.* Алмас Галимҗан улы Шәйхулов – чагыштырма-тарихи тел белеменең күренекле вәкиле *(галимнең тууына 80 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . 156

*Мортазина Л.Р.* Педагог һәм шәркыятчы галим Әбүбәкер Диваев . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

*Хәсәнова А.Н.* Сәлах Камалның тормышы һәм эшчәнлеге *(тууына 140 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172


## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР


*Вахитов Н.Р.* «Төрек дәрнәге» (1911–1912) мәҗмугасында татар әдипләренең мәкаләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178


## ЯҢА КИТАПЛАР


*Сафина Э.И.* Яңа «Русча-татарча сүзлек»кә бәяләмә (авторы Ф.Ф. Гаффарова; Казан, 2025. 655 б.) . . . . . . . . . . . 185


## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Валиева М.З.* Глагольные словосочетания в старотатарских письменных памятниках XVII–XVIII вв. *(на примере «Таварихе Булгария» Муслими)* . . . . . . . . . . . . 7

*Галимова О.Н.* «Словарь к книге “Цветы и травы”» Каюма Насыри в терминографическом аспекте . . . . . . . . . . 15

*Лутфуллина Г.Ф.* Лексические единицы ядра языкового сознания носителей татарского языка. . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

*Сафаров Р.Т.* Принципы параметризации микроструктуры толкового словаря. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34


## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Ганиева А.Ф.* Татарская советская проза: основные этапы развития и тенденции . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

*Надыршина Л.Р.* Личный фонд Г. Баширов как источник изучения его литературно-критических принципов . . . . . . . . 55


## К 140-ЛЕТИЮ ФАТИХА АМИРХАНА


*Загидуллина Д.Ф.* Публицистическая деятельность Фатиха Амирхана (1913–1925) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62

*Галимзянова Э.М.* О чем повествуют дневники Фатиха Амирхана? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80


## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Миннуллин К.М.* Образ Ходжи Насреддина в народном творчестве *(к 180-летию первого издания мэзэков Ходжи Насреддина в Казани)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85


## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Юсупов А.Ф.* Общество археологии, истории и этнографии: изучение духовной культуры татарского народа и этнических групп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

*Ахметов Д.И., Мухамадиева Л.Г.* Средства массовой информации кряшен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103


## 80 ЛЕТ ВЕЛИКОЙ ПОБЕДЕ


*Макарова В.Ф.* Великая Отечественная война в современной татарской прозе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Мухарлямова Г.Н.* Особенности развития эмоционального интеллекта у обучающихся на уроках родной (татарской) литературы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

*Хадиева Г.В.* Инфографика «Татарские писатели и поэты в цифрах» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

*Салахов А.М.* Учебные пособия по арабскому языку в медресе XIX – начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129

*Гайнуллина Г.Р., Маннанова Р.Р.* Обзор учебников, составленных Губайдуллой Нигматуллиным Файзи-Буби для школ-медресе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135

## ИСКУССТВО

*Улемнова О.Л.* История и культура татарского народа в живописи Р.Г. Загидуллина. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

*Гулиев Р.А.* Символизм женщины в древней скульптуре Азербайджана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

## ПЕРСОНАЛИИ

*Насипов И.С.* Алмас Галимзянович Шайхулов – видный представитель сравнительно-исторического языкознания *(к 80-летию со дня рождения ученого)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

*Муртазина Л.Р.* Педагог и ученый-востоковед Абубакир Диваев . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

*Хасанова А.Н.* Жизнь и творческая деятельность Салаха Камала *(к 140-летию со дня рождения)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Вахитов Н.Р.* Статьи татарских писателей в издании «Төрек дәрнәге» (1911–1912) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178

## НОВЫЕ КНИГИ

*Сафина Э.И.* Рецензия на «Русско-татарский словарь» Ф.Ф. Гаффаровой (Казань, 2025. 655 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . 185

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

*М.З. Вәлиева*

# XVII–XVIII ГАСЫРЛАР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР (Мөсīиминең «Тәварихе Болгария» әсәре мисалында)

Статья посвящена изучению синтаксических языковых единиц – глагольно-именных словосочетаний старотатарского литературного языка XVII–XVIII вв., выявленных в тексте «Таварихе Булгария» Муслими. Актуальность работы обосновывается тем, что в лингвистике до сих пор недостаточно изучены данные синтаксические категории в их историческом развитии. Они, как и другие языковые единицы, играют важную роль в формировании синтаксического строя татарского языка. На основе богатого фактического материала предоставлена общая характеристика этой группы словосочетаний, выявлены и описаны их модели, определены способы и средства связи. Именно-глагольные словосочетания, собранные из старотатарского письменного источника, разделены на две большие группы: словосочетания, выражающие прямое объектное отношение, и словосочетания, выражающие косвенное объектное отношение. Отмечено, что в обоих типах преобладают падежные аффиксы в качестве грамматических средств связи сочетающихся слов. Примечательно, что в синтаксических категориях, выражающих косвенные объектные отношения, союзы также широко используются.

**Ключевые слова:** татарский литературный язык, старотатарский письменный источник, синтаксис, глагольные словосочетания.

The article is devoted to the study of syntactic linguistic units – verb-nominal phrases of the Old Tatar literary language of the 17th – 18th centuries, revealed in the text of “Tavarikhe Bulgariya” by Muslimi. The relevance of the work is substantiated by the fact that these syntactic categories in their historical development have not been sufficiently studied in linguistics. They, like other linguistic units, play an important role in the formation of the syntactic structure of the Tatar language. Based on rich factual material, a general description of this group of phrases is provided, their models are identified and described, and the methods and means of communication are determined. The verb-nominal phrases collected from the Old Tatar written source are divided into two large groups: phrases expressing a direct object relationship and phrases expressing an indirect object relationship. It is noted that in both types, case affixes prevail as grammatical means of communication between combined words. It is noteworthy that in syntactic categories expressing indirect object relationships, conjunctions are also widely used.

**Keywords:** Tatar literary language, old Tatar written source, syntax, verb phrases.

Татар теле – үсеш тарихы борынгы чорларга барып тоташа торган борынгы төрки телләрнең берсе. Телебезнең үсеш тарихын тикшерү, язма традицияләрне барлау, телнең төрле юнәлешләренә

(лексика, морфология, синтаксис һ. б.) хас үзенчәлекләрне өйрәнү һәм системага салып бирү – хәзерге тел белемендә тирәнтен өйрәнүне таләп итә торган өлкәләрнең берсе, һәм ул язма чыганакларга таянып алып барыла. Бүгенге көндә татар теленең тарихи синтаксисын, сүзтезмә, җөмлә, текст төзелешен һ. б. өйрәнү татар тел белемендә актуаль проблемалардан санала. Аеруча язма истәлекләрдә кулланылган сүзтезмәләрне тикшерү, аларның төрләрен барлау, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау, төркемләү принципларын анализлау өйрәнелмәгән тармак булып тора. Шуларны күздә тотып, әлеге мәкаләдә XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә объект семантикасына ия фигыль сүзтезмәләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен анализлауны максат итеп куябыз. Фактик материал татар халкы тарихын яктырту, телебезгә хас грамматик үзенчәлекләрне чагылдыру җәһәтеннән мөһим чыганакларның берсе – Мөслими Хисаметдин бине Шәрәфетдиннең «Тәварихе Болгария» әсәре нигезендә тупланды. Татар халкы арасында киң таралган әлеге җыентык шунда тасвирланган тарихи вакыйгаларның бик дөрес булмавына, туры килмәвенә карамастан [3: 444–466; 16: 134–166], шул чордагы укымышлы татарлар тарафыннан яратып укылган. Әдәбиятчы галимнәр «Тәварихе Болгария»нең «тарихи әсәр булудан бигрәк, гомумән төньяк-көнчыгыш Европаның физик географиясе һәм мәгълүм дәвердәге төрле тарихи вакыйгалар һәм шәхесләр турында язылган әсәр» буларак әһәмиятле икәнлеген ассызыклыйлар [18: 449]. Үз чорында ул халык өчен белем-мәгълүмат, эстетик тәрбия чыганагы булып торган. Мәгълүм булганча, әлеге язма истәлекнең язылу датасы хакында галимнәр арасында фикер төрлелеге яшәп килә. Күренекле әдәбиятчы галим М. Гайнетдинов үзенең хезмәтләрендә әлеге чыганакның язылу вакытын 1584 ел дип күрсәтә [4: 151]. М. Әхмәтҗанов исә, «Тәварихе Болгария» әсәрендә татар халкының XVIII–XIX гасырлардагы сәяси хәле тасвирлана дип, аның XVIII гасыр ахырыннан да иртә язылмавы турында искәртә [1: 413]. Әлеге әсәрнең татар халкы тарихы, теле үсеше өчен зур әһәмияткә ия икәнлеген, Мөслиминең талант иясе булуын ассызыклап, И.Б. Бәширова болай дип яза: «...белеме төрле дәрәҗәдәге халыкның һәр барчасына да аңлаешлы итеп хикәяли-бәян итә алган, төрле чорда сокланып укырлык әсәр яза алган, үзеннән соң иҗат ителәчәк хезмәтләргә юл ачкан» [2: 50]. Шуңа да әлеге язма истәлекнең тел байлыгын, шул исәптән синтаксик үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган сүзтезмәләрне тикшерү фәнни әһәмияткә ия.

Сүзтезмәләрне төркемләү принциплары гомум тел белемендә дә шактый төрле. Татар тел белемендә кимендә ике яки берничә мөстәкыйль мәгънәле сүзнең төгәлләүле мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә ясалган һәм төгәлрәк төшенчәне белдерә торган төзелмәне сүзтезмә дип атау кабул ителгән [15: 57]. Сүзтезмәләргә хас төп үзенчәлекләрнең берсе итеп аның ике-өч компонентлы, ягъни валентлык сыйфатына ия булуы күрсәтелә. Компонент булып, ни-

гездә, сүз, яисә сүзформа тора. Сүзтезмәнең валентлыкка ия булуы, структур-синтаксик яктан караганда, аның бердәнбер һәм аңа гына хас үзенчәлеге булып тора. Валентлык төшенчәсе тел белеменә узган гасыр ахырларында ныклап кулланылышка керә. А.Ф. Лосев үзенең хезмәтендә бу хакта: «Принцип валентности языкового знака – это чрезвычайно важный принцип, безусловно относящийся к самой специфике языка, понимаемого строго динамически», – дип яза [10: 133]. Шуны да ассызыкларга кирәк: бер үк фигыль төрле тарихи чорларда төрле грамматик чаралар белән бәйләнешкә кереп, төрле мәгънә мөнәсәбәтләре белдереп килергә мөмкин. Моның сәбәпләрен галимнәр төрлечә аңлаталар. Аерым алып әйткәндә, түбәндәге сәбәпләрне күрсәтүчеләр дә бар: борынгы төрки телдә бер килеш формасының актив, икенчесенең пассив булуы, киң кулланылышта йөргән килеш формаларының ул чорда сирәк очравы яисә бөтенләй күзәтелмәве, бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең азлыгы, сүзтезмә компонентлары арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренең киңлеге һәм барлык мөнәсәбәтләрнең дә формалашып җитмәве һ. б. [8: 92–101].

Хәзерге татар тел белемендә, иярүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, сүзтезмәләр җиде зур төркемгә бүлеп карала: фигыль сүзтезмәләр, исем сүзтезмәләр, сыйфат сүзтезмәләр, хәбәрлек сүзле сүзтезмәләр. Һәрбер сүзтезмә үз эчендә, иярүче сүзнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, тагын берничә төркемгә бүленә. Мәсәлән, исемле исем сүзтезмә, исемле фигыль сүзтезмә һ. б. [15: 60]. Шулар арасыннан фигыль сүзтезмәләр күләм ягыннан да, семантик яктан да күп һәм төрле булулары белән аерылып тора. Белгәнебезчә, иярүче кисәк булып, исем генә түгел, исем функциясендәге алмашлыклар, саннар, сыйфатлар, сыйфат фигыльләр һәм исем фигыльләр килгән очракларны да исемле фигыль сүзтезмәләргә кертеп карыйлар [15: 61]. Без исә әлеге мәкаләдә иярүче сүз белән ияртүче сүз арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен алгы планга куеп, исемле фигыль сүзтезмәләрне, аларның объект семантикасына ия булганнарын анализлап, ике төргә бүлеп бирергә булдык.

**I. Иярүче сүзе процессның туры объектын, ягъни процесс турыдан-туры кагыла торган предметны, затны, төшенчәне белдерүгә корылган сүзтезмәләр.**

Мөслиминең «Тәварихе Болгария» китабында әлеге мәгънә мөнәсәбәтен белдерү өчен берничә чара кулланылган. Иң беренче чиратта, килеш кушымчаларының актив булуы күренә. Барыннан да бигрәк төшем килешенең еш очравын ассызыкларга кирәк.

1. Ияртүче кисәккә төшем килеше кушымчалары ярдәмендә бәйләнгән исемле фигыль сүзтезмәләр. Мәгълүм булганча, төшем килеше инде борынгы әдәбиятта ук чагылыш таба. Мәсәлән, Л. Җәләй үзенең хезмәтләрендә бу турыда: «Орхон-Янәсәй язмаларында ук нуль форма, тартымлы төшем формасы һәм алмашлыкларда хәзерге *-ны, -ни* кушымчалары да очрый», – дип яза [7: 24]. Күлтәгин текстындагы грамматик чаралар хакында сүз алып барганда, шушы

тармакның төп белгечләреннән берсе С.Е. Малов болай дип ассызыклап үтә: «Борынгы төрки телләрнең иң зур үзенчәлеге булып төшем килешенең *-г, -ғ* (сузыклардан соң) һәм *-ыг, -иғ* (тартыклардан соң) формалары тора» [11: 44]. Гомумән, төшем килеше кушымчасының килеп чыгышы турында фәндә фикер төрлелеге яшәп килә. Мәсәлән, Н.К. Дмитриев тартымлы төшемнең *-ын/ -ен* кушымчасын монгол телендәге *in* дигән күрсәтү һәм зат алмашлыгы белән бәйли. Алтай телләре монгол һәм төрки тармакларга аерылмаган чорда әлеге алмашлык уртак булып йөргән. Ә соңрак инде төрки телләрдә мөстәкыйль сүз буларак кулланылмый башлаган, бары тик кушымча рәвешендә генә сакланып калган булырга мөмкин, дигән фикерне уздыра [6: 65]. Күренекле тюрколог А.Н. Кононов суффиксларның килеп чыгышын фузия күренешенә, ягъни бер яки ике фонемалы морфемаларның бер-берсе белән кушылуына бәйле рәвештә аңлатырга тырыша: «Однако утвердившееся с прочностью предрассудка широко распространенное мнение, что все агглютинативные форманты восходят к самостоятельным словам, есть заблуждение, направившее тюркологов по ложному пути» [9: 82]. Татар тел галимнәреннән Г.Р. Сәмирханова да шул ук фикерне яклый: «Без кайбер суффиксларның килеп чыгуын алар составындагы авазларның билгеле бер мәгънә белдерүе белән дә бәйле булырга мөмкин, дип саныйбыз» [14: 80]. Шуңа бәйле рәвештә килеш кушымчаларының, шул исәптән төшем килешенең дә, килеп чыгышы турында бердәм фикерләр юк. Әмма язма истәлекләрдән күренгәнчә, бу килеш кушымчалары борынгы әдәбиятта ук чагылыш таба. XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә дә фигыль сүзтезмәләр барлыкка китерүдә катнаша торган иң актив грамматик чараларның берсе булып тора. Фактик материалдан күренгәнчә, бу чор язма чыганакларда төшем килеше кыпчак тибы төрләнеше *ны/-не* кушымчалары, III зат берлек сандагы тартымлы исемнәргә ялгана торган кыпчак төрләнешендәге *-ын/-ен, -н* кушымчалары һәм угыз төрләнешендәге *-ыны/-ене* кушымчалары ярдәмендә җиткерелә.

а) *-ны/-не* кушымчасы ярдәмендә ясалган исемле фигыль сүзтезмәләр. Бу төр сүзтезмәләрдә объект буларак күпчелек очракта кеше, зат һәм башка җан ияләрен белдерүче лексик берәмлекләр урын ала. Мәсәлән: *Вә Кабил **Һабилне үлтерде*** [12: 9]. *Вә **чәмәнләрне күрделәр** илә, күрделәр ирсә бәс айның адыны «Рабигыль-әүвәл» куйдылар* [12: 11]. *Хәзрәте Мир Тимер еглады, **галимне үлтерде** икән див, хәсрәттә улды* [12: 40]. Икенче бер төркем исемле фигыль сүзтезмәләрдә объект ролендә *күрергә, күзәтергә, җиңәргә, язарга* һ. б. мөмкин булган сүз-төшенчәләр килә: *Шул **Болгарны хәраб әйләде**, халыкны әтрафе галәмә таратды* [12: 45]. *Бер елгача бунларый зыяфәт итеп, бәхре Мохитнең **атауларыны вә шәһәрләрене күргезделәр**: ничә атаулар вә ничә карьялар вә ничә шәһәрләр вардыр мисрый гаскәренә күргезеп кайтардылар* [12: 21]. *<...> бу **вакыйгаларны языб**, үгет вә нәсыйхәт биреб, тәүбәйә боердьы* [12: 42];

ә) *-ын/-ен/-н* кушымчасы ярдәмендә ясалган фигыль сүзтезмәләр. Бу форма, кагыйдә буларак, текстка III зат берлек сандагы тартымлы исемнәрне эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләргә бәйләгәндә килеп керә. Фәндә әлеге кушымчаларның килеп чыгышына бәйле дә фикер төрлелеге яшәп килә. Мәсәлән, В. Хангилдин *-н* кушымчасы хакында болай дип яза: «...*-н* төбендә үк *-ны/-не* кушымчасының кыскартылмасы гына...» [17: 87]. Димәк, тартымлы исемнәргә ялгана торган *-н* кушымчасы – тарихи яктан соңрак барлыкка килгән күренеш. Бу чара XVII–XVIII гасырларның иске татар язма истәлекләрендә еш күзәтелә. Мәсәлән: ***Башын кисеб алдылар*** *вә Димәшкъка илтделәр* [12: 11].

«Тәварихе Болгария» әсәрендә тартымлы төрләнештә төшем килешенең тулы варианты – *-ыны/-ене* кушымчасының киң кулланылуын искәртергә кирәк. Мәсәлән: *Ул егачның* ***түбәсене уйсалар,*** *су чыгар* <...> [12: 22]. *Мәккәдә Әбу Кобәес тагына бенеб куй* ***башыны йисәләр,*** *ул кемсәгә һәргиз җиһанда эт өрмәйә, дешләмәйә* [12: 24]. <...> *ул Харҗәм* ***гаскәрене тар-мар әйләдиләр****, бәгъзиләрене үлдереб, калдыкларыны кол идеб* [12: 24]. <...> *йа фәлән, сән бәнем тәхетемнең аякларыны кисмәгел, зира ки аталарымыздан калган мирасдыр, зиннәте китмәсен, диде* [12: 16]. *Солтан Мәһди Мир Тимернең илчеләренең* ***колакларыны кисеб йибәрде*** [12: 42].

2. Ияртүче кисәккә янәшә тору чарасы аша бәйләнгән исемле фигыль сүзтезмәләр. Бу форма, нигездә, укучы, тыңлаучы өчен алдан таныш булмаган билгесез объект хакында сүз барган яисә шул объектлар турында гомумиләштереп мәгълүмат биргән сүзтезмәләрдә урын ала. Мәсәлән: *Аллаһы Тәгалә ул диңгездә ак* ***кошлар яратмыш*** [12: 21]. *Хан илчеләр артындин* ***язу йибәрде****, син караксың, сиңа нә өчен кальгаларымызны ачалык* (12: 42). *Ул тагның башына бер олуг* ***сарай дөзделәр*** [12: 47]. *Халянки дөшем имеш, вә дәхи анам әйтде, өч көндин соң миңа өләшерсең диде, бер локмә* ***нигъмәт бирде*** [12: 40]. *Мисыр шаһы Хуҗа Бәйрәм бер* ***көймә төзетте*** [12: 21]. <...> *башлыклары килеб, болардан күб* ***мал алды*** [12: 42] һ. б.

3. Ияртүче кисәккә чыгыш килеше кушымчалары ярдәмендә бәйләнгән исемле фигыль сүзтезмәләр. «Тәварихе Болгария» әсәрендә чыгыш килешенең борынгы варианты – *-дин* кушымчасы кулланылуын әйтергә кирәк. Бу кушымчаның объект мөнәсәбәтен белдереп килүен галимнәр аның төшем килеше ролендә кулланылуына бәйләп карыйлар һәм бу үзенчәлекнең бүгенге көндә урта диалектның карин-глазов сөйләшенә хас булуын да искәртәләр [13: 162]. Чыннан да, XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә дә ул нәкъ менә объект мәгънәсен бирүдә катнаша. Мәсәлән: *Шул урысның абзарындан кара байталны алыб, ике арт* ***ботындин тотды****, чиркәүнең манарасы егылды* (12: 45).

4. Ияртүче кисәккә *-га/-гә* кушымчалары ярдәмендә бәйләнгән исемле фигыль сүзтезмәләр. Бүгенге көндә юнәлеш килеше кушымчасы буларак мәгълүм *-ка/-кә* кушымчасы шулай ук төшем килешендә

килә торган объект мәгънәсен белдерә. Дөрес, без бу чара ярдәмендә оешкан сүзтезмәләрне бик сирәк очратабыз. Шулай булуга карамастан, XVII–XVIII гасырларда иске татар язма әдәбиятында анык кулланылышта йөрүен искәртми мөмкин түгел. Мәсәлән: *Падишаһ хәзрәте бик сабыр әһлендән ирде,* ***каравылчыларга чагырмаеб****, акрын әдәб берлә, йа фәлән, сән бәнем тәхетемнең аякларыны кисмәгел, зира ки аталарымыздан калган мирасдыр, зиннәте китмәсен, диде* [12: 16].

**II. Иярүче сүзе процессның кыек объектын, ягъни процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны, төшенчәне аңлата торган сүзтезмәләр.**

Биредә түбәндәге бәйләүче чаралар катнаша:

а) ияртүче кисәккә юнәлеш килеш кушымчалары *-га/-гә, -ка/-кә* һәм тартымлы *-на/-нә* ярдәмендә бәйләнгән исемле фигыль сүзтезмәләр. Мәсәлән: *Аксак Тимер хәзрәтләре* ***Солтан Мәһдигә җибәрде*** *<...>* [12: 42]. *Бу Вәзна аенда* ***дийаре мәгърибә варают****, андагы падишаһлар бәңа бәйгать бирсенләр, хараҗә разый улсынлар, яки үзем кеби* ***көнешкә гыйбадәт итсенләр,*** *ягъни бәнем динемдә улсынлар, див* [12: 15]. *<...> ул көн әмбияләрдән* ***алты кешейә тәшам улынды*** [12: 8]. Түбәндәге сүзтезмәләрдә бәйләүче чара булып тартымлы исемнәргә ялгана торган *-на/-нә* кушымчалары килә: *Бер елгача бунларый зыяфәт итеп, бәхре Мохитнең атауларыны вә шәһәрләрене күргезделәр: ничә атаулар вә ничә карьяләр вә ничә шәһәрләр вардыр мисрый* ***гаскәренә күргезеп кайтардылар*** [12: 21]. *Гали Кошчыны Дауд әфәнденең күршесе Нияз Хуҗаның* ***углына сатды*** [12: 40]. *Бәс каравылчылар* ***башлыкларына барыб әйтделәр*** *<...>* [12: 42];

ә) ияртүче кисәккә чыгыш килеш кушымчалары ярдәмендә бәйләнгән исемле фигыль сүзтезмәләр. Бу төр сүзтезмәләрдә бәйләүче чара буларак *-дан/-дән* кушымчалары урын ала. Кагыйдә буларак, бу очракта зат, кеше яисә халыкны атап лексик берәмлекләр дә, абстракт мәгънәле сүзләр дә килергә мөмкин. Мәсәлән, түбәндәге мисалларда объект ролен затны, халыкны атаучы сүзләр үти: *<...> зира ки* ***аталарымыздан калган*** *мирасдыр, зиннәте китмәсен, диде* [12: 16]. *Мин* ***өммәтләремдән разыймын****, диде* [12: 40]. Алдагы мисалларда объект буларак абстракт сүзләр килгән: *Барчалары ултырдылар вә әйтде, йа падишаһ, ул Мәләкел-Мәүтнең бармак күрсәтмәгәе синең гомереңкүблегендән вә азгылындан хәбәр бирмәк дүгелдер...* [12: 17]. *Шаһ* ***йокысындан уйганды,*** *күрде ки, бер дивана йөрер, кулында бер кечәрәк балтасы вардыр* [12: 16];

б) ияртүче кисәккә килеш кушымчасы һәм бәйлекләр ярдәмендә ияргән исемле фигыль сүзтезмәләр. Бу очракта чыгыш килеш кушымчасы + *гайре* сүзе ярдәмендә ясалган сүзтезмәләрнең киң кулланылуын искәртергә кирәк. *Гайре* сүзе галимнәр тарафыннан гарәп телендәге инкяр итү кисәкчәсе буларак каралса да [5: 415–416], «Тәварихе Болгария» әсәрендә ул «шуннан башка», «шуннан тыш» мәгънәсен бирә торган бәйлек буларак килгән: *Бәлки будыр, биш нәрсәне*

***Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәс*** *димәкдер* [12: 17]. *Икенче бармагы ишарәтдер, ягмур ягмагыны каю айда вә каю көндә, вә каю сәгатьдә ягмагыны* ***Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләрдер*** [12: 17]. *Ул көймә берлә бер ел киттеләр,* ***диңгездән гайрене күрмәделәр*** [12: 21].

Сүзтезмәләр барлыкка китерүдә актив катнаша торган бәйлекләр арасында *илә, илән, берлә* бәйлекләре аерым урын алып тора: *Әрмәнленең Ник дидеге кальгасында* ***гаскәре илә кундылар*** [12: 12]. *Чунки Хәбәш шаһы сиңа җәнг илә килде дийарыңны хәраб әйләмәгә диделәр, Исмәгыйль галәйһиссәлам* ***аның илә җәнг идәргә Мәккә җәмәгате илән чыгды***... [12: 14]. *Әз ин җаниб, чунки Гали хәзрәтләре ул алты* ***егет берлә текәрләр ирде*** [12: 40]. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, биредә объект буларак зат, кеше мәгънәсендәге лексик берәмлекләр килсә, түбәндәге очракта җансыз предметларны яки абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр өстенлек ала: *Голәмалары әйделәр,* ***китаблар илә җаваб бирермез****, диделәр* [12: 43]. *Вә иген нигъмәтене Аллаһы Тәгалә* ***ягмур суы илән сугарыр*** [12: 19]. *Шул* ***фикер илә ятды****, хабә китде* [12: 15]. *Сәгадәт вә шәкавәт һәр икесе* ***заман илә кәсеб улыныр*** [12: 8].

Шул рәвешчә, Мөслиминең «Тәварихе Болгария» әсәрендә теркәлгән исемле фигыль сүзтезмәләрнең объект мөнәсәбәтен белдерә торган төре ике зур төркемгә бүлеп каралды: иярүче сүзе процессның туры объектын белдерә һәм иярүче сүзе процессның кыек объектын аңлата торган төрләр. Беренче төрдә бәйләүче чара буларак төшем килешенең актив булуы ачыкланды. Мәсәлән, *галимне үлтерде, чәмәнләрне күрде* кебек сүзтезмәләр әлеге чараның хәзерге әдәби телдә дә норма буларак кулланылуы хакында сөйли. «Тәварихе Болгария» әсәрендә тартымлы төрләнештә төшем килешенең тулы варианты – ***-ыны****/-ене* кушымчасының киң файдаланылуы (*аякларыны кисмәгел, гаскәрене тар-мар әйләдиләр* һ. б.), төшем килеше мәгънәсендә чыгыш килеше кушымчасы *-дин,* юнәлеш килеше кушымчасы *-га*/*-гә* урын алуы (*ботындин тотыб атды*) шушы чорга, әлеге язма истәлекнең теленә хас, әмма сирәк очрый торган үзенчәлекләр булып тора. Ияручe сүз процессның кыек объектын белдерә торган сүзтезмәләрдә бәйләүче чаралар булып юнәлеш, чыгыш килеше кушымчаларының (*Мәһдигә йибәрде, аталарымыздан калган* һ. б.), *гайре, илә, илән, берлән* кебек ярдәмче сүзләрнең (*гаскәре илә кундылар, җәмәгате илән чыкдылар* һ. б.) өстенлек алуы ачыкланды.

## Әдәбият


1. *Әхмәтҗанов М.И.* Кереш // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Матбугат йорты, 2006. Б. 3–12.

2. *Бәширова И.Б.* Иске татар язма әдәби теле // Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘһСИ, 2015. Б. 21–206.

3. Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963, 580 б.

4. *Гайнетдинов М.В.* Литература XVIII века // Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. Казань: Фэн, 1999. С. 181–199.

5. *Гранде Б.М.* Курс арабской грамматики в сравнительно-историческом освещении. М.: Изд-во вост. лит., 1963. 594 с.

6. *Дмитриев Н.К.* Грамматика башкирского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948. С. 65.

7. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе: (Очерклар). Казан: Фикер, 2000. 287 б.

8. *Ибраһимов С.М., Сафиуллина Ф.С.* Фигыль сүзтезмәләрнең үсешенә карата // Актуальные вопросы грамматики и стилистики татарского языка. Казань, 1981. Б. 92–101.

9. *Кононов А.Н.* Грамматика языка тюркских рунических памятников VII–IX вв. Л.: Наука, 1980. 254 с.

10. *Лосев А.Ф.* Языковая структура. М.: МГПИ им. В.И. Ленина, 1983. 375 с.

11. *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М.: Наука, 1951. 451 с.

12. *Мөслими.* Тәварихы Болгария / басмага әзерл. С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

13. *Нуриева Ф.Ш.* Письменно-литературный язык XIV века. «Нахдж ал-Фарадис» // История татарского литературного языка. Казань: Фикер, 2003. С. 144–211.

14. *Сәмирханова Г.Р.* Хәзерге татар әдәби телендә килеш мөнәсәбәтләренең белдерелүе. Казан, 2005. 159 б.

15. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һ. авт. М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. III т. 536 б.

16. *Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. 318 с.

17. *Хангилдин В.Н.* Татар теле грамматикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 243 б.

18. *Хисмәтуллин Х.* Шагыйрь Мәүлә Колый иҗаты // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 480–487.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Валиева Милеуша Закиевна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*miliy21@mail.ru*

УДК 811.512.145

***О.Н. Галимова***

# К. НАСЫЙРИНЫҢ «“ГӨЛЗАР ВӘ ЧӘМӘНЗАР” КИТАБЫНА СҮЗЛЕК» ХЕЗМӘТЕ ТЕРМИНОГРАФИК АСПЕКТТА

В предлагаемой статье «Словарь к книге “Цветы и травы”» («“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлек») Каюма Насыри впервые рассматривается в терминографическом аспекте. Изучается композиция словаря, определяются модели словарных статей. Выявляются особенности фиксации заголовочных слов, татарских эквивалентов. Анализ показал, что работа имеет традиционную сегодня макроструктуру и состоит из вводной части, где дается информация о структуре, словнике словаря, а также из самого корпуса словаря, который состоит из 313 расположенных в алфавитном порядке словарных статей с заголовочными словами – названиями растений, их частей и получаемых из них веществ, и приложения со специальными лексемами, имеющимися, в основном, в книге «Цветы и травы». Большое внимание автором уделено синонимичным фитонимам как в русском языке, так и в татарском. В ходе исследования установлено, что К. Насыри работает над совершенствованием терминологических словарей, пробует новое в фиксации заголовочных слов, синонимов в правой части словаря. Автор впервые применяет этимологическую помету *гарәпчә* ‘по-арабски’ с целью выделения заимствованных и своих лексем: указывая арабизмы в фитонимической лексике своего времени, одновременно делает акцент на татарские названия, представляет их в качестве основных терминов. Статья вносит вклад в изучение истории терминологических словарей татарского языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, терминография, терминологический словарь, словари К. Насыри, макроструктура словаря, микроструктура словаря, словарная статья.

In the article “Dictionary for the book "Flowers and Herbs"”» by Kayum Nasyri considered in the thermographic aspect for the first time. The composition of the dictionary was studied. Models of dictionary entries are determined. Features of fixation of headwords, Tatar equivalents are revealed. The analysis showed that the work has the traditional today macrostructure. It consists of an introductory part, where information about the structure and dictionary glossary are given, as well as from the dictionary body itself, which consists of 313 alphabetically arranged dictionary entries with plant title words, their parts and substances obtained from them, and applications with special lexemes available mainly in the book “Flowers and Herbs”. The author pays much attention to synonymous phytonyms both in Russian and in Tatar. In the course of the study, it was established that K. Nasyri is working on improving terminological dictionaries, trying new things in fixing header words, synonyms on the right side of the dictionary. For the first time, the author applies the etymological litter garәpchi “in Arabic” in order to distinguish borrowed and his lexemes: indicating Arabisms in the phytonymic vocabulary of his time, at the same time focuses on Tatar names, presents them as the main terms. The article makes a contribution to the study of the history of Tatar language terminological dictionaries.

**Keywords:** Tatar language, terminology, terminological dictionary, dictionaries of K. Nasyri, macrostructure of the dictionary, microstructure of the dictionary, dictionary entry.

Телнең лексик байлыгын өйрәнү тел белемендә актуаль проблемалардан санала. Бу яктан сүзлекләр аеруча әһәмияткә ия. Шул сәбәпле лексикографик хезмәтләргә тупланган сүз байлыгы гына түгел, ә аны теркәү юлларын өйрәнү һәм камилләштерү дә мөһим мәсьәлә булып тора. Лексикографиядә өстенлекле юнәлешләрнең берсе – терминография [5: 222]. Терминография дигәндә, махсус сүзлекләр төзү теориясе һәм практикасы [3: 6] күздә тотыла. Ул фәннең аерым тармакларының терминологиясен лөгать формасында тикшерә һәм әлеге тармакларны төшенчәләр аша күзаллау мөмкинлеге тудыра [4: 547]. Терминография сүзлекләр төзүне оптималь итеп проектлаштыру, төзү һәм барлыкка китерелгән продуктны нәтиҗәле куллану өчен махсус методика, методлар һәм технологияләр булдыра, терминологик сүзлекләр тарихын өйрәнә [5: 76].

«Татар терминологик сүзлекләре турында фикер йөртү XIX йөзнең икенче яртысында милләт формалашуга бәйле рәвештә башлана» [10: 181], һәм турыдан-туры К. Насыйри исеме белән бәйле була [12: 114]. Галимнәр аның махсус сүзлекләр төзү өлкәсендәге эшчәнлеген югары бәялиләр һәм төп принципларын үрнәк итеп күрсәтәләр: теге яки бу атаманы теркәгәнче, аның халык телендә кулланылу-кулланылмавын тикшерү; телдән әзер сүзләр алу; татар теле материалын кулланып, яңа атама ясау; рус һәм Европа телләреннән алынмаларны куллану һәм калькалаштыру [11: 85; 2: 13]. В. Хангилдин К. Насыйриның китапханә, архивлардагы кульъязмалары арасында саклана торган түбәндәге терминологик сүзлекләре барлыгын билгеләп үтә: «а) Латинча-гарәпчә биология терминнары сүзлеге; б) Татарча-латинча-русча ботаника терминнары сүзлеге; в) Татарча биология терминнары сүзлеге; г) Русча-латинча-татарча ботаника терминнары сүзлеге; д) «Гарәпчә-татарча-латинча гомуми терминнар сүзлегенең башлангычы» [13: 79–80]. К. Насыйриның әлеге сүзлекләрне басылып чыккан хезмәтләрендә, мәсәлән, «Гөлзар вә чәмәнзар», «Буш вакыт» исемле китапларында куллануын әйтә [13: 80]. «Гөлзар вә чәмәнзар» (1894) – татар телендә терминология үсешен өйрәнүдә әһәмиятле хезмәтләрнең берсе. Ф.С. Фасеев «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»нә язылган кереш сүзендә аның татар телендә терминологик сүзлекләр эшләүгә дә тәэсир итүен әйтә [9: 5]. Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова үсемлек һәм игенчелек атамаларын системалы өйрәнү кысаларында К. Насыйриның «Гөлзар вә чәмәнзар»ында үсемлек һәм аның өлешләренең атамалары бирелешенә игътибар итәләр. Мәсәлән, Г.Г. Саберова әлеге китапның үсемлекләрнең үзенчәлекләре турындагы бүлегендә 192 дару үләненең тасвир ителүен, аерым очракларда аларның татар-

ча, русча, латинча, гарәпчә, фарсыча атамалары китерелүен билгеләп үтә [8: 28]. Ф.Ф. Гаффарова мондый күзәтүләрен хезмәттән мисаллар белән дә ныгыта: «*Яфрак* димез, гарәпчә *вәрак* аталыр, *кабык* яки *кайры* гарәпчә *кыйшыр* аталыр». Теркәлгән атамаларны анализлап, ул К. Насыйриның татар терминологиясенә алып килгән яңалыгы дип чын татар сүзләрен фәнгә кертүне, фәнни төшенчәләргә беркетүне күрсәтә [2: 13–14]. Г.Г. Батыршина «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында ботаника гына түгел, ә медицина терминнарының да урын алуын әйтә. Терминнарның татарча-русча-латинча бирелүе хезмәтне тагын да фәннирәк итә, ди һәм китаптан түбәндәге терминнарны мисал итеп китерә:

*гөлбадран – рябина – tanacetum;*
*үги ана яфрагы – мать и мачеха – tussitago;*
*тимер үлән – железняк – verda officinalis;*
*мәтрүшкә – душица обыкновенная – origanum vulgare* [1: 130].

К. Насыйри «“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлек» (1894) тә эшли. Хезмәтне «Гөлзар вә чәмәнзар»да башланган эшнең – үсемлек атамаларының эквивалентларын теркәүнең сүзлек форматында дәвам ителүе дип карарга мөмкин. Аны Ф.С. Фасеев XX гасырның 60 нчы еллары ахырында әле дә кулланырга яраклы дип бәяли [12: 101]. Г.Г. Батыршина, «Гөлзар вә чәмәнзар» китабындагы терминнарны караганнан соң, әлеге сүзлекне дә телгә ала. Анда 313 үсемлекнең русча, латинча, татарча атамалары бирелүен әйтеп үтә [1: 130]. «“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлек» «Татар лексикологиясе» (1918) китабында «Татар лексикографиясе тарихы» бүлегендә дә карала. Монда шулай ук 313 үсемлек атамасының теркәлүе әйтелә, «төп терминнар татарча-русча-латинча китерелә», «кайбер очракта үләннәрнең гарәпчә исемнәре дә күрсәтелә», «кайчакта төп термин гарәпчә бирелеп, аңа татарча тәңгәллек китерелә», «192 дару үләненә аңлатма бирелә» [11: 85], диелә. Хезмәт эквивалентлар аспектында карала, аларга мисал итеп, алда әйтелгән атамалар алына [11: 85].

Ләкин әлеге мәгълүматлар гына татар терминографиясе тарихы, татар телендә терминнарны теркәү үзенчәлекләре турында тулы күзаллау тудыра алмый. Беренче басылып чыккан терминологик сүзлекләр терминография тарихын булдыруда, безнеңчә, зуррак игътибар сорый. Әлеге мәкаләдә Каюм Насыйриның «“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлек» хезмәте беренче тапкыр терминографик аспектта җентекләп өйрәнелә: макроструктурасы һәм микроструктурасы карала, мәкаләләрнең модельләре билгеләнә, «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы» (1892) белән чагыштырылып, үзгәрешләр ачыклана. Тәкъдим ителгән хезмәтнең яңалыгы әнә шуның белән билгеләнә. Татар теле сүзлекләрен шул рәвешчә өйрәнү үзе дә яңалык булып тора. Мәкалә татар теленең терминографиясе тарихын булдыруга үзеннән өлеш кертә.

«“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлек» кыска гына сүз башы белән ачылып китә: « گلزار و چمنزار كتابند ه مذكور نباتات ننك روسيه و لاتينيه لرى و آند ه ذكر ايتولماكان بعض نباتاتلارننك علاو ه سى بلان – لكن لغتلرى بيان قيلنماغان بعض ماده لر هم موجيد بولسه كيراك » / «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында мәзкүр нәбататның русия вә латинияләре вә анда зикер ителмәгән[1] бәгъзы нәбататларның гыйлавәсе[2] белән. Ләкин лөгатьләре бәян кылынмаган бәгъзы матдәләре һәм мәүҗид[3] булса кирәк» [7: 1]. Бер генә җөмлә рәвешендә булса да, ул зур мәгълүмат бирә. Чынлап та әлеге өлешне сүзлеккә кереш дип карап була. Моннан аңлашылганча, хезмәт эшләнеше ягыннан мөстәкыйль түгел, ул «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында булган атамаларны тәкъдим итә. Билгеле булганча, татар лексикографиясе тарихында аерым хезмәтләргә сүзлек эшләү тәҗрибәсе булган. Моңа мисал итеп И. Хәлфинның «Жизнь Джингизъ-хана и Аксакъ-Тимура съ присовокуплениемъ разныхъ отрывковъ до исторiи касающихся, коихъ всѣ слова для обучающихся расположены по алфавиту, въ пользу воспитанниковъ Императорского Казанскаго университета, составленная лекторомъ онаго Университета Ибрагимомъ Хальфиномъ» (1822), С. Кукляшевның «Словарь к татарской хрестоматии» (1859) хезмәтләрен китереп була.

Кереш җөмләдән лөгатьлектә «Гөлзар вә чәмәнзар» китабына кермәгән атамалар да бар дип тә аңлашыла. Монда укучыга үсемлек атамаларының русчасы һәм латинчасы да тәкъдим ителә, кушымта да бирелә. Шул рәвешле, кереш җөмлә укучыга сүзлекнең төзелеше һәм лөгатьлеге турында тулы гына мәгълүмат бирә. Шунысын да әйтергә кирәк: «“Гөлзар вә чәмәнзар”» китабына сүзлек»тә үсемлек атамаларыннан тыш ارم مايى / *әрем мае*, ببريه مايى / *бәбрия мае*, ايمن قاير سى / *имән кайрысы,* جيتون اورلوغى / *җитен орлыгы* [7: 8, 9, 3, 6] кебек сүзтезмәләр дә бар. Бу исә, аларның саны аз булуга карамастан, хезмәтне берничә тармак сүзлеге дип бәяләргә мөмкинлек бирә.

Хезмәтнең лөгатьлек өлеше зур түгел. 12 биттә 313 сүзлек мәкаләсе урнашкан. Алар гарәп цифрлары белән билгеләнгән. Һәр мәкалә өч баганага бүленә. Баш сүз – рус сүзе, ул сул баганада, уртанчы баганада латинча атама урнаштырылган, өченче баганада татарча эквивалент бирелә. Шулай итеп, сүзлек өчтелле, ул русча-латинча-татарча итеп төзелгән, ягъни автор үсемлек атамаларын рус, латин атамалары аша беркетә. Баш сүзләргә килгәндә, К. Насыйри рус телендәге бер атаманы ала һәм аның латинчасын, татарчасын китерә. Әмма лөгатьлектә мәгънәдәш сүзләр дә күренә. Алар ике төрле бирелә. Мәсәлән, беренче баганадагы синонимнар өтер аша һәм ياكه / *яки* теркәгече белән китерелә:

11 Артышъ ياكه арда. Herba sabinae آرتش عرب چه ابهل / *артыш,* гарәпчә *әбһәл* [7: 1].

---

[1] Зикер ителмәгән – телгә алынмаган.
[2] Гыйлавә – кушымта.
[3] Мәүҗид – булган.

Шул ук вакытта бер мәкаләдә аслы-өсле урнаштырылып, һәр икесе бер үк цифрга беркетелгәннәре дә бар. Сүзлек мәкаләләрен шул рәвешчә оештыру, безнең күзәтүләребезгә караганда, терминологик сүзлекләрдә беренче тапкыр тәкъдим ителә:

2 Аиръ благовонный. Calamus aromaticus. حوش ایسلی قاموش

2 Александр. листъ. ایر طامری – عرب چه وج سناء مکه / *хуш исле камыш, ир тамыры*, гарәпчә – *вәҗ, сүнәи мәккә* [7: 1].

Сүзлек рус алфавиты тәртибендә төзелгән. Терминологик сүзтезмәләр, галимнең «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы»ндагыча, аерым сүзлек мәкаләсе тәшкил итә. Алар компонентларының уңай тәртибендә дә, кире тәртибендә дә теркәлгән:

2 Аиръ благовонный. Galamus aromaticus.

حوش ایسلی قاموش ایر طامری – عربچه وج سناء مکه / *хуш исле камыш, ир тамыры,* гарәпчә – *вәҗ, сүнәи мәккә;*

62 Губка древесная. Boletus igniaruius. آغاچ کومبه سی / *агач гөмбәсе* [7: 1, 3].

Сүзтезмәләрне шул рәвешчә теркәү сәбәпле, кайберләре сүзлектә ике тапкыр кулланылган. Мәсәлән, *бѣленное сѣмя* һәм *сѣмя бѣленное* мәкаләләре 32 һәм 238 цифрларына беркетелгән [7: 2, 9].

Рус фитонимнарының кире тәртиптә кулланыла һәм теркәлә алуы татар телендә терминологик сүзтезмәләрне теркәүгә дә тәэсир итә булса кирәк. Мәсәлән, рус телендәге *фиалка трехлистная* атамасының эквиваленты компонентларын К. Насыйри шулай ук инверсияле тәртиптә урнаштыра:

271 Фiалка трехл. Viola odorata. میلاوشه اوچ یافراق / миләүшә өч яфрак [7: 10].

Сүзлектә сүзләрне бирүдә алфавит тәртибе сакланмаган очраклар да бар. Мәсәлән, 305–313 нче *калганъ, имбирь, ипокакуанъ, корица, камфарное дерево, буковое дерево, кедровая смола, сладкiй миндаль, кококсовый орѣхъ* мәкаләләре 304 нче итеп бирелгән *ячмень* мәкаләсеннән соң килә. Боларның үзләре арасында да алфавит бозылган. Шуңа да әлеге мәкаләләр соңрак өстәлгән булырга мөмкин дип уйлыйбыз.

Бер үк ыруг компоненты белән ясалган терминологик сүзтезмәләрне теркәүдә дә алфавиттан тайпылышлар күренә. Мәсәлән, *смородина чёрная* атамасы – 243 номеры белән, ә *смородина красная* 244 номеры белән теркәлгән:

243 Смородина черная. Ribes nigrum. قارا قارلغان / *кара карлыган;*

244 Смородина красная. Ribes. قزل قارلغان / *кызыл карлыган* [7: 10].

Төр атамалары ыруг атамасыннан соң да, аннан алда да бирелә:

223 Ромашка. Matricaria. بابونه – بابونج / *бабунә, бабунәҗ;*

224 Ромашка римская Matricaria nobilis. بابونهٔ رومی / *бабунә руми;*

225 Ромашка простая. Matricaria. پیغمبر چچکی / *пәйгамбәр чәчәге*;
296 Шафранъ луговой. Colchicum autumnale. زغفران بری – لحلاح / *зәгъфран бәри, лихлах*;
297 Шафранъ. Safran. زغفران / зәгъфран [7: 9, 11].

Хезмәттәге аерым мәкаләләр шулай ук баш сүзләрнең тәртибе бозылган дигән тәэсир тудырырга мөмкин, чөнки К. Насыйри бер үк мәгънәдәге сүзләрнең һәркайсын яңа юлдан, ләкин бер үк цифр белән терки. Автор аларны шул рәвешчә тигез хокуклы терминнар буларак тәкъдим итә булса кирәк:

22 Благодать трава. Gratila officinalis کرمته البیضا – اورن
22 Лихор. трава / *кәрмәт әл-бәйза, урен* [7: 2].

Баш сүзләрне өйрәнү сул якта үсемлек атамаларының – ачыклагыч, сирәгрәк төп компонентының да кыскаруын күрсәтә. Әйтергә кирәк, мондый күренеш К. Насыйриның «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы»на да хас. Аларның кайберләре беренче таблицада чагылыш таба.

1 нче таблица

К. Насыйри сүзлекләрендә баш сүзләрдәге кыскартылмалар

| Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы | «Гөлзар вә чәмәнзар» китабына сүзлек |
|---|---|
| – | Александр. листъ. |
| Вероника (апт.) | 37 Вероника (аптечн.) |
| Ложечная трава | 135 Ложечный тр. |
| – | 2 Александр. лист |
| – | 22 Лихор. трава |
| Фіалка трехлистный | 271 Фіалка трехл. |
| – | 295 Шандра собир. |
| Касатик болотн. | 101 Касатикъ болотный |
| – | 120 Куркумъ длин. |
| – | 121 Куркумъ болот. |
| – | 119 Кукушка соб. |

Атамаларны чагыштыру үсемлек атамаларының озынлыгын киметүнең әле системалы булмавын күрсәтә. Ул бигрәк тә бер үк компонентлы атамаларда күзгә ташлана. Мәсәлән, ачыклагыч *аптечный* компоненты кыскартылмыйча да, берсе – озынрак, берсе кыскарак формада киселеп тә кулланылган:

14 Балдырьянъ аптечный. Valeriana officinalis. سنبل جبلی / *сөнбел җәбәли;*

34 Валеріана аптечн. Valeriana officinalis. سنبل بری – والریانا / *сөнбел бәри – валериана*;

156 Маунъ апт. Valeriana. سنبل جبلی – والیریانا / *сөнбел җәбәли – валериана* [7: 1, 2 , 7].

Һәр рус атамасына икенче баганада бер латин эквиваленты китерелгән, ә өченче баганада татар эквивалентлары урын алган. Алар атама буларак кына түгел, ә теркәлүләре белән дә игътибарга лаек. К. Насыйри хезмәтләренә үзе белгән, халыкка таныш булган бөтен атаманы теркәргә омтыла булса кирәк, моннан тыш үзе дә атамалар ясый. Шуңа да сүзлекнең уң ягы синонимнарга, вариантларга бай. Бу өлештә гарәп атамалары да шактый урын алып тора. Синонимнар сызыкча аша һәм *яки* теркәгече белән яисә махсус билгеләр белән аермыйча да теркәлә:

8 Армодъ. Pyrus cydonia. امرود یاکه ارمود / *амруд* яки *армуд*;

9 Ааронова борода. Arum maculatum. یلان یاصدوغی یاکه هارون صاقالی / *елан ястыгы* яки *Һарун сакалы*;

214 Просвирняк аптечный. Malva silvestris. ابه کوماچی – ماچی بورچاغی – خبازی / *әбә күмәче – мачы борчагы – хуббаза*;

174 Наперстникъ. Didgitalis. یوکسك اوطی – اویماق اوطی دیجیتال – اصبعی / *юксек уты – уймак уты, диҗитал – исбәгый*;

114 Крутина. Rhamnus. ات شمرطی ات جیلاکی / *эт шомырты, эт җиләге* [7: 1, 9, 7, 5].

Галимнәр, инде әйтеп үтелгәнчә, К. Насыйриның «гарәп терминнарына татарча конкурентлар тудыру»ына басым ясыйлар [11: 271], татар телендә атама табылмаганда, тәрҗемә һәм калькалаштыру алымнарын (ангелика – *фәрештә уты*, ааронова борода – *Һарун сакалы*, тысячелистник – *меңъяфрак*) уңышлы куллануын [1: 130] әйтәләр. «“Гөлзар вә чәмәнзар”га сүзлек»не «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы» [6] белән чагыштыру галимнең әлеге юнәлештәге эшен күрсәтергә дәлилләр бирә. Икенче таблицада шундый кайбер мәкаләләр китерелә һәм алардагы үзгәрешләр билгеләнә. Мәсәлән, күп кенә гарәп алынмалары *гарәпчә* дип күрсәтелә. Бу күренешне татар терминографиясендә беренче тапкыр махсус билге, ягъни помета куллану очрагы дип әйтә алабыз. Чыганак телне махсус билгеләү, безнеңчә, нәкъ менә телнең үз сүзләрен аерып бирүгә хезмәт итә. Шул ук вакытта сүзлек мәкаләләре яңа материал белән дә баетыла. Мәсәлән, *ааронова борода, анис, горох мышиный* кебек мәкаләләрдә татар теленнән синонимнар китерелә; *тюльпан* мәкаләсендә алынма фитоним өстәлгән; *артыш, анис, арбуз* мәкаләләренә гарәпчә алынмалар өстәп бирелә, яисә элек теркәлгәннәренең гарәп теленнән булуы күрсәтелә. Шулай итеп, автор әлеге сүзлегендә төп игътибарын эквивалентларга юнәлтә, аңлатмалар бирүне кирәк дип тапмый.

2 нче таблица

Терминологик сүзлекләрдә фитонимнарны теркәү

| Баш сүз | Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы | «Гөлзар вә чәмәнзар» китабына сүзлек | «“Гөлзар вә чәмәнзар» китабына сүзлек»кә өстәлгән / үзгәртелгән кисәк |
|---|---|---|---|
| *аронова / ааронова борода* | هان صاقالی دیکان بر نباتدر / Һарун сакалы дигән бер нәбаттыр | یلان یاصدوغی یاکه هارون صاقالی / елан ястыгы яки Һарун сакалы | یلان یاصدوغی / елан ястыгы |
| *артышъ* | آرطش / артыш | آرطش عربچه ابهل تورکچه اردج / артыш, гарәпчә – әбһәл, төрекчә – ардыҗ | عربچه ابهل‌تورکچه اردج / гарәпчә – әбһәл, төрекчә – ардыҗ |
| *бездушка* | ام الفطر - کومبه آناسی / үмм әл-футр – гөмбә анасы | کومبه آناسی عربچه ام فطر / гөмбә анасы, гарәпчә – үмм футр | عربچه ام فطر / гарәпчә – үмм футр |
| *анисъ* | معلوم بر خوش ایسلی اولندر وانیسون آطالور – یوتالنی یومشاتور / мәгълүм бер хуш исле үләндер вә әнисун аталыр – ютәлне йомшатыр | انیچ عربچه انیسون / әнич, гарәпчә – әнисун | انیچ عربچه انیسون / әнич, гарәпчә – әнисун |
| *арбузъ* | بطیخاخضر – خربوزه – قاربوز / бәттыйх ихзар – харбузә, карбуз | قاربوز عرب چه بطیخ احضر / карбуз, гарәпчә – бәттыйх ихзар | عرب چه بطیخ احضر / гарәпчә – бәттыйх ихзар |
| *горец апт.* | عصی الراعی–چوثان تایاغی / гаса әр-рагый – чупан таягы | چوپان تایاغی عربچه عصی الراعی / чупан таягы, гарәпчә – гаса әл-рагый | عربچه عصی الراعی / гарәпчә – гаса әл-рагый |
| *болиголовъ* | شوقران کبیر / шөкран кәбир | شوقران کبیر – بالدران / шөкран кәбир – балдыран | بالدران / балдыран |
| *бузина чёрная* | (نباتاتدان) قارا بوزون / (нәбататтан) кара бузун | کارا بوزون – بلسان آغاچی / кара бузун – бәләсан агачы | بلسان آغاچی / бәләсан агачы |
| *горохъ мышиный* | صچقان بورچاغی / сычкан борчагы | طچقان بورچاغی یاکه بت اولنی / тычкан борчагы яки бет үләне | یاکه بت اولنی / яки бет үләне |
| *зубъ собачий* | ات تشی بر نباتدر / эт теше, бер нәбаттыр | ات تشی یاکه صاروت / эт теше яки сарут | یاکه صاروت / яки сарут |
| *тюльпанъ* | (اق لاله ) معروف چچکدر توبنده صوغانی بار / ак лалә мәгърүф чәчәктер, түбәндә суганы бар | اق لاله – تولثان / ак лалә – тюльпан | تولثان / тюльпан |

Сүзлек мәкаләләре төрле. Иң гадиләре баш рус сүзеннән һәм аның латин, татар телендәге эквивалентларыннан тора. Татар өлешендә эквивалент булып татар сүзе дә, гарәп сүзе дә, башка теллләрдән алынмалар да бирелә ала:

20 Берёза. Betula alba. قايين / *каен*;

23 Блекота черная. Hyosciamus niger. قارا تیلبران / кара *тилбәрән*;

34 Валеріана аптечн. Veronica officinalis. سنبل برى – والريانا / *сөнбел бәри*, *валериана* [7: 2].

Өченче баганада ничә эквивалент теркәлүгә карап, сүзлек мәкаләләренең берничә моделен күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, «баш рус сүзе – латин эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты». Алынма атамаларның чыганагы күрсәтелмәгән сүзлек мәкаләләрен дә шушы төргә кертеп карыйбыз:

35 Василекъ. Centaureum. آلتمش تارماق – قنطر بون / *алтмыш тармак*, *кантарбун*;

52 Глазки анютины. Viola quadrifolia. قارغه كوزى ياكه توله مه جيلاكى / *карга күзе* яки *түләмә җиләге*;

98 Каперсы. Capparis spinosa. قبار – كباريه / *каббар – кәббария* [7: 2, 3, 4].

Татар өлешендә өч һәм дүрт эквивалент китерелгән мәкаләләр дә бар. Аларның моделе түбәндәгечә була: «баш рус сүзе – латин эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты», «баш рус сүзе – латин эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты»:

64 Гулявица чихотная. Herba ptarmicae. توچكروك اولنى – عطسه عطاس / *төчкерек үләне*, *гатсә, гыйттас*;

72 Дубъ. Quercus ايمن آ غاچى – پلوط – آق ميشه / *имән агачы*, *пәлут*, *ак мишә*;

154 Маточникъ. Matrikaria chamomilla. پاپاديه – بابونج – پيغمبر چچكى / *пападия, бабунәҗ, пәйгамбәр чәчәге*;

174 Наперстникъ. Digitalis. يوكسك اوطى – اويماق اوطى ديجيتال – اصبعى / *юксек уты, уймак уты, диҗитал, исбәгый* [7: 3, 6, 7].

Атаманың гарәп теленнән икәнлеге күрсәтелгән мәкаләләрне яңа модельдә оештырылган дип карарга кирәк дип саныйбыз, чөнки, инде әйтелгәнчә, К. Насыйри татар теленең үз атамаларын күрсәтүне бурыч итеп куйган. Ачыкланган модельләрдә чыганак тел белән эквивалентны аерып күрсәтү дә әнә шуны тасвирлау максаты белән эшләнде. Шулай итеп, мондый мәкаләләрне «баш рус сүзе – латин эквиваленты – татар эквиваленты – гарәпчә тамгасы + эквивалент» моделендә бирелгән дип әйтергә була. Ә инде алынма атамаларның саны артканда, мәкаләләр «баш рус сүзе – латин эквиваленты – татар эквиваленты – гарәпчә тамгасы + эквивалент – эквивалент» кебек асмодельләрдә формалаша:

38 Виноградъ. Vitis vinifra .يوزوم عربچه عنب / *йөзем* гарәпчә *гыйнәб*;

53 Горецъ аптечный. Poligonum bistorta چوپان تاياغى عربچه عصى الراعى / *чупан таягы,* гарәпчә – *гаса әл-рагый;*

33 Бѣлокопытникъ. Tussilago. – اوگى آنا يافراغى عربچه حشيشه السعال طول عورت / *үги ана яфрагы,* гарәпчә – *хәшишәт әс-сүгал,* (?) *тули гаурәт* [7: 2, 3].

Кайбер очракларда К. Насыйри башка телләрне дә күрсәтә. Мәсәлән, түбәндәге сүзлек мәкаләсе «баш сүз – *яки* теркәгече – синоним – латин эквиваленты – татар эквиваленты – гарәпчә тамгасы + эквивалент – төрекчә тамгасы + эквивалент» моделендә. Әлеге мәкалә баш сүз янында синоним бирелү белән дә катлауландырылган:

11 Артышъ ياكه арда Herba sabinae آرتش عرب چه ابهل توركچه اردج *артыш,* гарәпчә – *әбһәл,* төрекчә – *ардыҗ* [7: 1].

Сул якта синонимнарның бирелүенә бәйле рәвештә «цифрлы баш сүз – цифрлы баш сүз – латин эквиваленты – татар эквиваленты – татар эквиваленты – гарәпчә тамгасы + эквивалент – эквивалент» моделендә оешкан сүзлек мәкаләсен күрсәтергә мөмкин:

2 Аиръ благовонный. Calamus aromaticus. حوش ايسلى قاموش

2 Александр. листъ اير طامرى – عربچه وچ سناء مكه / х*уш исле камыш, ир тамыры,* гарәпчә – *вәҗ, сүнәи мәккә* [7: 1]

Сүзлек ахырында, 12–16 битләрдә «صفرندان قاراب روسچه سن تابارغه» / «Сыйфырыннан карап, русчасын табарга» дигән баш астында кушымта бирелә. Бу өлеш тә өч баганага бүленә. Һәр баганада алфавит тәртибендә «Гөлзар вә чәмәнзар»да кулланылган сүзләр урнаштырыла, аларның битләре күрсәтелә.

Шул рәвешчә, «“Гөлзар вә чәмәнзар”га сүзлек» – русча-латинча-татарча сүзлек. Монда, башлыча, үсемлек атамалары теркәлгән. Шулай ук үсемлек морфологиясенә караган һәм үсемлектән алына торган матдәләрнең дә атамалары кергән. Хезмәт структур яктан өч өлештән тора: кереш, сүзлек, кушымта. Лөгатьлек рус алфавиты тәртибендә эшләнгән, әмма алфавиттан тайпылышлар да күзәтелә. Алар, нигездә, баш сүзләрнең компонентларына бәйле, шул ук вакытта сүзлеккә өстәмәләр кертү белән дә аңлатылырга мөмкин. Мәкаләләрнең һәм рус, һәм татар өлешләренә синонимнар тупланган. Сул якта мәгънәдәш атамалар янәшә дә, һәркайсына бер үк цифр куеп, аслыөсле дә урнаштырылган. Соңгысы исә баш сүзләрне яңача теркәү булып тора. Татар өлешендә синонимик атамалар бер-бер артлы тезелеп бирелә. Хезмәтнең төп яңалыгы – гарәп сүзләрен аерып күрсәтү. Әлеге максаттан К. Насыйри *гарәпчә* тамгасын куллана. Бу өлеш татар эквивалентыннан соң өстәмә мәгълүмат буларак бирелә һәм, әйтергә кирәк, әле системалы түгел.

К. Насыйриның «“Гөлзар вә чәмәнзар”га сүзлек» һәм «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы»нда уртак һәм аермалы якларның булуы сүзлекченең терминнарны теркәүдә яңа юллар

эзләвен, башта кулланылган алымнарны камилләштерергә омтылуын күрсәтә.

Татар теленең башка терминологик сүзлекләрен дә әлеге яссылыкта өйрәнергә кирәк дип саныйбыз.

**Әдәбият**

1. *Батыршина Г.Г.* Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. Казан: КДАТУ нәшр., 2007. 171 б.

2. *Гаффарова Ф.Ф.* Татар телендә җир эшкәртү лексикасы. Казан: Матбугат йорты, 2000. 176 б.

3. *Гринев-Гриневич С.В.* Введение в терминографию: Как просто и легко составить словарь: уч. пособ. изд. стереотип. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2021. 222 с.

4. *Дубичинский В.В.* Некоторые современные вопросы лексикографии. Rasprave: Časopis Instituta za hrvatski jezik i jezikoslovlje. Вып. 46, 2020. С. 547–566.

5. *Комарова З.И.* Теоретико-методологическая база современной русской терминографии // Вестник Челябинского государственного университета, 2016. № 4 (386). Филологические науки. Вып. 100. С. 74–77.

6. *Насыйри К.* Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы. Казан: Ун-т тип., 1892. 263 б.

7. *Насыйри К.* «Гөлзар вә чәмәнзар» китабына сүзлек. Казан, 1894. 16 б.

8. *Саберова Г.Г.* Названия растений в татарском литературном языке / науч. ред. Ф.А. Ганиев. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1996. 130 с.

9. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / төз.: А.К. Тимергалин, Г.Г. Әхмәтов, Ш.Г. Садыйков; махсус ред. Ф.С. Фасеев. Казан, 1971. 304 б.

10. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. 2 т. 392 б.

11. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2018. 3 т. 2 кис. 392 б.

12. *Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 200 б.

13. *Хангилдин В.* К. Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 78–91.

***Галимова Ольга Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Галимова Ольга Николаевна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела лексикографии Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*Olgan_77@mail.ru*

УДК 81’374

*Г.Ф. Лутфуллина*

# ТАТАР ТЕЛЕ ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ ТЕЛ АҢЫ ҮЗӘГЕ ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ

Цель настоящего исследования – выявить лексические единицы, которые формируют языковое сознание носителей татарского языка, используя различные методы анализа ассоциативных реакций. В результате работы установлено, что слова-маркеры, репрезентаторы, идентификаторы и наиболее часто встречающиеся лексемы способствуют реконструкции системы языкового сознания, отражая специфику языка и подчеркивая культурные и когнитивные особенности татар, закрепленные в их языковой картине мира. Особое внимание уделено семантическим характеристикам слов-стимулов и реакций в ассоциативном поле. Все примененные нами способы позволяют выделить лексемы, входящие в национальное самосознание народа, которое детерминируется через антропологический, исторический и понятийный аспекты. На основе анализа данных ассоциативного словаря татарского языка можно утверждать, что в ядро языкового сознания носителей татарского языка входят такие базовые понятия, как душа, родной, луч, дом, сила, человек, земля, свобода, настроение.

**Ключевые слова:** языковое сознание, ассоциативный словарь татарского языка, носитель татарского языка, слова-маркеры, слова-репрезентаторы, слова-идентификаторы, высокочастотные слова.

The purpose of this study is to identify lexical units that form the linguistic self-consciousness of native Tatar speakers using various methods of analyzing associative reactions. As a result of the work, it was found that marker words, representative-words, identifier-words and the most frequently encountered words contribute to reconstruct the system of linguistic consciousness, reflecting the specifics of the language and emphasizing the cultural and cognitive features of the Tatars, enshrined in their linguistic picture of the world. Particular attention is paid to the semantic characteristics of stimulus words and reactions in the associative field. All the methods we used allow us to identify lexemes that are part of the national self-consciousness of the people, which is determined through anthropological, historical and conceptual aspects. Based on the analysis of the Associative Dictionary of the Tatar Language, it can be argued that the core of the linguistic consciousness of native Tatar speakers includes such basic concepts as soul, native, ray, home, strength, person, land, freedom, mood.

**Keywords:** linguistic consciousness, Associative dictionary of the Tatar language, native speaker of the Tatar language, marker words, representative words, identifier words, high-frequency words.

Мәкаләнең актуальлеге милли үзаңның типик сыйфатларын һәм компонентларын ачыклау, саклау һәм культивацияләү зарурлыгы белән билгеләнә. Интернетта кулланыла торган, хәзерге җәмгыять ихтыяҗларына һәрвакытта да җавап бирмәгән кыйммәтләрне яшертен рәвештә алга сөргән һәм мәдәни аерымлыкларны бетергән

телләр өстенлек иткән цифрлаштыру дәверендә әлеге мәсьәләләр аеруча зур әһәмияткә ия. Теге яки бу милләтнең үз тамырларына, үз мәдәниятенә мөрәҗәгать итүе аның бөтенлеген, кыйммәтләрен саклап калырга мөмкинлек бирә. Ассоциатив сүзлек ярдәмендә тел аңын тикшерү традицион мәдәни ориентирларны ачыклау юлы белән этник кыйммәтләр, образлар системасын күзалларга һәм аларны интерпретацияләргә ярдәм итә. Тел үзаңы өлкәсенә караган лексемаларны анализлау этномәдәни үзенчәлекләрне һәм мәдәниятара бәйләнешләр контекстында, һәм бер мәдәният кысаларында өйрәнү өчен тиешле шартлар тудыра [9]. Бүгенге көндә төрле этносларның тел аңын тикшерү актуаль проблемаларның берсе булып тора һәм бер төркем галимнәрнең хезмәтләрендә чагылыш таба. Мәсәлән, А.П. Боргоякова хакас, рус һәм инглизләрнең иллешәр нигез сүзне үз эченә алган тел аңы үзәген аерып чыгара [1]. Казах теле материалы нигезендәге тикшеренүләр Н.В. Дмитрюк, Г.И. Черкасова һәм Ф.И. Артыкбаева [3] хезмәтендә чагылыш таба.

Т.Н. Ушакова фикеренчә, вербаль-ассоциатив алым тел һәм аң арасындагы үзара бәйләнешләрне ачыклау ысулы булып тора, чөнки аңасты дәрәҗәсендә лексик берәмлекләргә гомум кабул ителгән коннотацияләр, образлар беркетелә, һәм әлеге лексемаларны өйрәнү алар үз эченә алган кыйммәтләрне билгеләргә мөмкинлек бирә. Бу очракта бөтен сүзлек запасыннан үзендә нигез сүзләрне берләштергән үзәк аерып чыгарыла. Тел чынбарлыкны концептуальләштерү һәм аны чагылдыру инструменты, ягъни кеше аңының көзгесе булып тора [12: 6].

Нигез лексик берәмлекләр үз чиратында милли фикерләүнең базасын тәшкил итәләр, алардан тел вәкилләренең күпчелек төшенчәләрен аңлату өчен файдаланалар.

Куелган максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү сорала: 1) тел аңы өлкәсенә караган маркер сүзләрне аерып чыгару; 2) репрезентант сүзләрне билгеләү; 3) идентификатор сүзләрне тикшерү; 4) ассоциацияләрнең характерын аеруча еш билгели торган лексик берәмлекләрне ачыклау.

Тикшеренүгә материал татар теленең 2024–2025 елларда компьютер технологияләре ярдәмендә ачыкланган ассоциацияләрнең нәтиҗәләре буенча төзелгән ассоциатив сүзлегеннән алынды. Эш барышында, аерым алганда, милли мәдәниятнең аеруча мөһим маркер сүзләрен аерып чыгарганда, семантик, репрезентант һәм идентификатор сүзләрнең кырын тәшкил иткән ассоциацияләрне аңлатканда тасвирлама алымнар кулланылды. Күләм ягыннан анализ алымы ассоциатив сүзлекнең югары ешлыклы берәмлекләрен билгеләгәндә файдаланылды.

Тикшеренүнең теоретик нигезен Т.Н. Ушакова [12], Э.Ф. Тарасов [10], Т.М. Рогожникова, Г.Р. Кочетова [8], Ю.Н. Караулов [6; 7], А.П. Васильева [2] кебек галимнәрнең тел аңы концепциясенә һәм

тел аңының системалылыгы мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре тәшкил итте.

Үз вакытында А.А. Залевская фәнни кулланылышка ассоциатив кырларда нигез лексемаларның ешлыгын белдерә торган «бәйләнешләрнең югары тыгызлыгы» дигән терминны кертеп җибәрде [4: 273]. Әлеге лексемалар башка сүзләр белән иң күп бәйләнешләр барлыкка китерәләр һәм, асылда, телдәге башка төшенчәләр чагылыш тапкан каркасны тәшкил итәләр. Сан ягыннан алар чагыштырмача күп түгел, ләкин билгеләнгән ассоциацияләр составында шактый зур урын алып торалар [4: 112].

Н.О. Золотова үзенең хезмәтләрендә лексикон концепциясен алга сөрә. Аның нигезендә сүзләр ассоциацияләр составында чагылыш табу ешлыкларына бәйле рәвештә дифференциацияләнәләр [5: 90]. Тел аңы үзеген башкаларны интерпретацияләгәндә катнашкан һәм сүзләр арасында өзлексез бәйләнеш барлыкка китергән нигез лексемалар тәшкил итә [11: 79]. Тел аңы үзәге лексемаларын аерып чыгару методларының берсен тәшкил иткән ассоциацияләр составындагы югары ешлыклы сүзләрне билгеләү методикасы А.А. Залевская тарафыннан эшләнде.

Татар теленең ассоциатив сүзлеге Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе булышлыгы белән төзелде. Бу сүзлек якынча 20 ассоциацияле 500 дән артык стимул сүзне үз эченә ала. Алар ассоциатив ешлыклары кимү тәртибендә урнаштырылган. Күләме ягыннан чикләнгән әлеге хезмәт алга таба аның даими тулыландыру мөмкинлеген күз уңында тоткан онлайн версиясен эшләү кебек перспектив тикшеренүләр өчен нигез булып тора. Сүзлек, ассоциатив бәйләнешләрне анализлаганда уңайлы булсын өчен, «сүз – реакция» принцибы нигезендә төзелде. Татар теле вәкилләренең ассоциацияләре Татарстан Республикасы кысаларында халыкның чагыштырмача яшь өлеше арасында тупланды. Әлеге эш тәкъдим ителгән ассоциацияләр җыелмасын үз эченә алган һәм үзеңнекеләрне өстәү мөмкинлеге каралган Google формаларын тутыру юлы белән башкарылды. Нәтиҗәләр ачык стандарт ассоциатив эксперимент алымы белән тикшерелде.

Тикшеренүнең практик әһәмияте аның нәтиҗәләрен татар телен өйрәнүдә, лингвокультурология һәм мәдәниятара коммуникацияләр дисципланаларының теоретик курсларын эшләгәндә, татар теленнән укыту әсбаплары һәм сүзлекләр төзегәндә җәлеп итү мөмкинлеге белән билгеләнә.

Татар теленең ассоциатив сүзлеге, алда әйтеп киткәнчә, стимул сүзләрне һәм тәкъдим ителгән ассоциацияләр җыелмасын үз эченә алган Google формаларын тутыру юлы белән башкарылды. Экспериментта 18 яшьтән 21 яшькә кадәрге 500 дән артык вуз студенты катнашты. Ир-атлар һәм хатын-кызлар бертигез күләмдә диярлек җәлеп ителде. Контингент татар телен белү дәрәҗәсен ачыклауга юнәлтелгән шәхси әңгәмә нигезендә алдан билгеләнде.

**Маркер сүзләр** телнең әлеге мәдәнияткә генә хас булган һәм аның төп милли кыйммәтләрен гәүдәләндергән нигез берәмлекләрен тәшкил итәләр. Тел аңы системасын төзү эше нәкъ менә әлеге лексемаларны (1 нче табл. ) анализлау нигезендә башкарылды. Аларны билгеләү өчен тоташтан сайлап алу алымы кулланылды. Бу үз чиратында татар мәдәниятендә урын алган милли реалияләрне чагылдырган сүзләрне билгеләргә мөмкинлек бирде.

1 нче таблица

Татар теле вәкилләре тел аңының маркер сүзләре

| № | Маркер сүзләр | Ассоциацияләр |
|---|---|---|
| 1 | Тукай | шагыйрь, әдәбият, татар, мәдәният, шигырь, иҗат, халык, милләт, тел, горурлык, тарих, белем, рух, сәнгать, китап, уку, тәрбия, җан, яшьләр, мирас |
| 2 | Сабантуй | көрәш, бәйрәм, ат чабышы, җыр, бию, гореф-гадәт, авыл, кунаклар, ашамлык, күңел ачу, сабан, уеннар, дуслык, мәдәният, Казан, көмеш, җәй, көрәшче, йолдыз |
| 3 | Бәлеш | аш, милли ризык, пешерү, камыр, тәмле, традиция, бәйрәм, туганнар, өстәл, ризык әзерләү, тәм, аш пешерү, милли кухня, тәмләткечләр, ашамлык, аш бүлмәсе, аш пешерүче, ризык рецепты, ашамлык төрләре |
| 4 | Өчпочмак | өчпочмак, камыр, ит, бәрәңге, пешерү, тәмле, милли ризык, аш, табын, кунак, традиция, туган көн, бәйрәм, кухня, ризык, тәм, пешекче, әзерләү, җылы |

Таблицадан күренгәнчә, ассоциацияләр маркер сүзләрнең семантикасын гына ачып калмыйча, милли аңның түбәндәге төп компонентларын да актуальләштерәләр:

1) антропологик аспект белән бәйле *туганнар, кунаклар, яшьләр, авыл* төшенчәләрен;

2) тарихи аспект белән бәйле *тарих, традиция, мирас* төшенчәләрен;

3) концептуаль аспект белән бәйле *тел, белем, җан, татар, бәйрәм, милләт, милли* төшенчәләрен.

Милли мәдәниятне татар теле вәкилләре өчен аеруча әһәмиятле булган *Сабантуй, Тукай* сүзләре, милли ашларның атамалары һ. б. маркерлый. Аңда әлеге маркерларга *туганнар (кунаклар, яшьләр), тарих, мирас, тел, белем, җан, бәйрәм, рух, милләт* кебек төшенчәләр белән бәйле күзаллаулар беркетелә.

Тел аңы милләт һәм халык төшенчәләре белән бәйле **репрезентант сүзләр** (2 нче табл. ) нигезендә дә анализланырга мөмкин.

2 нче таблица

*Милләт* һәм *халык* төшенчәләре белән бәйле репрезентант сүзләр

| № | Репрезентант сүзләр | Ассоциацияләр |
|---|---|---|
| 1 | Милли | халык, тел, гореф-гадәт, мәдәният, бәйрәм, кием, милли ризыклар, тарих, горурлык, милли музыка, милли бию, милли символлар, милли тел, милли әдәбият, милли сәнгать, милли бәйрәмнәр, милли гореф-гадәтләр, милли җырлар, милли рәсемнәр, милли мирас |
| 2 | Нәсел | гаилә, ата-баба, туганнар, нәсел агачы, нәсел җепләре, нәсел тарихы, нәсел саклау, нәсел тамырлары, нәсел бәйләнеше, нәсел варислары, нәсел традицияләре, нәсел хөрмәте, нәсел горурлыгы, нәсел бердәмлеге, нәсел байлыгы, нәсел үсеше, нәсел җыены, нәсел бәйрәме, нәсел тарихын өйрәнү, нәселне саклау |
| 3 | Иман | дин, Алла, дога, изгелек, җәннәт, җәннәткә ышану, дини белем, намаз, догалар уку, рухи көч, иманлы кеше, изге китап, гыйбадәт, иман нуры, иманлы тормыш, рухи тәрбия, иманның көче, иман һәм ышаныч, иманлы җан, изге юл |

Таблицадан күренгәнчә, ассоциацияләр *нәсел* һәм *иман* репрезентант сүзләренең эчтәлеген ачып бирә һәм *милли* сыйфаты белән еш ярашкан түбәндәге төшенчәләрне идентификацияли:

1) антропологик аспект белән бәйле *халык, туганнар, кеше* төшенчәләрен;

2) тарихи аспект белән бәйле *гореф-гадәт, мирас, тарих, традиция* төшенчәләрен;

3) концептуаль аспект белән бәйле *тел, бәйрәм, милләт, милли, көч, җан* төшенчәләрен.

Милли өлкәне һәр тел вәкиле үз мәгънәсен салган һәм үз компонентларын (*халык (туганнар, кеше), тарих, мирас, тел, бәйрәм, милләт, көч, җан* кебек төшенчәләрне) аерып чыгарган сүзләр идентификацияли.

Алга таба тел аңының үзәген торгызу өчен **идентификатор сүзләр** (3 нче табл.) анализланырга мөмкин.

3 нче таблица

*Туган* һәм *Ватан* төшенчәләренең асылын ача торган идентификатор сүзләр

| № | Идентификатор сүзләр | Ассоциацияләр |
|---|---|---|
| 1 | Туган | җир, гаилә, мәхәббәт, тугрылык, дуслык, йорт, балачак, кайгырту, туганлык, изгелек, тынычлык, горурлык, хәтер, туган тел, бәйрәм, җылы, якынлык, туган көн, ярдәм, бәхет |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Туган җир | авыл, шәһәр, табигать, тарих, туган тел, горурлык, ватандашлык, туган җирнең матурлыгы, туган җирне саклау, туган җиргә мәхәббәт, туган җирнең традицияләре, туган җирнең халкы, ватаныбыз, туган җиргә кайту, туган җирнең символлары, туган җирнең тарихы, туган җирнең киләчәге, туган җирдә яшәү, туган җирнең табигате, туган җирнең рухы |
| 3 | Туган тел | тел, сөйләм, сүз, әдәбият, мәдәният, горурлык, халык, белем, укыту, сөйләшү, аңлау, тарих, тел байлыгы, сөйләм теле, сүзлек, шигырь, җыр, телне саклау, телне өйрәнү, тел үсеше, телнең әһәмияте |
| 4 | Туганлык | гаилә, туганнар, мәхәббәт, бердәмлек, җылы мөнәсәбәтләр, ярдәм, туган йорт, туган тел, туган җир, туган көн, туганнар җыены, туганлык хисе, туганнар арасында, якынлык, туганлык җепләре, туганлык ныгытучы, туганлык һәм дуслык, туганлык һәм хөрмәт, туганлык һәм ярдәмләшү |

Һәр милләт өчен төшенчәләрне үз һәм чит төшенчәләргә бүлү хас. Биредә ярашу белән бәйле ассоциацияләр дә, гади ассоциацияләр дә мөһим роль уйный. Татар теле вәкилләре үзләренеке итеп түбәндәгеләрне санышйлар:

1) территория белән бәйле *йорт, авыл, җир* төшенчәләрен;
2) *кешеләр, гаилә, туганлык* төшенчәләрен;
3) тел белән бәйле төшенчәләрне;
4) тарих, традицияләр, хәтер белән бәйле төшенчәләрне;
5) *бәйрәм, белем, җыр, рух* төшенчәләрен.

Тел аңының эчтәлеге ассоциатив-вербаль челтәрдә һәм гомумән сөйләм практикасында еш чагылыш таба торган **югары ешлыклы сүзләрне** (4 нче табл.) анализлау юлы белән ачыкланырга мөмкин.

4 нче таблица

Татар теленең ассоциатив кырындагы югары ешлыклы сүзләр

| Сүзләр | Чагылыш табу ешлыгы | Сүзләр | Чагылыш табу ешлыгы |
|---|---|---|---|
| туган | 83 | кеше | 76 |
| нәсел | 19 | гаилә | 30 |
| халык | 22 | җир | 61 |
| иген | 25 | ирек | 83 |
| гомер | 7 | җыр | 50 |
| җан | 68 | ризык | 38 |
| нур | 65 | күңел | 226 |
| кыр | 63 | бала | 50 |
| өй | 184 | йорт | 74 |
| һөнәр | 22 | өлкән | 3 |
| көч | 106 | үткән | 27 |

Н.С. Сергиева фикеренчә, нигез берәмлекләр ассоциацияләр составындагы түбән ешлыклы башка сүзләрне табарга мөмкинлек бирә [9: 224]. Ешлык күрсәткечләре буенча, 20 ассоциацияле 550 стимул сүз (барлыгы 1000 сүз) арасында иң югары ешлыкка *җан, туган, нур, өй, көч, кеше, ирек, күңел, йорт* лексемалары ия.

Киң ассоциацияләр алымы дөнья образының гади күзгә күренми торган системалылыгын ачуның бер ысулы булып тора [11: 78] һәм ассоциацияләрне барлыкка китерүдә катнашуы ешлыгын билгеләү нәтиҗәсендә тел аңы үзәге составына кергән лексик берәмлекләрне ачыклап була. Соңгы фактор аларның тел вәкилләре лексиконындагы күпчелек сүзләр белән үзара бәйләнешенең күрсәткече булып тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, тикшеренү барышында кулланылган барлык ысуллар халыкның антропологик, тарихи һәм концептуаль аспектлар аша билгеләнгән милли үзаңында урын алган лексемаларны ачыкларга мөмкинлек бирә. Маркер сүзләрне анализлау милли аңның төп компонентларын актуальләштерә, чөнки алар нәкъ менә әлеге мәдәнияткә хас булган милли реалияләрне атап киләләр. Милләт һәм халык категорияләре белән бәйле репрезентант сүзләрне тикшерү тел вәкилләренең аларга нинди мәгънә салганлыгын ачыкларга һәм *милли, нәсел, иман* төшенчәләренең ни рәвешле идентификацияләнгәнен аңларга ярдәм итә. *Туган* төшенчәсенең асылын ача торган идентификатор сүзләрне анализлау тел вәкилләренең нәрсәне үз һәм нәрсәне чит дип санауларын белергә мөмкинлек бирә. Югары ешлыклы сүзләрне тикшерү ассоциатив сүзләр арасында аеруча еш очрый торган һәм шул рәвешле алар арасында бәйләнешләр булдыра торган, ассоциацияләрнең нигез сүзлек фондын тәшкил иткән лексемаларны ачыкларга булыша.

Гомумән алганда, татар теленең ассоциатив сүзлеге материалларын югарыда күрсәтелгән дүрт ысулга таянып анализлау татар теле вәкилләренең тел аңы үзәгендә *җан, туган, нур, өй, көч, кеше, ирек, җир, күңел, йорт* кебек нигез төшенчәләр урын ала дип әйтергә мөмкинлек бирә. Тикшерү барышында ирешкән нәтиҗәләр татар һәм башка тел вәкилләренең милли үзаңын өйрәнү ысуллары турындагы белемнәрне баета һәм милли аң үзәгенә кергән барлык лексемаларны, алар арасындагы бәйләнешләрне өйрәнүнең перспектив юнәлешләрен күзалларга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. *Боргоякова А.П.* Национально-культурная специфика языкового сознания хакасов, русских и англичан (на материале ядра языкового сознания): дис. … канд. филол. наук. М., 2002. 189 с.

2. *Васильева А.П.* Ядро языкового сознания якутов: структура и ключевые элементы // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2024. Т. 17. Выпуск 12. С. 4814–4819.

3. *Дмитрюк Н.В., Черкасова Г.И., Артыкбаева Ф.И.* Этноментальный феномен ядра языкового сознания: ассоциативные исследования в Казахстане // Вопросы психолингвистики. 2016. № 2 (28). С. 132–150.

4. *Залевская А.А.* Введение в психолингвистику: Учебник. 2-е изд. испр. и доп. М.: Российский государственный гуманитарный университет, 2007. 320 с.

5. *Золотова Н.О.* Ядро ментального лексикона человека как естественный метаязык: дис. ... д-ра филол. наук: 10.02.19. Тверь, 2005. 400 с.

6. *Караулов Ю.Н.* Показатели национального менталитета в ассоциативно-вербальной сети // Языковое сознание и образ мира. М., 2000. С. 67–72.

7. *Караулов Ю.Н.* Послесловие. Русский ассоциативный словарь как новый лингвистический источник и инструмент анализа языковой способности // Русский ассоциативный словарь: в 2 т. / Ю.Н. Караулов, Г.А. Черкасова, Н.В. Уфимцева, Ю.А. Сорокин, Е.Ф. Тарасов. Т. I. От стимула к реакции: Ок. 7000 стимулов. М.: АСТАстрель, 2002. С. 245–249.

8. *Рогожникова Т.М., Кочетова Г.Р.* Ассоциативная цветность звуков башкирского и татарского языков // Вестник Башкирского университета. 2012. Т. 17. № 3. С. 97–101.

9. *Сергиева Н.С.* Хронотоп жизненного пути в русском языковом сознании: дис. ... д-ра. филол. наук. М., 2010. 400 с.

10. *Тарасов Е.Ф.* Актуальные проблемы анализа языкового сознания // Языковое сознание и образ мира. М., 2000. 203 с.

11. *Уфимцева Н.В.* Системность языкового сознания носителя языка как отражение системности культуры // Русский язык за рубежом. 2011. № 4. С. 79–83.

12. *Ушакова Т.Н.* Понятие языкового сознания и структура рече-мысле-языковой системы // Языковое сознание: теоретические и прикладные аспекты. М.; Барнаул. 2004. С. 6–19.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Лутфуллина Гөлнара Фирдәвис кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт энергетика университетының чит телләр бүлеге мөдире*

***Лутфуллитна Гюльнара Фирдависовна,***
*доктор филологических наук, профессор, заведующий кафедрой иностранных языков Казанского государственного энергетического университета*

*gflutfullina@mail.ru*

УДК 811.512.145

***Р.Т. Сәфәров***

# АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕКНЕҢ МИКРОСТРУКТУРАСЫН ПАРАМЕТРИЗАЦИЯЛӘҮ ПРИНЦИПЛАРЫ

Статья посвящена актуальным проблемам параметризации и унификации микроструктуры словарной статьи в татарской толковой лексикографии. На основе анализа современных татарских толковых словарей выявляются существующие пробелы и неточности в представлении грамматической информации о заглавном слове, в частности, для глаголов. Основное внимание уделяется разработке принципов заполнения грамматической зоны словарной статьи. Автор предлагает конкретные схемы подачи грамматических параметров глагола, включая формы инфинитива, повелительного наклонения, отрицательной формы инфинитива, а также форм 3-го лица настоящего и будущего времени изъявительного наклонения с указанием места ударения. Поднимается вопрос о необходимости указания управления глаголов и включения в грамматическую зону отдельных деепричастных и других неизменяемых глагольных форм. Предложенные принципы направлены на стандартизацию и совершенствование будущих толковых словарей татарского языка, что будет способствовать повышению качества лексикографических работ и адекватному отражению грамматического строя языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикография, толковый словарь, микроструктура, словарная статья, грамматическая зона, параметризация, глагол.

The article is devoted to the actual problems of parameterization and unification of the microstructure of a dictionary entry in Tatar explanatory lexicography. Based on the analysis of modern Tatar explanatory dictionaries, existing gaps and inaccuracies in the presentation of grammatical information about the capital word, in particular, for verbs, are identified. The main focus is on developing principles for filling in the grammatical area of a dictionary entry. The author suggests specific schemes for presenting grammatical parameters of the verb, including forms of the infinitive, imperative mood, negative form of the infinitive, as well as forms of the 3rd person of the present and future tense of the indicative mood, indicating the place of stress. The question is raised about the need to specify the control of verbs and the inclusion of certain adverbial and other unchangeable verb forms in the grammatical zone. The proposed principles are aimed at standardizing and improving future explanatory dictionaries of the Tatar language, which will help improve the quality of lexicographic works and adequately reflect the grammatical structure of the language.

**Keywords:** Tatar language, lexicography, explanatory dictionary, microstructure, dictionary entry, grammatical zone, parametrization, verb.

Моннан алда басылып чыккан хезмәтебездә [7] татар теленең аңлатмалы сүзлекләре микроструктурасының вокабула, фонетик һәм этимологик характеристика кебек төп зоналарында очрый торган проблемаларга анализ ясалган иде. Бу мәкаләдә исә сүзлек мәкаләсенең башка төп элементларын тасвирлауны бер системага

салу һәм унификацияләнгән параметрлар булдыруны тикшерү үзәккә куела. Максатыбыз – фактик материалны комплекслы анализлау, татар теленең киләчәктә төзеләсе сүзлекләрен стандартлаштыруга һәм камилләштерүгә юнәлдерелгән принциплар эшләү.

Проблемаларны ачыклау өчен, тикшерү объекты буларак: 1) 1977, 1979, 1981 елларда басылып чыккан өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (алга таба – АС3); 2) 2005 елгы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (АС1); 3) 2013 елгы «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» (МАС); 4) 2015–2021 елларда нәшер ителгән алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (АС6) һәм шуның 2020–2024 елларда басылып чыккан икенче басмасы алынды.

Универсаль, тел берәмлеге турында максималь дәрәҗәдә тулы мәгълүматны үз эченә алган сүзлекне В. В. Дубичинский *инвариант сүзлек* дип атый [2: 107]. Галим фикеренчә, мондый сүзлекнең сүзлек мәкаләсе 1) баш сүз, 2) аның фонетик тасвирламасы, 3) аның грамматик тасвирламасы, 4) семантизациясе, 5) баш сүзнең башка сүзләр белән бәйләнеше, 6) баш сүзнең сүзьясалыш мөмкинлекләре, 7) этимологик белешмә, 8) иллюстратив белешмә (лексикографик иллюстрация), 9) лексикографик тамгалар, 10) энциклопедик мәгълүмат һәм 11) сылтамалардан гыйбарәт булыр иде [1: 56–57].

Мәкаләбездә югарыда саналган сүзлек мәкаләсе зоналарының татар теленең аңлатмалы сүзлекләре өчен актуаль булган грамматик тасвирламага тукталабыз.

Грамматик зонада грамматик характеристика, ягъни баш сүзнең төп морфологик сыйфатлары турында мәгълүмат китерелә [10]. Төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә дә грамматик зонага игътибар үтә аз бирелә, күп очракта ул гомумән төшереп калдырыла. Без карый торган сүзлекләрдән МАСта гына мондый зона бар, һәм анда исемнәр өчен баш сүзнең юн. килеше, чыг. килеше һәм тартымлы формасы; сыйфатларның кайберләренә чагыштыру формасы; фигыльләр өчен хәзерге заман 3 нче зат формасы, *-ау/-әү* дип бетә торган фигыльләрнең боерык бормасы күрсәтелгән:

**СИРТМӘ** (-гә; -дән; -се) *ис.* <...>
**ТИСКӘРЕ** (-рәк) *сф.* <...>
**ҮГИСЕТ|Ү** (-ә) *фг.* <...>
**ЯУЛ|А́У** (-а; -ый) *фг.* <...>

Башка аңлатмалы сүзлекләрдә грамматик мәгълүмат фрагментар рәвештә санаулы берничә сүз өчен генә бирелгән:

**УЛ** II (аның, аңа, аны, аннан, анда) <...> [АС3, 3 т., 306].
**ТАНУ (ТАНЫ-)** *фг.* <...>
**ТАНУ (тан, тана, танар, таначак)** II фг. <...> [АС1: 514].
**ТАШУ** I *ф.* (таш, таша, ташар, ташачак) <...>

**ТАШУ** III *ф.* (ташы, ташый, ташыр, ташыячак) <...> [АС6, 5 т., 414–415].

Тулы типтагы татар сүзлекләрендә әлеге грамматик зонаның эшләнмәве зур кимчелек һәм татар теленең структурасын һәм функцияләрен тулысынча ачуга комачаулый торган актуаль проблема дип саныйбыз. Аерым сүзләрнең төрләнеш үзенчәлекләрен ачыклау өчен бары тик сүзлекләр генә төп чыганак вазифасын үти. Шуңа күрә бу зонаны булдыру лексикографик хезмәтләрнең сыйфатын арттыруга ярдәм итә торган этап буларак күзаллана.

Грамматик зонага татар лексикасының грамматик аспектлары ягыннан мөһим саналган һәр сүз төркеме өчен аерым грамматик характеристикаларны кертү максатка ярашлы булыр иде. Мәкалә күләме чикле булганлыктан, без фигыль сүз төркеменә генә тукталабыз.

1. Фигыльләрнең кушымчалары нигезнең калын/нечкә, тартык/сузык һәм шулай ук сонор авазга (һәм шул авазны белдергән хәрефкә) бетүгә бәйле. Димәк, сүзлектә сүзнең төрләнешен аңлау һәм вариантлы очракларның кайсын сайлауны аңлатырлык дәрәҗәдә берничә кушымча бирелә ала. Кайбер сүзләрдә кушымча түгел, сүзнең соңгы өлеше, аерым очракларда (бер иҗекле сүзләр) тулысынча бирелергә дә мөмкин.

«Татар теленең орфографик сүзлеге»ндә фигыльләр исем фигыль формасында бирелә, шул ук мәкаләдә боерык фигыль, билгеле үткән заман хикәя фигыль, хәзерге, киләчәк заман хикәя фигыль формалары, инфинитив формасы һәм исем фигыльнең 3 нче зат тартымлы төрләнеше күрсәтелә:

**а|ву**, -у, -уды, -ва, -вачак, -варга, -вуы
**бө|гү**, -к, -кте, -гә, -гәчәк, -гәргә, -гүе
**би|ю**, -е, -еде, -и, -еячәк, -ергә, -юе
**кайт|у**, ~, -ты, -а, -ачак, -ырга, -у [12: 7]

«Татар теленең орфоэпик сүзлеге»ндә фигыльләр инфинитив формада бирелә. Фигыльләр парадигмасыннан боерык форма, хикәя фигыльнең хәзерге һәм киләчәк заман формаларының 3 нче зат берлек саны күрсәтелә:

**искерергә́**,
искéр, искерә́, искерәчә́к [13: 10]

Безнеңчә, аңлатмалы сүзлектә фигыльләрне орфоэпик сүзлек үрнәгендә бирү уңышлырак булыр иде. Баш сүзне инфинитив формада бирү аның фигыль булуын күрсәтеп тора, димәк *ф.* яки *фг.* кебек сүз төркемен билгеләгән тамганың кирәге калмый. [6: 164] Шулай ук *көтү, сайлау, чигү* кебек сүзләрне элекке сүзлекләрдәге кебек омоним итеп бирүдән азат итә. Инфититив форма күп кенә бер иҗекле фигыльләрнең орфографиясен ныгытырга ярдәм итә [9: 368].

Моннан тыш, сүзлекләрдә инфинитивның юклык формасына игътибар бирелми. Ул – тамырны төгәл билгеләргә ярдәм итә торган формант. Югарыдагы ортологик белешмәлекләр тәҗрибәсен күз уңында тотып, аңлатмалы сүзлектә фигыльләр өчен түбәндәге сүзформаларны китерү җитәрлек булыр иде (кызганыч, бу мәсьәләдә һәр сүзлектә кабатлана торган бер типтагы грамматик характеристикалар традициясенә таяна алмыйбыз):

а) лемма итеп барлык формасындагы инфинитив һәм шуннан соң баш сүзнең тутырып язылган боерык формасы;

ә) шул боерык формадан соң вертикаль сызык аша инфинитивның юклык формасы кушымчасы;

б) хәзерге заман хикәя фигыльнең 3 нче зат кушымчасы;

в) киләчәк заман хикәя фигыльнең 3 нче зат кушымчасы. Мәсәлән:

**кагылырга́**, кагыл|маска́, -а́, -ача́к
**укырга́**, укы|маска́, -й, -яча́к

Әгәр дә сүзформалар тәкъдим ителгән калыпка сыймаса, һәр очракны аерым карарга, кирәк булганда кушымчаларны гына түгел, сүзләрне тутырып язарга да мөмкин:

**сөяргә́**[1], сөй|мәскә́, сөя́, сөячә́к
**сөяргә́**[2], сөя|мәскә́, сөйи́, сөяячә́к
**үтәргә́**[1], үт|мәскә́, -ә́, -әчә́к
**үтәргә́**[2], үтә|мәскә́, -и́, -ячә́к

Грамматик зонада басымның соңгы иҗеккә күчүен яки күчмәвен күрсәтү акцентология мәсьәләсен хәл итә:

**и́ндексларга**, и́ндексла|маска, -ы|й, -ячак
**культива́цияләргә**, культива́цияләргә|мәскә, -ли, -ячәк

2. Татар аңлатмалы сүзлекләренең берсендә дә фигыль башкарылышы күрсәтелмәгән. Мәгәр сүзлекләрдә фигыль башкарылышы турындагы мәгълүмат фигыльләрне сөйләмдә дөрес куллану өчен кирәк. Фигыль башкарылышы конкрет фигыльләрнең нинди килеш таләп итүен һәм алар белән бергә нинди бәйлекләр кулланылуын күрсәтә. Бу сүзләрне бер-берсе белән бәйләгәндә һәм җөмләләр төзегәндә хата җибәрмәскә ярдәм итә. Игътибарыгызга кайбер фигыльләрнең башкарылышында төрлелекне һәм мәсьәләнең җитдилеген күрсәткән берничә мисал тәкъдим итәбез (җөмләләр корпуслардан алынды).

**Нәфрәт итәргә**: *Күрәсезме?! – Сезгә нәфрәт итеп, Көлә-көлә, кылыч сайлыйбыз!* (Һ. Такташ). *Татар теле дәресләрен, татарлар**ны** нәфрәт итәм дигән сүзләрне ишеткәнем булмады* (Самара татарлары яңалыклары).

**Нәфрәтләнергә**: *Җәлил Сәлимне бер «идея»ле кеше ясый алмаса да, ул фәкать үзең өчен генә тырышу фикерен**нән** бер төрле нәфрәт-*

*ләнә, аны бик ваклык күрә башлады* (Г. Ибраһимов). *Башка кызны Алтынчәч гаепләр иде, ә үзен ул гаепләп кенә калмый, үз тәнен**ә** үзе нәфрәтләнә!* (М. Маликова).

**Идарә итәргә**: *Шул рәвешле, икътисадны һәм дәүләт**не** идарә итүнең Ленин заманындагы алымнарын тергезүнең чираттагы омтылышы ясала* (Б. Солтанбәков, «Казан утлары»). *Нindидер рухи көч һәм кодрәт аның **белән** идарә итә башлады* (Ф. Яхин).

**Зарланырга**: *Капкорсак патшаның атасын**нан** яки үзен**нән** зарланмыйсыңмы?* (А. Алиш). *...алар көн мәшәкатьләре, эштәге тоткарлыклар **хакында** зарланыштылар (*А. Вергазов). *Шәхси тормышы**на** да зарланмый яшәде* (А. Хәйртдинова).

**Шикаять итәргә**: *Казанда Пески урамында яшәгән халык якындагы «кызыл фонарьлар» шау-шуын**нан**, исерекләр**дән**, гаугалашлар**дан** тәмам туеп, җирле хакимиятләр**гә** күп тапкырлар шикаять иткән* (А. Тимергалин). *Муллаң **өстеннән** шикаять итеп йөрүнең ничек икәнен танытыйм әле* (Т. Гыйззәт). *Моңа «Төрек сүзе» гәзите дә игътибар итә: «Шималь төрекләре – татарлар... яңа пьесаларның юклыгы**на** шикаять итәләр»* (Т. Әйди).

Мисаллардан күренгәнчә, фигыльнең башкарылышы кулланучыда сораулар тудыра, сүзлекләрдә аларга игътибар җитенкерәми. Юкса сүзлекләр нәкъ шундый кыен очракларда төп ярдәмче ролен үти һәм үтәргә тиеш.

«XXI гасыр рус теле сүзлеге» проектында ияртүле бәйләнешнең һәр очрагы аерым каралган, башкарылышлары туры килмәгән һәр аерым мәгънәнең нинди килеш яки нинди предлог таләп итүе күрсәтелгән. Мәсәлән:

**встрево́жить,** жу, жишь, *св; кого, что;*

**дари́ть** <...>

**1.** *кого, что кому.* Преподносить (в качестве подарка); отдавать безвозмездно. <...>

**2.** *чем. Устаревающее.* Перен. Удостаивать, награждать, одаривать. <...> [6: 185]

Безнеңчә, хәзерге татар аңлатмалы (һәм тәрҗемәле) сүзлекләрендә һәр фигыльнең, шул исәптән аерым мәгънәләрнең башкарылышы һичшиксез күрсәтелергә тиеш. Ярдәмлек буларак «Татар телендә сүзләр бәйләнеше сүзлеге»ннән файдаланырга мөмкин [3].

3. С.И. Ожегов белән Н.Ю. Шведованың гомумкулланыш лексиканы эченә алган «Рус теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә, әгәр булса, фразеологиядән (ромб арты зонасыннан) соң, булмаса, соңгы яки бердәнбер аңлатманың иллюстрациясеннән соң || билгесе белән яңа зона ачыла һәм анда баш сүз белән бәйле «некоторые разряды производных слов» бирелә. Мәсәлән:

**МЫТЬ**, мо́ю, мо́ешь; мы́тый; *несов.* **1.** *кого-что.* Очищать от грязи при помощи воды, воды с мылом, какой-н. жидкости.

*М. руки. М. посуду. Рука руку моет* (посл. о сообщниках в каком-н. неблаговидном деле). **2.** *что.* Добывать (обычно о золоте), промывая песок, землю. *М. золотой песок, самородки.* **3.** *что.* Обливать, окатывать; размывать. *Река моет берега.* || *сов.* **вы́мыть**, -мою, -моешь; -ытый (к 1 знач.) *и* **помы́ть**, -мо́ю, -мо́ешь; -ы́тый (к 1 знач.). || *возвр.* **мы́ться**, мо́юсь, мо́ешься (к 1 знач.); *сов.* **вы́мыться**, -моюсь, -моешься *и* **помы́ться**, -мо́юсь, -мо́ешься. || *сущ.* **мытьё**, -я, *ср.* (к 1 и 2 знач.), **мо́йка**, -и, *ж.* (к 1 знач.) *и* **помы́вка**, -и, *ж.* (к 1 знач.; спец.). || *прил.* **мо́ечный**, -ая, -ое (к 1 и 2 знач.). *Моечное отделение* (в бане). *Моечная машина* [5: 372].

Соңгы зонада бирелгән формалар (*вымыть, моечная, моечный, мойка, помыть*), кагыйдә буларак, шулай ук вокабула буларак та тәкъдим ителгән, һәм өстәмә мәгънәләре булмаса, алардан *мыть* сүзенә сылтама бирелгән [8: 24].

Шуңа охшаш мәгълүмат «XXI гасыр рус теле сүзлеге» проектында грамматик зонада баш сүздән соң ук тәкъдим ителгән. Анда беренче чиратта бөтен фигыльләрнең дә күптән кабул ителгән грамматик характеристикалары – хәзерге заман (несовершенный видтагы фигыльләр өчен) һәм гади киләчәк заман (совершенный видтагы фигыльләр өчен) берлек сан 1 нче һәм 2 нче зат формалары, шулай ук һәрвакыт видлары күрсәтелеп бара [6: 177]. Гомуми кагыйдәгә буйсынмыйча ясалган очракларда боерык фигыль формалары китерелә [6: 182]. Шулардан соң нигез үзгәрү, басым күчү, вариантлары булу белән гомуми кагыйдә нигезендә ясалмаган сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары бирелә:

**мочь**[1], могу́, мо́жешь, мо́гут <...> *прич. действ. наст.* могу́щий, ая, ее <...>;

**запере́ть**, пру́, прёшь <...> *деепр.* запере́в и за́перши <...> [6: 183].

Әлеге ике чыганакта рус теле белешмәлекләрендә грамматик формаларга зур игътибар бирелгәне ачык күренә. Безнеңчә, татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә мондый зона булдыру һәм шунда аерым формаларны кертү, баш сүз итеп бирелгән кайбер формаларны грамматик зонага күчерү – хәзерге татар гамәли лексикографиясенең актуаль мәсьәләләреннән берсе.

Ф.Г. Миңнуллин фикеренчә, *-гала/-гәлә, -(ы)штыр/-(е)штер, -(ы)мсыра/-(е)мсерә* кушымчалары белән башлангыч нигезләрдән семантик яктан аерылып торган принципиаль яңа фигыльләр ясалмый, бары тик башкарылу ысулы мәгънәсе генә белдерелә, шул сәбәпле мондый фигыльләрне («глаголообразования») сүзлекләргә кертүнең кирәге юк [4: 16]. Бу фикер белән килешкән хәлдә, хәзерге сүзлекләрдә мондый кушымчалы фигыльләрнең баш сүз буларак бирелешендә төрлелек барлыгын ассызыкларга кирәк. Мисал өчен, МАСта *боргалау, ергалау, өзгәләү, телгәләү, караштыру, йокымсырау, көлемсерәү* кебекләр баш сүз итеп бирелгән. Ни өчен *язгалау, сызгалау, баргалау, килгәләү* юк? Мондый системасызлык һәр сүзлектә

күзтелә. Мәгәр *-гала/-гәлә/-кала/-кәлә, -штыр/-штер/-ыштыр/-ештер, -ынкыра/-енкерә/-нкыра/-нкерә, -ымсыра/-емсерә/-мсыра/-мсерә* кушымчалары белән кулланылган фигыль формаларын эзлекле рәвештә грамматик зонада биреп барырга булыр иде.

«Татар грамматикасы»нда затланышсыз фигыльләрнең 13 формасы күрсәтелгән [11: 255–302]. Шулардан алтысы сыйфат фигыль, бише хәл фигыль. Сүзлектә бирелеш ягыннан нәкъ шул хәл фигыль формаларының кайберләре игътибарга лаек дип карыйбыз. Менә алар:

1) *-ып/-еп, -п* кушымчалы форма (юклык формасы *-мыйча/-мичә, -мый/-ми*): *юып, юмыйча, юмый* (*калдырма*);

2) *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы формасы (хәзерге татар әдәби телендә, гадәттә, кабатланып килә): *юа-юа* (*җитә* хәл фигыленә *-рак/-рәк* кушымчасы ялгана: *җитәрәк*);

3) *-гач/-гәч, -кач/-кәч* (юклык формасы *-магач/-мәгәч*): *югач, юмагач;*

4) *-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче* кушымчалы формалар: *юганчы;*

5) *-ышлый/-ешли* кушымчалы формалар, аерым фигыльләргә генә ялгана: *узышлый, барышлый, кайтышлый, үтешли.*

Ике чыгармадан тыш, башлыча, бу формалар хәзерге сүзлекләрдә чагылыш тапмый. Беренче чыгарма – *-ышлый/-ешли* кушымчалы формалар. Болар – чикле фигыльләр белән генә кулланыла ала торган кушымчалар, һәм ул фигыльләрнең барысы да диярлек АС6га баш сүз буларак кертелгән: *барышлый, кайтышлый, керешли, килешли, китешли, көтешли, менешли, торышлый, узышлый, үтешли, чыгышлый.* (Шулар рәтенә тагын корпустан *салышлый, төшешли* дигән ике сүзне өстәргә мөмкин.)

Икенче чыгарма – *-ып/-еп, -п* һәм шуның юклык формасы *-мыйча/-мичә, -мый/-ми* кушымчалы формалар. Аларның кайберләре рәвеш буларак баш сүз итеп сүзлекләрдә тәкъдим ителгән (*кистереп, ныгытып, абайламыйча, сорамыйча, икеләнмичә* һ. б. ш.). Әгәр дә бу кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр нигез сүзнең (фигыльнең) мәгънәләреннән тыш яңа мәгънә ясамаса, галимнәр андыйларны баш сүз итеп алырга нигез юк дип саный [14: 292]. *-ып/-еп, -п, -мыйча/-мичә, -мый/-ми* хәл фигыль ясаучы кушымчалар регуляр кушымчалар, аерым берничә очракны санамаганда (*каңгырап/каңгырып*), аларның ясалышы сорау тудырмый, шуңа күрә мондый формаларны грамматик зонада бирүнең кирәге юк кебек.

*-гач/-гәч, -кач/-кәч, -магач/-мәгәч* һәм *-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче* кушымчалары да – регуляр кушымчалар, тик алар ярдәмендә ясалган сүзләрдә басымның төрлечә булуын исәпкә алганда, мондый формаларны грамматик зонага кертү урынлы булыр иде. Чаг.: *юаргá – югáч, ләкин ю́магач, ю́ганчы.*

*-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы форма хәзер, башлыча, кабатланып килә торган парлы нигезләрдә генә очрый. Кайбер хезмәтләрдә аларны икеләтелгән хәл фигыльләр дип атыйлар һәм лексикализация

кичергән формалар дип саныйлар [14: 292]. Аларның сүзлекләрдә бирелешенә килгәндә, шулай ук бер система булмавы күренә. Мәсәлән, АС6да *бара-бара* баш сүз итеп оештырылган, *юа-юа, ашый-ашый, сөйләшә-сөйләшә* кебекләр гомумән берничек тә сүзлектә чагылмый. Мондый формаларның басым үзенчәлекләрен дә исәпкә алып, грамматик зонада бирү кулланучы файдасына гына булыр иде.

Шулай ук парлы нигез формаларыннан *тора-бара, абынасөртенә* кебекләр рәвеш буларак баш сүз булып килә, киләчәк заманның барлык һәм юклык комбинацияләреннән ясалган формалар (*белер-белмәс, әйтер-әйтмәс, чыгар-чыкмас, җитәр-җитмәс*) сүзлекләргә кертелми кала.

Фигыль буларак тотрыклы янәшә кулланыла торган кайбер нигезләр парлы рәвешләр ясый ала (*абына-сөртенә, атлый-йөгерә, аватүнә, кызарып-бүртенеп* һ. б. ш.) Аларны сүзлекләрдә, Ф.Г. Миңнуллин тәкъдим иткәнчә, парлы фигыль итеп бирү белән килешә алмыйбыз [4: 21]. Без телдә *уйнау-көлү, кыру-себерү* һ. б. ш. парлы фигыльләр юк дип карыйбыз һәм текстта боларны тотрыклы янәшә килә торган тиңдәш кисәкләр кебек бирүне дөресрәк дип табабыз. Шул сәбәпле мондый фигыль нигезле парлы рәвешләрне сүзлекләрнең грамматик зонасында бирү түгел, лөгатьлегенә чыгару үзен аклый һәм тулы типтагы сүзлектә чагылдыру мәҗбүри.

Югарыда санап үткән мәсьәләләр татар аңлатмалы лексикографиясенең хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары турында мөһим нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Татар теленең тулы типтагы аңлатмалы сүзлекләрендәге сүзлек мәкаләләренең микроструктурасын анализлау аларда грамматик мәгълүматны системалаштыру ягыннан кимчелекләр булуны күрсәтә. Төп проблемалардан берсе – сүзлек мәкаләсенең грамматик зонасын параметрлаштыруның бердәм принциплары булмау. Кулыбыздагы сүзлекләрдә фигыльләргә грамматик характеристика бирүнең фрагментар булуы күзәтелә, бу аларның мәгълүматлылыгын һәм норматив кыйммәтен сизелерлек дәрәҗәдә киметә. Фигыльнең төп грамматик формаларын күрсәтүнең стандартлаштырылган схемасы һәм фигыльнең башкарылышы турында мәгълүмат булмау мәсьәләсе аеруча кискен тора.

Тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган проблемаларны хәл итүнең конкрет юллары тәкъдим ителде. Фигыльнең леммасы өчен иң перспектив форма – инфинитив, аннан соң төп форма ясау параметрлары: боерык формасы, инфинитивның юклык формасы, хәзерге һәм киләчәк заманның 3 нче зат кушымчалары күзаллана. Сүзлек мәкаләсенә фигыльнең синтаксик башкарылышы турында мәгълүмат кертү кирәклеге аерым әһәмияткә ия.

Фигыль формаларын сүзлеккә кертү мәсьәләсенә игътибар сорала. Тикшерү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, даими һәм һәр фигыльдән ясала торган формаларны сүзлеккә алуның кирәге юк, ләкин гомуми

кагыйдәгә буйсынмыйча ясалган, басым регуляр булмаган очраклар нигез фигыльнең грамматик зонасында чагылдырыла ала.

Эшнең гамәли әһәмияте татар аңлатмалы сүзлекләренең микроструктурасын унификацияләү өчен конкрет тәкъдимнәр эшләүдән гыйбарәт. Тәкъдим ителгән параметрлаштыру принципларын гамәлгә ашыру татар телен лексикографик тасвирлау сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирәчәк. Бу татар академик лексикографиясен үстерү һәм аны хәзерге халыкара стандартлар дәрәҗәсенә ирештерү өчен нигез тудырачак.

**Әдәбият**


1. *Дубичинский В.В.* Лексикография русского языка: учеб. пособие. М.: Наука: Флинта, 2008. 432 с.

2. *Дубичинский В.В.* Микроструктура инвариантного словаря // Вестник Новосибирского государственного педагогического университета. 2014. № 4 (20). С. 107–113.

3. *Зарипова И.Ф.* Татар телендә сүзләр бәйләнеше сүзлеге: [2 бүл.] 1 бүл.: (А–Р). Уфа: БашДУның РНҮ, 2012. 222 б.; 2 бүл.: (С–Һ). Уфа: БашДУның РНҮ, 2013. 280 б.

4. *Миннуллин Ф.Г.* Глаголы татарского языка и их лексикографирование: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2003. 26 с.

5. *Ожегов С.И., Шведова Н.Ю.* Толковый словарь русского языка. 4-е изд., дополненное. М.: ООО «ИТИ Технологии», 2003. 944 с.

6. Проект «Словаря русского языка XXI века». Образцы словарных статей / Г.Н. Скляревская, И.О. Ткачева, М.Л. Сергеев [и др.] // Journal of Applied Linguistics and Lexicography. 2019. Т. 1, № 1. С. 136–311.

7. *Сәфәров Р.Т.* Аңлатмалы лексикографиядә сүзлек мәкаләсе зоналарын параметризацияләү проблемалары // Актуальные проблемы языкознания в свете современных научных исследований: сборник материалов Междунар. науч.-практ. конф. (20–21 октября 2025 г., Казань). Казань: ИЯЛИ, 2025. С. 326–333.

8. *Сәфәров Р.Т.* Берничә йөкләтү юнәлеше кушымчасы белән килгән фигыльләрнең сүзлектә теркәлеше // Фәнни Татарстан. 2023. № 3(39). Б. 21–25.

9. *Сәфәров Р.Т.* Сүзлекләрдә фигыльләрнең бирелеше // Национальные языки и межъязыковые процессы в современном мире: материалы Международной науч.-практ. конф., посвящ. 85-летию создания Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. 9–10 октября 2024 года. Казань: ИЯЛИ, 2024. С. 367–372.

10. Структура словаря. URL: https://lab314.brsu.by/kmp-lite/kmp2/OTT/tLecture/tDictEntry.htm (дата обращения: 15.09.2025).

11. Татар грамматикасы: өч томда. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

12. Татар теленең орфографик сүзлеге / А.Ә. Тимерханов, Р.Т. Сәфәров, Ф.И. Таһирова һ. б.; фәнни мөх-р Г.Р. Галиуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 560 б.

13. Татар теленең орфоэпик сүзлеге / Р.Т. Сәфәров, А.Ә. Тимерханов, О.Н. Галимова; фәнни ред. Р.Т. Сәфәров. Казан: ТӘһСИ, 2019. 156 б.

14. *Улаков М.З.* Принципы отбора и размещения изолированных форм в словарях тюркских языков / М.З. Улаков, Б.А. Мусуков, Г.Р. Абдуллина // Мир науки, культуры, образования. 2023. № 5(102). С. 290–293.

## Чыганак сүзлекләр

АС3 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.

АС1 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005.

МАС – Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.

АС6 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: алты томда. Казан: ТӘһСИ, 2015, 2016, 2017, 2018, 2019, 2021; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: алты томда. Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020, 2020, 2021, 2022, 2023, 2024.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

***Сафаров Ринат Тагирович,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник, заведующий отделом лексикографии Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*safar.rinat@yandex.ru*

УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева***

# ТАТАР СОВЕТ ПРОЗАСЫ: ТӨП ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

В данной работе исследуется советский этап развития татарской литературы как целостный исторический отрезок. Объективная оценка исторического наследия, в особенности переосмысление советской литературы, представляет собой одну из актуальных задач современности. Целью исследования является определение ключевых направлений развития татарской прозы в советскую эпоху. Автор, рассматривая литературный процесс в неразрывной связи с историческими катаклизмами, пережитыми страной, выделяет три ключевых этапа в эволюции татарской советской прозы: 1917–1940, 1941–1955 и 1960–1980 годы. Исследование ведется в контексте трансформации оппозиции «мы-они», проявившейся в тематических новациях и возрождении художественных традиций национальной литературы.

В заключении утверждается, что, несмотря на значительное идеологическое влияние, характерное для советского времени, татарская проза смогла сохранить свою гуманистическую направленность и национальную самобытность.

**Ключевые слова**: татарская литература, проза, соцреализм, роман, повесть, рассказ, главный герой.

This article examines the Soviet period in the development of Tatar literature as a holistic historical period. An objective assessment of the historical legacy, particularly a reinterpretation of Soviet literature, is one of the pressing challenges of our time. The aim of the study is to identify key areas of development in Tatar prose during the Soviet era. The author, examining the literary process inextricably linked to the historical upheavals experienced by the country, identifies three key stages in the evolution of Tatar Soviet prose: 1917–1940, 1941–1955, and 1960–1980. The study is conducted within the context of the transformation of the “us-they” opposition, manifested in thematic innovations and the revival of artistic traditions in national literature. The conclusion asserts that, despite the significant ideological influence characteristic of the Soviet era, Tatar prose managed to preserve its humanistic focus and national identity.

**Keywords:** Tatar literature, prose, socialist realism, novel, story, short story, protagonist.

Соңгы еллардагы иҗтимагый-сәяси шартлар совет әдәбиятының идеологик, эстетик һәм тарихи әһәмиятен билгели. Кызганычка каршы, 1990 еллардан башлап татар совет әдәбиятының күпчелек өлеше фәнни өйрәнүдән читтәрәк кала бирә. Әлеге чор прозасы социалистик реализмның тар чикләренә сыешмый һәм аның үсеше СССР-ның башка милли әдәбиятларында барган процессларны кабатламый. Ул үткән буын татар язучыларының традицияләренә таянып, аларны

яңартып үсә, шуның белән татар әдәбиятының милли үзенчәлекләрен саклауга һәм ныгытуга ирешә.

Советлар иле кешелек тарихына уникаль күренеш буларак кереп калды. Әлеге чорның әдәбияты да катлаулы үсеш тенденцияләре кичергән, берьяклы гына аңлатып булмый торган үзенчәлекле мирасны тәшкил итә. «Художественное развитие вообще и развитие эпических жанров в частности в 1920–1950-х годах шло не только согласно логике эстетических законов. Оно испытывало давление политических и идеологических факторов и обнаруживает известную синхронность с процессами, которыми была отмечена общественно-политическая жизнь советской эпохи» [21: 3]. Барыннан бигрәк ул күпмилләтле булуы һәм, үзәктән килгән бертөрле басым астында иҗат ителүгә карамастан, һәр милли әдәбиятның үз үсеш закончалыклары нигезендә үсүе белән кызыклы.

## Татар совет әдәбияты формалашу (1917–1930)

Татар әдәбияты Октябрь революциясенә үзенең алтын чорында алдагы буыннарга камертон булып торачак классик әсәрләре белән килеп керә. Дистә гасыр дәвамында шәркый традицияләрдә формалашкан, XIX–XX гасырлар чигендә милли юнәлешен ачыклап, рус һәм Европа мәдәнияте йогынтысында баеп, яңа сулыш белән үсеш алган әдәбият өчен инкыйлаб чын мәгънәсендә җимергеч афәт булып чыга. Дөрес, самодержавие бетерелү милли-социаль азатлыкка, демократиягә китерәчәк, дип ышанган татар язучыларының күбесе революцияне хуплап каршы ала. Әмма большевикларның илдә пролетариат диктатурасы урнаштыруы әлеге идеяләрне юкка чыгара.

Илдәге үзгәрешләр язучыларны төрле мәсләкләргә аера. Инкыйлабны кабул итмәүчеләрнең берничәсе чит илгә китә, хуплап каршы алучыларның да күбесен алга таба фаҗигалы язмыш көтә.

Әдәбиятта инкыйлабны гомумкешелек идеалларын тормышка ашыручы итеп күрсәтү башлана. Милли нигезле «без – алар» каршылыгы социаль хәлгә карап аерылып, яңадан корыла. Сыйнфый көрәш идеясе алга чыга. Кыйммәтләр кискен алмашына. Искелек белән яңалык көрәшенең эчтәлеге үзгәрә: инкыйлабка кадәр ул аңбелем, мәгърифәтлелек белән бәйле булса, аннан соң милекчелек, динилек, миллилек искелек калдыгы буларак күрсәтелеп, нәфрәт яисә көлү объектына әверелә.

Совет чоры әдәбиятының беренче еллары Гражданнар сугышы чорына туры килә. Проза әсәрләрендә реалистик сурәт сугыш романтикасы белән кушыла. Инкыйлабны танылган язучы, галим һәм милли лидер буларак каршылаган Г. Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр» повестенда (1922) Гражданнар сугышы чоры вакыйгаларын сурәтли: бер авылда туып, уйнап үскән, төрле социаль катлаудан булган биш татар егетен язмышның төрле якларга ташлавы турында яза.

Якты киләчәккә ышанган төп герой Солтан: «Мин көрәшне яратам. Көрәшсез үткән көннәрне әрәмгә саныйм. Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным рәхәтләнә, йөрәгем үзенә көч ала, гайрәт ала» [14: 75], – ди.

Г. Ибраһимов персонажлары ике лагерьга бүленә: революцияне яклап көрәшүчеләргә (авыл крестьяннары уллары) һәм революцион үзгәрешләргә каршыларга (бай һәм мулла уллары). Татар тормышы, көнкүреше, этнографик детальләр (йорт төзелеше, көзге авыл хуҗалыгы эшләре, яшьләрнең кичке уеннары, туй уздыру) һ. б. күренешләр традицион ачкычта күрсәтелә; лиризм һәм символлар (кызыл чәчәкләр) шулай ук XX йөз башы татар прозасы белән охшашлык тудыра.

Повесть яңа шартларда проза үсешенең бер юлын ача: көрәш романтикасы, Гражданнар сугышы моңарчы сурәтләнгәнчә җимергеч көч итеп түгел, бәхет, хөррият, якты тормыш алып килүче итеп күрсәтелә башлый. Татарның көндәлек тормышын җентекләп сурәтләү һәм вакыйгаларга символик бәя бирү революциягә кадәрге традицияләр белән интертекстуаль бәйләнеш урнаштыра. Шулай итеп, татар прозасында яңачалык поэтик традицияләр белән үреп бирелә.

Гомумән, прозада чор картинасы тудырыла: Гражданнар сугышы, сыйнфый каршылык, яңа хакимиятне хуплау, халык массаларының киләчәккә якты өмете. Революция яклы кешеләр – уңай геройлар итеп, аңа каршылары дошман буларак күрсәтелә. Шәхси милеккә нәфрәт тәрбияләү шушы еллар әдәбиятыннан башлана. Күп очракта революцион аскетизм алгы планга чыгарыла. Ш. Усмановның «Краском мәхәббәте», «Ил кызы», «Югалган иман», «Замана агымы» кебек хикәяләрендә җитеш, тук, бәхетле гаилә тормышы инкяр ителеп, революцион көрәш хуплана. Киләчәк хакына гомерне бирү – барлык бәхетләрдән өстен куела. Мәхәббәт романтикасы революция темасы белән бергә бирелә. Боларда татар хатын-кызы образы үзгәрә, революционер-көрәшче хатын-кыз иҗат ителә.

20 нче еллар ахырыннан 30 нчы еллар уртасына кадәрге чор – Россия мәдәниятенең сүтелеп, яңадан корылган дәвере. Халыкның рухи тормышындагы үзгәрешләр аеруча әдәби даирәдә чагылыш таба. Башында Ленин, аннан Сталин торган пролетариат партиясе халык массаларына идеология үткәрүдә әдәбиятны төп корал итә. Татар җәмәгатьчелегендә дә пролетариат әдәбияты нинди булырга тиеш, дигән сорауга җавап эзләү башлана. Моңарчы булган әдәби кануннарны инкяр итеп, яңа формалар эзләү, үткәндәге мирасны кире кагу, яңа тормышны мактау тенденцион төс ала. Иҗатта социальләшү абсурд чигенә җитеп, вульгар социологизм күренеше барлыкка килә. Марксизм һәм ленинизм тәгълиматын һәрберсе үзенчә аңлаган иҗат әһелләре арасында фикер каршылыклары туа. Бу каршылыклар әдәби-тәнкыйди характерда булсалар да, алга таба язмышларын фаҗигалы хәлләргә илтүче сәбәпләргә дә әйләнәләр. Әлеге катлаулы 20–30 нчы еллар әдәби хәрәкәте Ф. Галимуллин хезмәтләрендә чагылыш

таба[1]. Галим үзенең «Татарская литература: взгляд сквозь столетия» («Татар әдәбияты: гасырлар аша караш») монографиясендә болай дип яза: «Литература советского периода, по определению самих теоретиков метода социалистического реализма, должна быть социалистической по содержанию, национальной по форме, на деле все сводилось к тому, что социалистическое содержание обретало вненациональный, абстрактный интернациональный характер. Для достижения этих целей были использованы различные надуманные обвинения в пантюркизме, джиганизме, султангалиевщине и др. В ходе борьбы с такими, якобы, проявлениями «измов» в литературе велась работа по постепенному вытеснению из искусства слова художественных средств, которые традиционно были присущи многовековой татарской письменной литературе» [6: 48].

Үзәк 20 нче еллар ахырында язучылар иҗатын контрольгә ала башлый. 20 нче еллар уртасында Казанда оешкан «Октябрь», «Сулф», «Завод», «Часовой» кебек әдәби берләшмәләрдәге язучылар иҗатын тикшереп тору кыенлаша. 1928 елда ТАПП (Татар пролетариат язучылары ассоциациясе) оеша һәм партия күрсәтмәләре нигезендә эш итә башлый. 1929 елда рус язучылары Евг. Замятин һәм Б. Пильняк үз романнарын чит илдә бастырып чыгаргач, аларны совет әдәбиятына һәм совет иленә корткычлык эшләүдә гаеплиләр. Шул вакыйгадан соң дәүләт рус һәм милли әдәбиятларда ачыктан-ачык башкача фикерләүчеләргә каршы көрәш ача. Укучы массага нисбәтләнгән һәр әдәби әсәр сәяси яктан тикшерелә башлый.

Иҗат методы мәсьәләсендә дә күп бәхәсләр була. Төрле иҗат юнәлешендә үскән татар әдәбияты алга таба иҗат методы буларак реализмны гына сайлый. 1934 елда Совет язучыларының I съездында әдәбиятның бердәм методы – социалистик реализм рәсми кабул ителгәч, әдәбиятта һәм сәнгатьтә советчыл миф тудыру дәвере башлана. «Аның беренче төп сыйфаты – чынбарлыкның, тарихның зур революцион борылышын һәм киң халык массаларының аңында, настроениеләрендә барлыкка килгән тирән үзгәрешне гәүдәләндерү» [23: 108] була.

Ләкин, яңа власть тема һәм проблематикага гына түгел, поэтикага да кагыла. Автор позициясен белдерүгә аеруча басым ясала. Мисал өчен, колхозлаштыру сәясәте башлангач, вакыйгаларның кайнар эзеннән Фатих Хөсни «Җир тыңлый» романын (1931) яза. Әмма китап кискен каршылыкка очрый: тиражы яртылаш таралуга, ТАПП әсәргә тәнкыйть яудыра башлый, матбугатта авторны гаепләп мәкаләләр язылa, китап укучылар конференцияләрендә авторны сүгәләр,

[1] *Галимуллин Ф.Г.* Соотношение эстетичного и социологического в татарской литературе 1920-30 годов: дис. ... д-ра филол. наук. Казань: КГУ, 1999. 444 с.; *Галимуллин Ф.Г.* Әле без туганчы...: 1920–1930 нчы еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 320 б.; *Галимуллин Ф.Г.* Табигыйлеккә хилафлык: XX гасырның 20–30 нчы еллар татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 303 б.; *Галимуллин Ф.Г.* Татарская литература: взгляд сквозь столетия. Казань: Школа, 2016. 295 с.

романга «сәяси яктан зарарлы, кулак идеологиясен яклап язылган» дип бәя бирәләр [18: 6]. Әсәрнең сыйнфый позициядән чыгып язылмавы төп кимчелек буларак карала, авторы революцион көрәшне аңламауда гаепләнә. Ф. Хөсни үз әсәреннән баш тартырга мәҗбүр ителә. Китапның рецензенты Сәгыйть Фәйзуллин җибәргән «хата»сы өчен гафу үтенгән һәм Ф. Хөснинең үз әсәрен кире каккан җан өшеткеч язмалары «Атака» журналында басыла [22].

Роман вакыт ягыннан бик кыска (1930 елның гыйнвары) араны колачласа да, зур масштабка ия, моның сәбәбе персонажларның күплеге һәм вакыйгаларның тыгызлыгы белән аңлатыла. Ф. Хөсни, 30 нчы еллар әдәбиятына хас булганча, геройларын «безнекеләр»гә һәм «аларныкылар»га аерып, схемачылык юлыннан китми, ә психологизм алымнарын оста кулланып, геройларын эчтән, рухи дөньялары аша ача. Шуңа аларның һәркайсының тормышка, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә үз карашлары, мөнәсәбәтләре бар.

Тормышны киң социаль панорамада чагылдыру, чор каршылыгын кешеләр язмышы аша тасвирлау, иҗтимагый проблемалар белән мәхәббәт сызыгын үреп бару, теленең җорлыгы белән Ф. Хөсни талантлы каләм иясе, проза остасы булачагын беренче романы белән үк күрсәтә. Әмма С. Хафизов язганча, «Фатих Хөснинең җорлыгы, юмористик сыйфатлары калды, башка әсәрләрендә дә дәвам иттеләр алар. Ләкин «Җир тыңлый»да ачык расланган кыюлык, хөр фикерлелек, гомумкешелек гуманизмы кебек мөһим талант сыйфатлары, кире кагылган романы кебек, фаҗигалы язмышка дучар ителделәр» [25].

М. Әмирнең укучыга аз билгеле романын да шуңа охшаш язмыш көтә. М. Әмир татар әдәбиятында хәрби теманың аз яктыртылуын искә алып, гади татар авылыннан чыккан егетнең командир дәрәҗәсенә ирешүен, характеры ничек чыныгуын, гомумән, аның катлаулы тормыш юлы турында зур күләмле әсәр язарга алына. Әлеге «Командир» дип атаган романының бер кисәге 1934 елда аерым китап булып басылып та чыга. Әсәр әдәби җәмәгатьчелектә каршылыклы фикер тудырганлыктан, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты җыелышында махсус тикшерелә, соңрак фикер алышу «Совет әдәбияты» журналында дәвам итә.

Роман Сәүбанның армиягә алыну хәбәре белән башланып китә. Әсәрнең күп өлешендә аның авырлыкта үткән балачагы, армиягә китү алды көннәре вакыйгалары сурәтләнә. Автор җанлы күренешләр, оста тотып алынган аерым детальләр аша 30 нчы еллар татар авылы картинасын тудыра.

Тәнкыйтьчеләр (Л. Җәләй һәм М. Максуд) романдагы «кимчелекләрне» язучының «политик ялгышуыннан» күрәләр. Алар, беренче чиратта, 1928–1929 еллар авылы фоны дөрес күрсәтелми, совет властеның йогынтысы сизелми, дип белдерәләр. Икенчедән, Кызыл армия артык караңгы бирелә, капитаннары да дөрес сурәтләнми, диләр. Шулай ук әсәрдә интернационализмның чагылмавы кимчелек

дип карала, ә инде командир Моратовның милли полк турында хыяллануы М. Әмирнең милли мәсьәләне ялгыш аңлавы, дип күрсәтелә. «Командир» романының авторы тормыш диалектикасын аңламауда һәм әсәрендә партиячелекне чагылдырмауда гаепләнә [11; 17]. Ф. Галимуллин билгеләвенчә, «сәнгатьчә дөреслеккә ирешүдә әһәмиятле баскыч булган әлеге роман М. Әмирнең характер мантыйгы буенча язылган иң уңышлы әсәрләренең берсе» [5: 33] була. Тар идеологик кысалар сәнгать әсәрен бәяләүдә хаталануларга китерә, язучыларның иҗади мөмкинлекләрен чикли.

Җәмгыятьтәге яңалыклар гаилә институтына да үзгәрешләр алып килә. Совет хатын-кызының нинди булырга тиешлеге турында кызу бәхәсләр бара. Тормышта хатын-кызның роле үзгәргән кебек, әдәбиятта да яңа тип татар хатыны образы барлыкка килә. 20 нче еллар прозасында сугышчан хатын-кыз алга чыкса, 30 нчы елларда иҗтимагый тормышта актив катнашучы эшлекле образ иҗат ителә. Татар әдәбияты казанышы – татар укучысының яраткан әсәре – «Тапшырылмаган хатлар»ны Гадел Кутуй 1935 елда яза. Повестьның уңышы – төп героиня Галиядә татар хатынының аналык сыйфатлары саклануда, шул ук вакытта яңа заман кешесе буларак, аның көчле характерлы булуында. Г. Кутуй социалистик реализм шартларында иҗат итсә дә, әсәрнең әлеге кысаларда гына калмавын, авторның һәр заман актуаль булып калган хатын-кыз бәхете мәсьәләсенә – аның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге урынын билгеләүдә классикларча эш итүен күрәбез.

Шулай итеп, татар совет әдәбиятының башлангыч чоры яңа идеологик карашларның һәм үткәннән килгән сәнгать традицияләренең үзара тыгыз бәйләнеше белән аерылып тора. Милли һәм иҗтимагый азатлык өчен мөмкинлек дип кабул ителгән инкыйлаб кырыс диктатурага әверелә. Гасыр башы татар прозасындагы традиционлек һәм прогресс тарафдарлары арасындагы оппозицияне күрсәткән «без – алар» каршылыклы структур конфликты яңа мәгънә ала һәм яңа социалистик тормыш өчен совет хакимияте дошманнарына каршы көрәшне белдерә башлый. Нәтиҗәдә, XX гасыр башындагы татар әдәбиятының «татар халкы язмышы» темасы яңа социалистик тормыш өчен көрәш темасына алыштырыла.

## Бөек Ватан сугышы һәм идеологик чикләүләрне җиңәргә омтылыш (1941–1955)

Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы еллар прозасы әдәбият тарихында үзе бер дәверне тәшкил итә. Бу чор әдәбиятында кешенең гайре табигый шартларда үз-үзен тотышына игътибар бирелә, сугыш Ватан һәм аерым шәхес алдына килгән әхлак вә намус сынавы буларак карала. Язучыларга инкыйлабка кадәрге татар әдәбиятының поэтик традицияләре белән иркенрәк эш итәргә мөмкинлек туа. Барыннан да бигрәк «без – алар» каршылыгының эчтәлеге үзгәрә: без – совет кешеләре, туган җир азатлыгы өчен көрәшүчеләр, алар – яулап алучылар. Бу исә совет кешесенең холкын тулырак ачарга ярдәм итә.

Сугыш чоры әсәрләренең төп объекты – тормышның авыр сынауларына карамастан, кешеләр арасындагы дуслык, туганлык, мәхәббәт, үзара ярдәмләшү, хөрмәт кебек матур мөнәсәбәтләрнең саклануын сурәтләү. Язучылар үз хикәяләрендә символларны һәм символик образларны актив куллана башлыйлар (1930 еллар ахырында бу әдәбиятчылар һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан хупланмый) һәм алар аша вакыйга-күренешләргә эмоциональ бәя бирәләр.

Мисал өчен, М. Әмирнең «Курай» (1943) очеркында һәм «Сыерчык» (1943) нәсерендә әсәрләрнең исеменә үк чыгарылган образлар – сугышның кирәксез һәм коточкыч күренеш булуын ачу өчен кулланылган махсус символик детальләр. Сугыш – сәнгатьнең, гүзәллекнең капма-каршысы. Алар яктысында сугышның аянычлылыгы тагы да ныграк чагыла.

Бөек Ватан сугышы елларында татар хикәясе сюжет-композиция ягыннан да, стиль ягыннан да алга китә. Монда аның оператив һәм җыйнак жанр булуы зур роль уйный һәм шулай ук патриотик максатларда милли символларны, традицион образларны кулланырга рөхсәт ителү файдага була. Н. Гыйззәтуллин билгеләгәнчә, «Бу еллардагы татар прозасында ачык билгеләнгән ике стиль юнәлеше күренде: беренчесе – героик характерны катлаулы вакыйгаларда күрсәтү һәм шушы максатларда сюжетны төп чара итеп куллану булса (мәсәлән, Г. Әпсәләмов хикәяләрендә), икенчесе – совет кешесенең сугыш елларындагы эчке кичерешләрен бөтен нюанслары белән бирергә, «кеше рухының диалектикасын» ачарга омтылудан гыйбарәт иде (Ә. Еники, Ф. Хөсни һ. б.)» [9]. Әлеге икенче юнәлеш психологик алымнар аша гуманистик идеяләрне алгы планга чыгара. Язучылар әдәбиятның үзәгендә кеше, аның язмышы, хис-кичерешләре торырга тиеш дигәнгә тугры калып, сугыш чоры хикәяләрендә сугышны кешелекне җимерүче афәт, ә кеше гомерен исә берни белән алыштыргысыз кыйммәт итеп күрсәтә. Шуңа без татар әдәбиятындагы 60 нчы елларда барлыкка килгән яңарышның яралгылары сугыш чоры әдәбиятында күренә башлый, дибез.

Фатих Хөснинең татар әдәбияты тарихында мөһим урын тоткан «Йөзек кашы» повесте (1942) Бөек Ватан сугышы чорында языла. Соңгы ике дистә елда әдәбиятның партиялелеге турында гына сөйләгәндә әсәр чын мәгънәсендә яңалык булып кабул ителә. Сайланган сюжет, аның белән тел-стиль, сурәтләү чараларының ярашуы, тирән психологизм, композицион бөтенлек һәм халыкчанлык – әлеге әсәрне сүз сәнгатенең гүзәл җәүһәрләре рәтенә куя. Барыннан да бигрәк төп герой Айдарның каршылыклы характер булуы әһәмияле. Ул – бер яктан, дуамал, алдын-артын уйламаучы бунтарь, икенче яктан, саф күңелле, эчкерсез һәм ярата белүче, батырлыкларга сәләтле егет.

Повестьның лирик башлангычка корылуы укучыны тирән хисләргә әзерли. Авылга алма сатучы килгән һәм бөтен тирә-юньгә алма исе таралган. Кечкенә Айдарның күңелен, алмасыннан бигрәк, алма сатучының кызы биләп ала. Кызчыкның малайга алма ыргытуы да

тикмәгә түгел: алма – матурлык, сафлык, сөю символы. Әсәр башындагы лирик күтәренкелек психологик киеренкелек белән алмашына һәм ахыргача шул халәт дәвам итә.

Бер караганда, Айдарның холкы, уйламыйча кылган эш-гамәлләре, сөйгәне Вәсиләне, якыннарын борчуга салуы нәфрәт кенә тудырырга тиеш кебек, әмма киресе – эчкерсезлеге, гаделсезлеккә аяусыз протесты, кыюлыгы, ил алдында батырлыклары өчен укучы аны ярата башлый. Бу аеруча аның капма-каршысы булган Госман образы белән чагыштыруда күренә. Кечкенәдән Айдарга карата аның күңелендә яшәп килгән көнчелек, хөсетлек хисе үсә барып, ул ике яшь йөрәкне аерып кына калмый, үзен дә аянычлы, хурлыклы үлемгә дучар итә.

Татар әдәбиятында геройларны уңай һәм тискәрегә аеру борынгы әдәбияттан ук килә, шулай ук мәгърифәтчелек һәм соцреализм әдәбиятында да өстенлек итә. Әдәбиятны тәрбия чыганагы итеп күргән һәм совет чорында идеология чарасы булуына күнеккән татар укучысы өчен Айдар – чыннан да ят герой. «Үрнәк булырлык язмышмы соң бу, диярләр миңа акыллы башлы тәнкыйтьчеләр. Алдан ук әйтәм, түгел. Киресенчә, аның күп кенә яклары минем үземә дә ошамый. Ләкин тормыш – шуның өчен дә тормыш ул, аның законнары минем яки синең кәеф белән генә исәпләшеп тора алмый. Әйе, тормышта Айдарлар да бар. Үрнәкме алар, түгелме? Ләкин андыйлар бар һәм, димәк, тормышның бүтән яклары белән бергә аларның да җырга кереп калырга хаклары бар» [26: 8], дигән сүзләрендә авторның гуманистик карашлары, кешегә партия карарларын үтәүче иҗтимагый продукт итеп кенә түгел, ә иң беренче чиратта шәхес итеп каравы күренә.

Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә» (1944) хикәясе туган авылы турысыннан эшелонда үтеп баручы Гомәрнең әти-әнисе, туганнары янына кереп чыгуы турында. Язучы хәрби егеткә бирелгән бер сәгать эчендә геройларының күңел кичерешләрен гаять оста психологик детальләрдә күрсәтә. Әсәрдә минутларның санаулы булуы укучыны киеренке халәткә көйли. Туганлык җепләре һәм мәхәббәт белән үзара бәйләнгән кешеләрнең мөнәсәбәтләрендәге күркәмлекләр ачыла. Кеше гомеренең мизгелләрдән генә торуы, яшәүнең татлы һәм кадерле булуы милли җирлектә, образларда күрсәтелә.

Шулай итеп, сугыш әдәбиятка психологизмны һәм милли образларны кайтара, гуманистик идеяләрне алгы планга чыгара. Шулай ук әлеге чорда проза характер тудыруда яңа үргә күтәрелә.

Сугыштан соңгы елларда сәяси-иҗтимагый тормышта кискен үзгәрешләр булмый, киресенчә, сугышка кадәрге чикләүләр кире кайта, иҗади интеллигенциягә контроль кырыслана. «С окончанием Великой Отечественной войны кратковременное послабление нормативной концепции в словесном искусстве, которое было возможно в условиях суровой военной действительности, вновь стало неактуальным в рамках доминирующей в литературе монистической

концепции» [19: 201]. Монда сугышның төп тема булып калуын да билгеләргә кирәк. Шуңа әлеге 10 ел (1945–1955) вакыт аралыгын сугыш чоры әдәбиятына кертеп карау гадәткә кергән.

Тыныч тормыш зур полотнолы әсәрләр язарга мөмкинлек бирә: роман һәм повесть жанрлары үсеш ала. Г. Бәшировның «Намус» (1948), Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» (1948), «Газинур» (1950), Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» (1945–1957), К. Нәҗминең «Язгы җилләр» (1948), Ә. Фәйзинең «Тукай» (1950) романнары, М. Әмирнең «Саф күңел» (1954–1959) дилогиясе, И. Газинең «Онытылмас еллар» (1949–1966) трилогиясе шул елларда языла. Әсәрләрдә халыкның җиңелмәс рухы, хәрби батырлыклар, тыл тормышы михнәтләре, тарихи-революцион үткәне, кеше язмышлары, сугыштан соңгы авыл тормышы сурәтләнә. Соцреализм төп принцип булып торса да, прозаиклар тормыш материалын киң планда яктыртырга омтылалар.

Көчле идеологик басым дәверендә татар халкының үткәне турында тискәре фикер булдыру, Казан ханлыгы алынуны прогрессив күренеш буларак бәяләү, Көнчыгышның татар әдәбиятына булган йогынтысын киметеп күрсәтү кире кайта, инкыйлабка кадәрге бик күп әдипләр иҗаты халыктан яшерелә, рус мәдәнияте тәэсире күрсәтелмәгән әсәрләр буржуаз милләтчелектә гаепләнә. Бу чорда «без» совет халкына караса, «алар» дигәндә, халыкның тискәре мәгънәдәге үткәне күздә тотыла. Кабаттан 1930 елларда интернационализм принцибы кысаларында барлыкка килгән совет җәмгыяте схематизмы популярлаша. Язучылар бүгенге тормыш, күбрәк җитәкче коммунист герой турында язарга тиеш булалар. Әмма 1950 еллардан башлап, Ә. Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр» (1952), Ф. Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» (1953), Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» (1957), «Йолдызым» (1960) кебек повестьлары партияле җитәкче мәсьәләсен күтәрсәләр дә, кеше җанының тирән төпкелләренә үтүләре, гади кешенең шәхси бәхете турында булулары белән әһәмиятле.

Гомумән алганда, Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы еллар прозасы татар әдәбияты үсешендә мөһим этап булып тора. Сугыш, бер яктан, халык өчен фаҗигалы сынау булса, икенче яктан, сәнгать чараларын һәм рухи кыйммәтләрне аңлауны һәм кире кайтаруны тизләтүче дә була. Язучылар, замандашларының батырлыгын, хәсрәт һәм өметләрен сурәтләргә омтылып, әдәбиятны психологизм, символик детальләр һәм милли образлар белән баеталар. Сугыштан соңгы чор идеологик чикләүләренә карамастан, татар язучылары кешенең рухи халәтен ачуга нигезләнгән әсәрләр иҗат итү юлларын эзлиләр. Тора-бара социалистик реализм призмасы аша гади кешенең шәхси бәхетен сурәтләү омтылышы барлыкка килә. Бу татар прозасының алга таба үсешенә юл ача: авырлыкларга карамастан, ул милли үзенчәлеген һәм гуманистик юнәлешен саклап калуга ирешә.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

1. *Ахмеров З.С.* Воспитывать атеистов. Из опыта работы школ Татарской АССР. М., 1962.

2. *Балтанов Р.Г.* Утверждение коммунистической нравственности и борьба с пережитками морали ислама: автореф. дис. ... канд. филос. наук. Казань, 1963.

3. *Бәширов Г.* Туган ягым – яшел бишек: повесть // Бәширов Г. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 2 т. 452 б.

4. *Гайнуллина Г.Р.* XX гасырның 60–70 нче елларында татар автобиографик прозасы үсеше. Казан: Ихлас, 2012. 107 б.

5. *Галимуллин Ф.* Реализммы, романтизммы? // Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 321 б.

6. *Галимуллин Ф.Г.* Татарская литература: взгляд сквозь столетия. Казань: Школа, 2016. 295 с.

7. *Галлямова Г.А.* Татарская АССР в период постсталинизма (1945–1985 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 455 с.

8. *Ганиева А.Ф.* Архетип матери-хранительницы национальной идентичности в татарской прозе // Вестник Удмуртского университета. Серия История и филология. Т. 32. 2022. № 3. С. 623–629.

9. *Гыйззәтуллин Н.* Хикәяләр остасы // Социалистик Татарстан. 1967. 30 апр.

10. *Еники Ә.* Саз чәчәге // Ә. Еники. Әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 2 т.: повестьлар. 447 б.

11. *Җәләй Л.* Киң җәймәдәге таплар // Совет әдәбияты. 1934. № 9. Б. 81–89.

12. *Заһидуллина Д.Ф.* Караш җитмәсне колачлаган әдип // Чын мирас. 2013. 3 март. Б. 91–98.

13. *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

14. *Ибраһимов Г.* Кызыл чәчәкләр // Әсәрләр: 15 томда. 3 т.: хикәя, повестьлар, роман, драма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 422 б.

15. *Колоницкий П.Ф.* Мораль коммунистическая и мораль религиозная. М., 1952.

16. *Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н.* Современная русская литература: 1950–1990-е гг.; пособие для студ. высш. учеб. заведений: в 2 т. Т. 2. 1968–1990. М.: Изд. центр «Академия», 2003. 688 с.

17. *Максуд М.* Тагын «Командир» романы турында // Совет әдәбияты. 1935. № 7. Б. 85–89.

18. Матур әдәбият фронтында кулак идеологиясенә каршы // Атака. 1931. № 5–6. Б. 6.

19. *Надыршина Л.Р.* Поэма в татарской литературе XX века. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. 2022. 352 с.

20. *Сафина А.М.* Национальный характер в татарской исторической прозе (вторая половина XX века): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2010. С. 11.

21. *Скороспелова Е.Б.* Русская проза XX века: от А. Белого («Петербург») до Б. Пастернака («Доктор Живаго»). М.: ТЕИС, 2003. 420 с.

22. Фатих Хөсни иптәшнең белдерүе // Атака. 1931. № 7. Б. 42–43.

23. *Халит Г.* Романтизмны һәм реализмны яклап // Казан утлары. 1967. № 8. Б. 105–114.

24. *Хатипов Ф.М.* Әдәби әсәрнең эстетик энергиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 287 б.

25. *Хафизов С.* Гаугалы роман // Социалистик Татарстан. 1991. 2 август.

26. *Хөсни Ф.* Йөзек кашы // Хөсни Ф. Бер яшьлектә, бер картлыкта: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 8–52.

27. *Четырова Л.Б., Сахаров А.С.* «Деревенская проза» в контексте столкновения традиционной русской культуры и советской модерности // Семиотические исследования. 2023. Т. 3. № 2. С. 99–106.

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Ганиева Айгуль Фирдинатовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*aygulgani@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Л.Р. Надыршина***

# Г. БӘШИРОВНЫҢ ӘДӘБИ-ПУБЛИЦИСТИК ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫН АЧУДА АНЫҢ ШӘХСИ ФОНДЫНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Статья написана в виде обобщающего обзора материалов личного фонда выдающегося татарского прозаика, общественного деятеля, народного писателя ТАССР Баширова Гумера Башировича (1901–1999), со дня рождения которого 7 января следующего года исполняется 125 лет. Данный фонд насчитывает более тысячи документов различного характера: автографы литературных произведений и публицистических статей, рецензии, путевые заметки, письма, личные блокноты и др., демонстрирующие основные векторы широкомасштабной литературной и общественной деятельности писателя. Большинство этих документов были переданы Центру письменного наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова сыном писателя Зуфаром Башировым в 2024 году, и все они в совокупности представляют собой наглядный и надежный материал для проникновения в творческую лабораторию татарского классика, позволяют воссоздать основные этапы хроники его жизни и творчества, а также раскрывают основные вехи литературно-общественной жизни республики в советский и постсоветский периоды в целом.

Автор статьи представляет результат систематизации материалов их первой описи личного фонда Г. Баширова и определяет основные принципы его литературно-общественной деятельности, дает штрихи к творческому портрету писателя, устанавливает его вклад в развитие татарской литературы и общественной мысли.

**Ключевые слова:** Гумар Баширович Баширов, архив, татарская литература, советская литература, научное описание личных фондов, Центр письменного наследия ИЯЛИ АН РТ.

The article is written in the form of a generalizing review of the materials of the personal fund of the outstanding Tatar prose writer, public figure, People's Writer of the TASSR, Bashirov Gumer Bashirovich (1901–1999), whose 125th birthday will be celebrated on January 7, 2026. This fund contains over a thousand documents of various types, including autographs of literary works and journalistic articles, reviews, travel notes, letters, personal notebooks, and more, which demonstrate the main vectors of the writer's extensive literary and social activities. Most of these documents were donated to the Center for Written Heritage at the G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and Art by the writer's son, Zufar Bashirov, in 2024, and together they provide a clear and reliable insight into the creative process of the Tatar classic, allowing us to reconstruct the main stages of his life and work, as well as to understand the key milestones in the literary and social life of the republic during the Soviet and post-Soviet periods. The author of the article consistently describes each section of G. Bashirov's personal fund and defines the main principles of his literary and social activities, covering a creative portrait of the writer and establishing his contribution to the development of Tatar literature and social thought.

**Keywords:** Gumar Bashirovich Bashirov, archive, Tatar literature, Soviet literature, scientific description of personal funds, Center for Written Heritage of the Institute of Language, Literature and History of the Tatarstan Academy of Sciences.

Совет чоры татар әдәбияты, бигрәк тә прозасы турында сүз алып барганда, иң беренчеләрдән булып исеме атала торган әдип – Гомәр Бәширов (1901–1999) дисәк, ялгыш булмас. 1930 еллар башында «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә эшләгәндә күпсанлы очерклар язып каләм чарлаган язучы, әдәби мәйданга аяк баскач та, XX гасыр дәвамында милли прозаның үсеш юлларын сызган классикларыбызның берсе булып җитлегә, гомере азагынача әдәби әйдаманнарның берсе булып кала, «татар халык иҗатын туплап, эшкәртеп бастыру белән җитди шөгыльләнгән галим һәм үз чоры әдәби барышын һәрвакыт җентекле күзәтеп, бәяләп барган тәнкыйтьче-остаз буларак татар әдәбиятын үстерүгә үз өлешен кертә, татар халкы арасында милли җанлы, югары эрудицияле зыялы шәхес булып таныла» [1: 52–53]. Моны Г. Бәшировның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә (алга таба – Мирасханә) саклангaн һәм күпсанлы ядкәрләрне: язучы әсәрләренең караламаларын, публицистик язмаларын, төрле чараларда ясалган чыгыш текстларын, куен дәфтәрләрен, хатларын, аның тормышы һәм иҗаты белән бәйле видеоматериалларны һ. б. үз эченә алган шәхси фонды материаллары да бик ачык раслый. Әлеге фондка инде узган гасырның 70 нче елларында нигез салынган: ул вакытта Институтка йөзгә якын документ (нигездә, Г. Бәширов әсәрләренең кулъязмалары) тапшырылган, һәм алар шул елларда архив мөдире булып хезмәт куйган Һ.А. Сайманова тарафыннан тасвирланып, системага салынган. 2024 елда язучының улы, күренекле фотограф Зөфәр Бәширов бу фондны мең ярымнан артык саклау берәмлегеннән торган хәзинәмирас белән баетты, аларның барысы да Г. Бәшировның тормыш һәм иҗат биографиясен өйрәнүчеләр өчен гаять кыйммәтле чыганаклар буларак Мирасханә архивында үз урынын алды.

Фонд материалларын системалаштыру һәм фәнни тасвирлау барышында документлар Г. Бәшировның киңкырлы әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенең төрле тармакларын ача торган биш тасвирламага бүленде, әлеге мәкаләдә без әдипнең әдәби-публицистик эшчәнлеген чагылдырган беренче тасвирламага җентеклерәк тукталырбыз.

Беренче тасвирлама – күләме ягыннан иң зурларыннан. Өч йөздән артык саклау берәмлеген үз эченә алган калын-калын папкаларда язучының әдәби мәйданда олы уңышларга ирешү, иҗаты белән ил киңлегенә чыгу юлын чагылдырган кыйммәтле чыганаклар: төрле елларда язылган әсәрләренең кулъязмалары, вариантлары, караламалар һәм сызмалар, куен дәфтәрләренә, кәгазь битләренә терткәләп куелган әһәмиятле фикерләр һ. б. бик күп материаллар саклана. Арада басылмый калган әсәрләр дә («Татар егете», «Хәйдәр» һ. б.), кат-кат басылып, татар әдәбиятының алтын фондына кергәннәре дә («Намус», «Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә» һ. б.) бар, язучы әсәрләренең рус һәм башка телләргә тәрҗемәләре дә урын алган.

Документлар Г. Бәшировның әдәби әсәр иҗат итү эшенә олы җаваплылык белән якын килүен раслыйлар: язучы, берәр әсәрне язарга керешкәнче, аның планын эшләгән, геройларның якынча портретын сызгалаган, сөйләм үзенчәлекләрен күрсәткән. Мәсәлән, «Намус» романына караган материаллар арасында аның үз кулы белән булачак герое Сәйфигә шундый характеристика бирелгән: «Сәйфи – демагог, күп сөйләүчән. Хатын-кыз белән йөрүчән. Ул резко әйтмәс иде, бер кешене дә әбиҗәйт итми генә әйтер иде. ...ул хәйләкәр кеше бит! Әллә, пожалуй, самодуррак кеше дәме. Күп лыгырдый, урыны белән ялагай...» [7: 1 тасв., 83 сакл. бер.]. Һәм мондый язмалар фондта бик күп саклана, язучы һәр персонажын, һәр героен үз күңеле аша үткәреп иҗат итә, аларның берсенең генә дә язмышына битараф кала алмый. Үз чорында бу үзенчәлеккә Г. Ахунов та игътибар итеп, Г. Бәширов «совет кешесенә тирән мәхәббәт баглый, әсәрендәге һәрбер геройның язмышы өчен бөтен күңеле белән борчыла, совет кешеләренең гаҗәеп зур төзү эшләренә ярдәм итәргә теләп, чынбарлыкка үзенең мөнәсәбәтен дәртләнеп, хис белән, кайнарланып сөйли, шуңа күрә роман укучыны да дулкынландыра. Аны укыган чакта тыныч кына кала алмыйсың, барлык шатлык һәм кайгыны, барлык кыенлыкларны геройлар белән бергә кичерәсең» [2: 28], дип яза.

Язмалардан күренгәнчә, Г. Бәширов иҗатка теоретик әзерлек белән якын килгән. Ул еш кына булачак әсәренең сюжетына, образларына, гомумән, сурәтләнгән дөньяга төгәллек кертергә мөмкин булган төрле характердагы материалларны өйрәнә, конспектлый. Мәсәлән, шул ук «Намус» романын язганда, әдип, үзе «Гореф-гадәт законнан өстенрәк» мәкаләсендә (бу мәкалә рус теленә тәрҗемә ителеп, «Литературная газета»да да басылып чыга) әйтеп үткәнчә, татарларда һәм Көнбатышта хатын-кызлар мәсьәләсенә багышланган байтак кына китаплар укый (аларның конспектлары фондта саклана, әдипнең иҗат лабораториясен өйрәнүчеләр бу язмалар белән таныша ала), Нәфисә образын шул күзәтүләр яктылыгында иҗат итә. «Ул тынгысыз килен үзебезнең халык әкиятләрен дә яңадан укып чыгарга мәҗбүр итте. Үзем укыйм, үзем элек укыганнарым белән чагыштырып барам. Шул әкиятләрнең берсенең эчтәлеген генә булса да... искә төшерер идем. Ул әкияттә ике егетнең бер кызга гашыйк булуы турында сүз бара. Алар икесе дә яшь һәм көчле егетләр булганнар. Димәк, ул кыз өчен аларга көрәшергә дә мөмкин булган. Кем җиңсә, кыз шуңа! Әмма алай иткәндә кыз үзе теләгәнен сайлау хокукыннан мәхрүм калган булыр иде бит. Шунлыктан бу ике егет нишлиләр? Икесе ике юлдан китәргә булалар. Кызга әйтәләр: кайсыбызны яратсаң, шуның артыннан йөрерсең, диләр. Кыз һәм шулай итә дә. Кешенең хөрлеген һәм гомумкешелек гуманизмын аңлауда безнең халкыбызның философиясе әнә нинди югары баскычта булган, кешенең кешелек дәрәҗәсен, аның кадерен халык ул заманнарда ук әнә ничек тирән аңлаган!» [7: 1 тасв., 212-а сакл. бер.], – дип яза Г. Бәширов югарыда искәртелгән мәкаләсендә. Хәзерге вакытта әдәбият галимнәре

«үз чорына хас әдәби тип буларак тасвирланган Нәфисә – чын мәгънәсендә татар хатын-кызының иң матур сыйфатларын үзенә туплаган образ» [3: 40], дип нәтиҗә ясый икән – авторның да нәкъ менә шушы позициядән чыгып иҗат итүе фондтагы материаллар аша бик ачык чагыла.

Әсәр язуга әзерлек этапларын күрсәткән язмалардан шулай ук «Туган ягым – яшел бишек»кә керәчәк халык авыз иҗаты әсәрләре теркәп куелган битләрне дә атап булыр иде. Шуларга өстәп, чын мәгънәсендә «татар халкының рухын, эчке дөньясын сәнгатьчә чагылдырган уңышлы әсәрләрнең берсе» [4: 46] буларак иҗат ителгән бу әсәргә бәйле беренче сызмалар һәм фикерләр тупланган җиде блокнот та фондта урын алды [7: 1 тасв., 100 сакл. бер.]. Гомумән, мондый куен дәфтәрләрендә Г. Бәширов һәрдаим иҗади фикерләрен, идеяләрен язгалап барган, кая гына барса да, шул төбәктәге кешеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен, андагы мәкаль-әйтемнәрне, такмак-җырларны һ. б. теркәп куя торган булган, соңрак кызыклы формаларны үз әсәрләренә кертеп җибәргән.

«Туган ягым – яшел бишек» әсәренә бәйле блокнотларның берсендә мондый сүзләр бар: «Халыкның гореф-гадәтен, эчке культурасын бирү аша яшьләрдә туган иленә, үзенең халкына тирән мәхәббәт тәрбияләү максат итеп язылды». Бу – «прозабыз аксакалы»ның [5] тулаем иҗат мәсләге, аның әдәби-публицистик эшчәнлегенең төп принцибы. «Кеше үз мохитендә матур, ул үз җирлегендә, үз халкының баласы итеп күрсәткәндә генә тулысынча ачылырга мөмкин. Кеше кадәр кешене, табигатьнең күзе өстендә кашы булган шушы гади затны җир-суыннан, халкына хас сыйфатларыннан, үз мохитеннән мәхрүм итеп күрсәтү әдәби әсәр героен роботка охшаш читләнгән бер примитивка әйләндерә» [7: 1 тасв., 221 сакл. бер.], дип инанган татар классигы әсәрләрендә халкыбызның рухи кыйммәтләрен, матур традицияләрен татар укучысына һәм тәрҗемәләр аша башка милләтләргә таныту, милләтебезнең югары мәдәниятле, эчке культуралы, затлы, тәрбияле халык булуын аңлату теләге белән яна. Аның һәр әсәре, һәр публицистик язмасы шушы олы идеяне алга куеп иҗат ителә.

Иҗатта үтә таләпчәнлек, олы җаваплылык белән эш иткән Г. Бәширов әсәрләрен озак еллар буе җентекләп эшли, камилләштерә. Әдәбият катгый идеологик кануннарга буйсынган чорда да миллилекне саклап кала алган, «халыкчан тел-сөйләм, тормышны сурәтләүдә дә, сурәтләнгән дөньяда да эстетик камиллек, матурлык идеалына йөз тоткан» [6: 233] үрнәкләр булып укучы хөкеменә барып ирешкәнче, алар берничә вариантта иҗат ителеп, әдипнең үзтәнкыйть иләгеннән шактый иләнгәннәр. Әйтик, 1977 елда гына дөнья күргән «Җидегән чишмә» романының беренче сызмалары 1949 елга ук карый. Инде әдәби журналларда басыла башлаган өзекләр дә Г. Бәширов тарафыннан төзәтелеп бара – фондта автор төзәтмәләре белән чуарланган басмалар бик күп, китап рәвешенә килгәндә, әсәр инде жур-

нал вариантыннан беркадәр аерыла да (нигездә, стилистик яктан) башлый.

Әдәби иҗат эшенә шулай намус эше итеп караган, иҗаты чын мәгънәсендә югары дәрәҗәдәге профессиональлек үрнәге булган олуг зыялының – замандашлары иҗатына да нәкъ шулай таләпчән якын килүе бик табигый. Язучының беренче тасвирламада тупланган публицистик мәкаләләре шуны дәлилли. 1930 еллар ахырында Н. Гайсин, Г. Кашшаф, М. Гафури, К. Әмири, Т. Гыйззәт, И. Туктар кебек әдәбиятчыларның әсәрләренә, аерым китапларына язылган рецензияләрендә үк инде әдип үзен төгәл фикерле, теоретик хәзерлекле тәнкыйтьче итеп таныта. Үз иҗатында алга куйган принциплар – әдәби әсәрнең жанр таләпләренә туры килүе, билгеле бер идея җиткерүе, тел-стиль ягыннан камил эшләнгән булырга тиешлеге замандашларының иҗатын бәяләүдә дә төп критерий булып китә. Мәсәлән, Н. Булатның «Тимер» дигән романына язган рецензиясендә (1939) Г. Бәширов тәнкыйть объекты итеп авторның «материалны җыйнә алмавын» һәм шунлыктан әсәрнең бер кешенең бик озын итеп язылган биографиясе рәвешендә килеп чыгуын ала, «шуның белән бергә бу биографиягә автор тормышта очраганның берсен дә төшереп калдырмаска, барысын да теркәп узарга тырышкан, әсәрнең төп кимчелеге әнә шуннан килеп чыга» дип билгели; «кешеләрне, вакыйгаларны аларның эчке хәрәкәтен образлар белән күрсәтеп бирмәү, ә фотографияләгән сыман, аларның тышкы күренешләрен генә теркәп бару» да, ягъни психологизмнан ерак китү шулай ук әсәрнең зур уңышсызлыгы итеп күрсәтелә [7: 1 тасв., 160 сакл. бер.]. Үзе геройларын тудыруда һәр детальгә игътибарлы, әсәрен язарга керешкәнче үк, аларның психологик портреты нинди булырга тиешлеген, хәтта гадәт-кыланышларын, сөйләшү рәвешләренә кадәр бөтен төгәллеге белән ачык күзалларга күнеккән әдипнең мондый ясалмалылыкны бик тиз «тотып» ала белүе гаҗәп түгел.

Алга таба да Г. Бәширов объектив, төгәл эчтәлекле рецензияләр язуын дәвам итә, аларда ул әдәби әсәрнең жанр таләпләренә җавап бирергә, җыйнак язылырга тиешлеген (мәсәлән, Ф. Хөснинең хикәяләр җыентыгына язылган рецензиясендә); яңалыгы, оригинальлеге, башкаларны кабатламавы мөһим булуын (Л. Ихсанованың «Канатлы яшьлек» повестена язылган рецензиясендә); геройларның эчке кичерешләрен ачу, аларның психологиясен динамикада бирергә кирәклеген (А. Расихның «Кыш узар», С. Рафиковның «Олы юл» әсәрләренә язылган рецензияләрдә) ассызыклый.

Әдипнең тәнкыйди принципларын ачуда аның Язучылар берлегендәге төрле утырышлар алдыннан теге яки бу әсәр турында сызгалап куйган фикерләре дә әһәмияткә ия. Мәсәлән, Б. Камалов хикәяләренә бәйле ул «зур темалар, зур характерлар юк; гел вактөякләр тирәсендә әйләнә», «эчке мәгънә юк, барысы да, ни әйтәсе килүе тышта ярылып ята» [7: 1 тасв., 186 сакл. бер.], дип язса, Ә. Еникинең «Рәшә»се турында «бик үзенчәлекле, кычкырып тормый, үз

фикерен, үз карашын яшерә белгән, ягъни тенденциоз түгел» [7: 1 тасв., 199 сакл. бер.], ди. Мондый сызмалар архивта шактый, һәм алар язучының әдәби-публицистик мирасын максатчан өйрәнүчеләр өчен дә, аерым татар әдипләренең иҗатын тикшерүчеләр өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Х. Туфан кебек күренекле әдипләр турында язылган күләмле очерклар, иҗат портретларында да Г. Бәширов үзен әдәбиятны тирән аңлаучы, әдәби-иҗтимагый күренешләргә объектив бәя бирә белү сәләтенә ия, әдәби зәвыклы шәхес итеп таныта. Язмаларның күбесе Казан һәм Мәскәүдә рус телендә басылган газета-журналларда да дөнья күргән, шул рәвешле татар сүз сәнгатенең төп фигураларын ил киңлегендә таныту буенча да фидакяр хезмәт башкарылган.

Г. Бәшировның әдәби-публицистик эшчәнлегендә һәрвакыт үзәктә тора торган тагын бер мәсьәлә – әдәби әсәрнең теле. 1957 елда ук русча язылган бер язмасында «Вызывает недоумение странное отношение к художественному слову наших критиков и рецензентов языку произведения, они обычно отводят всего лишь несколько ничего не значащих строк и то в самом конце статьи. Они начинаются обычно такими безразличными и «усталыми» словами, вроде: «Что же касается языка произведения...» [7: 1 тасв., 170 сакл. бер.], дип белдергән язучы бөтен иҗат гомере дәверендә тел-сөйләм проблемаларын яктырткан төрле мәкаләләрне газета-журналлардан кисеп алып, аерым папкага җыеп барган, һәр төбәктә кешеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен күзәткән, үзе дә фәнни экспедицияләрдә катнашкан, тел культурасы хакында күпсанлы фикерләрен вакытлы матбугат битләре аша укучыга ирештергән. «Без, әдипләр, ягъни проза язучылар ... шушы тиңсез кадерле байлыктан заман таләбенә, әдәбиятның хәзерге дәрәҗәсенә лаек булырлык рәвештә файдалана беләбезме, шуңарга сәләтебез, осталыгыбыз һәм тырышлыгыбыз җитәме?» [7: 1 тасв., 240 сакл. бер.] дигән сорауны күтәреп, «Тел – тормышның көзгесе», «Бер сүз турында берничә сүз», «Яңа сүзләр кирәк, бик күп кирәк», «Дөрес яза беләбезме икән» һ. б. мәкаләләрендә, радиочыгышларында ул тел байлыгын урынлы куллану, әдәби әсәрнең тел-сөйләм ягына зур игътибар бирү зарурияте турында сөйли.

Гомумән, Г. Бәшировның әдәби һәм публицистик эшчәнлеген ачкан күпсанлы материаллар язучы иҗатының бөтен совет киңлегендә гаять зур популярлык казануының (аңа Советлар Союзының төрле төбәкләреннән, төрле милләт укучыларыннан килгән күпсанлы хатлар шуны раслый) сере табигатьтән бирелгән гаҗәеп сәләттә генә түгел, ә бәлки әдипнең, бер яктан, киң карашлы, югары эрудицияле һәм теоретик әзерлекле булуы, икенче яктан, иҗатта үз-үзенә карата һәрвакыт таләпчәнлеге, әдәби әсәр язу эшенә гаять җаваплы каравы нәтиҗәсе икәнлеген күрсәтеп тора.

## Әдәбият

1. *Абдуллина Д.М.* Гомәр Бәширов // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 6. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 52–60.

2. *Ахунов Г.* Әдәби язмышлар: мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 190 б.

3. *Габидуллина Ф.И.* Сугыштан соңгы еллар татар әдәбиятында герой концепциясе чагылышы // Фәнни Татарстан. 2025. № 1. Б. 35–42.

4. *Ганиева А.Ф.* XX гасырның икенче яртысы татар прозасы («кеше һәм табигать» мәсьәләсе). Казан: ТӘһСИ, 2019. 152 б.

5. *Ганиева-Гыйниятуллина А.* Прозабыз аксакалы // Мәдәни җомга. 2016. 22 гыйнв. (№ 2). Б. 15.

6. *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 223–234.

7. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 75 нче фонд.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024*

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Надыршина Лейсан Радифовна,***
*доктор филологических наук, старший научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*leysan_tatar@mail.ru*

УДК: 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ФАТИХ ӘМИРХАН ПУБЛИЦИСТИКАСЫ: КЫЙБЛАЛАР АЛМАШЫНГАН ЧАКЛАРДА (1913–1925)

Статья посвящена публицистической деятельности Фатиха Амирхана в 1913–1925 годах. Рассматриваются малоизвестные публикации, увидевшие свет на страницах газеты «Әлислах», журнала «Аң»; анализируется творческая эволюция его политических, национальных, общественно-философских и культурно-эстетических взглядов. Установлено, что Ф. Амирхан до 1917 года оставался одним из ведущих авторов социально-политических аналитических статей, лидером татарского возрождения. Он был сторонником идеи прогресса татарского народа, в критике и публицистике выступал за развитие национального образования, науки, культуры. В послереволюционный период он пытался разъяснить своему народу смысл перемен, однако в целом был отстранен от журналистской деятельности.

Ключевые слова: татарская литература, Фатих Амирхан, возрождение нач. XX века, «Аль-Ислах», «Анг», публицистика, критические статьи.

The article is devoted to the journalistic activity of Fatih Amirkhan in 1913–1925. Little-known publications published on the pages of the newspaper “Al-Islah” and the magazine “An” are considered; the creative evolution of his political, national, socio-philosophical, cultural and aesthetic views is analyzed. It is established that F. Amirkhan remained one of the leading authors of socio-political analytical articles and the leader of the Tatar renaissance until 1917. He was a supporter of the idea of the progress of the Tatar people, and in criticism and journalism he advocated the development of national education, science, and culture. In the post-revolutionary period, he tried to explain to his people the meaning of change, but was generally excluded from journalistic activities.

**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, renaissance of the beginning. twentieth century, “Al-Islah”, “Ang”, journalism, critical articles.

Фатих Әмирханның «Әлислах» чыгудан туктагач бераз сүлпәнләнеп-салмакланып калган публицистик эшчәнлеге 1913 елдан кабат ялкынланып китә. Чөнки 1912 елның ахырында татар вакытлы матбугаты мәйданында хасил булган яңалыклар нәкъ менә аның исеме, эш-гамәлләре белән бәйле булалар дисәк, ялгышмабыз.

1912 елның 10 декабрендә китап сатучы Кәримовлар канаты астында иҗтимагый-сәяси мәсләкле көндәлек «Кояш» газетасы чыга башлый. Ул 1918 елның 24 июненә кадәр яши, 1915 елның 9 апреленнән мөхәррире Зәкәрия Садретдинов була. Әмма беренче көненнән «Кояш»ның кыйбласын һәм һәр санның эчтәлеген билгеләүче, авторлар туплаучы, язмаларны бастыру мәсьәләләрен хәл итүче, оператив рәвештә аны җитмәгән материаллар белән «ипләп-сипләп» баручы –

Фатих Әмирхан. Шуңа да XX гасыр башы татар җәмәгатьчелегендә бу газета аның шәхесе һәм исеме белән бәйле кабул ителә.

Моннан тыш, Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай Казан шәһәренең зыялы яшьләрен моңа кадәр татар дөньясында күрелмәгән югары сыйфатлы, затлы бер журнал чыгару идеясе белән рухландыралар, «Гасыр» китап нәшриятының бер оештыручысы Әхмәтгәрәй Хәсәнине журналның мөхәррире булырга күндерәләр. 1912 елның 15 декабреннән Казанда ике атнага бер тапкыр чыга башлаган матур әдәбият, нәфис сәнгать һәм әдәби тәнкыйть журналы Г. Тукай тәкъдиме белән «Аң» исемен ала. 1918 елның мартында чыгудан туктаганчы, журналның эчтәлеген билгеләүдә Әмирхан әйдәп баручылардан була.

Әмирханның «Аң»да дөнья күргән үз публицистик мәкаләләре күп түгел, әмма алар газетага әзерләнгәннәрдән аналитик юнәлешле булуы белән аерылып тора. Әйтик, Казанда кызлар гимназиясе ачу хәбәренә нисбәтле язылган «Милли кызлар гимназиясе мөнәсәбәте илә» («Аң», 1913, № 3) язмасында әдип татар мәгарифе тарихына күз ташлый, аның башлангыч мәктәпне үзгәртү этабын узып, урта баскычларда яңача укытыла башлауны ассызыклый. Татар мәгарифендәге вазгыятьне әдип башка төрки халыкларның уку-укыту мәйданындагы хәл-әхвәл белән чагыштыра һәм гаять кызыклы күзәтүе белән уртаклаша. Ул башкаларда мәгариф реформасының югарыдан башлануын әйтә, татарларның бу хәрәкәтне «түбәннән», гади халыкка заманча аң-белем бирерлек шартлар тудырудан алып китүен хуплый, 20 ел эчендә булдырылган татар мәгариф системасын халык аңын үстерү фундаменты дип атый: «Нәтиҗәсендә, элегә аз күренә торган, ләкин яхшы ук сизелә торган бер фундаментның вөҗүдкә килә башлаганыны күрәмез: яшүсмерләремез язу таныйлар, китап укыйлар... Шуның аркасында әдәбият тарала ала. Әдәбият аркасында милли аң, милли монафәгане (*файданы*) аңлау вә гомумән дә мәдәният адымнары башлана» [6: 191].

Кызлар гимназиясе ачылу хәбәрен – чираттагы адым, алгарыш яклыларның олы җиңүе дип кабул иткән әдип болай ди: «Мәгълүматлы, милли рухлы аналар җитештерүгә муаффәкъ булган (*ирешкән)* милләтнең иң нык фундамент өстенә баскан милләт булачагы бик ачык» [6: 192].

Ул татар дөньясындагы һәр вакыйга яки күренешкә – милләтне үстерү, алга җибәрү, милләтпәрвәр яшьләр тәрбияләү ягыннан якын килә. «Балаларга бәйрәм (Мәүлид мөнәсәбәте илә)» мәкаләсе (Аң, 1913, № 4), татарларның дини һәм милли бәйрәмнәрен ничек уздыруына анализ ясап, боларны балалар өчен күңелле итеп оештыруның милли үзаң булдыруда, татарлыкны ныгытуда, үзләрен татар милләтенең бер вәкиле дип горурлану тәрбияләүдә – иң зур чараларның берсе икәнлеген сөйли. «Җырчыларымыз (Театр вә музыка)» (Аң, 1915, № 15–16) язмасында исә татар сәхнәсендә исем-ат казанган җырчылар Камил Мотыйгый, Фәттах Латыйпов, Фатыйма

Ихсанова, Сатирә Әхмәдиеваларның тавышы, аһәңе-моңы, музыканы аңлавы, репертуары аның тарафыннан тәнкыйть күзлегеннән кичерелә. Яңа гына сәхнәгә менгән җыр сәнгатенә Әмирхан югары таләпләр куя.

Журналдагы берничә язма узган көннәрне искә төшереп, аерым шәхесләр турында хатирәләр уртаклашып язылган. Якын дусты, фикердәше Тукайның иртә үлемен бик авыр кичергән Әмирхан «Тукай тугрысында искә төшкәннәр» (Аң, 1913, № 9) дигән күләмле язмасында шагыйрь турындагы хатирәләре белән уртаклаша. Исмәгыйль Гаспралы вафатына нисбәтле язылган «Олуг милләтче тугрысында кечкенә бер хатирә» (Аң, 1914, № 18) төрки халыкларның олы мәгърифәтчесенә югары бәя биреп, аны «Милләт мәдәниятенең бабасы» дип зурлый. «Сәхнәмезнең ун яше мөнәсәбәте белән» (Аң, 1916, № 16–17) мәкаләсендә Әмирхан татар театрына ун ел тулу уңаеннан шушы тарихны күздән кичерә, милли сәхнә сәнгатен барлыкка китерүгә өлеш керткән шәхесләрне барлый, шул юлдагы адымнарны искә төшерә. «Поляк мөхәррире Сенкевич» (Аң, 1916, № 19–20) Генрих Сенкевичның үлеменә нисбәтле язылган. Әмирхан аның поляклар өчен чын милли язучы булуына игътибар итә, әсәрләренең халык аңын, карашын, тормышын үзгәртүе турында сөйли, Сенкевич әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү хакында сүз алып бара. Әмирхан, татар укучыларына «Галәбә иткән Бартек» һәм «Познаньдагы мөгаллимнең көнлек дәфтәреннән» әсәрләре кызыклы һәм файдалы булыр иде дип искәртә. Шул рәвешле, сиздерми генә, каләмле яшьләргә юл күрсәтеп куя.

Татар мәдәниятендәге җитешсезлекләргә мөнәсәбәт белдереп, Әмирхан «Аң»га ике мәкалә яза. «Тәрҗемә – тәфсир»дә (Аң, 1916, № 15) Габдулла Гыйсмәтинең Коръән китабын татарчага тәрҗемә итү омтылышы тискәре бәяләнгән. «Бер “мәшһүрә”нең Усиягә сәяхәте (Пародия)» (Аң, 1915, № 17) ярым әдәби, ярым публицистик формада булып, ул еллар матбугатында татар кешеләренең үз сәяхәтләре хакында күпләп мәгънәсе булмаган мәкаләләр бастыруыннан көлеп, шуларга пародия итеп эшләнгән.

«Кояш» битләрендә исә Ф. Әмирханның кайчандыр «Әлислах»та нигезләнгән юнәлешләрдә бик күп язмалары бирелеп бара. Бу яктан, хәзер инде аның үткен каләменең иҗтимагый-сәяси проблемалардан милли-мәдәни якка борылуын да әйтергә кирәк. Әмма һәр язма диярлек татар халкы тормышындагы, милләт алгарышындагы күренешләргә кагылмый калмый.

1913 елда татар матбугаты, Романовлар династиясе патшалык итүенең өч йөз еллыгы уңае белән, хөкүмәттән күп кенә эшләр башкарырга рөхсәт һәм матди ярдәм алу мәсьәләсен гел куертып тора. Шушы дулкында «Йолдыз» газетасында, 5 хәзрәт язган мәкаләгә җавап итеп, Әмирхан «Биш хәзрәт» (Аң, 1913, 11 февраль) язмасы белән чыга, анда мөселманнар өчен берәр гыйльми җәмгыять, татар хатын-кызлар мәктәбе ачу «Кояш» газетасының инициативасы

икәнлекне искәртә, хәзрәтләрнең исә моңа каршы чыгуларына, җирле хакимият вәкиле М.Н. Пинегин белән киңәшеп, ятим кызларга приют (дареләйтам) булдыру ягын куәтләвенә борчылуын белдерә. Әмма сөйләшү шушы ноктада төгәлләнми: шушы мәсьәләгә нисбәтле Зәки Вәлидинең «Вакыт» газетасындагы репликасы Әмирхан тарафыннан шактый усал берничә мәкалә бастырылуга сәбәп була. Алар арасындагы каршылык ниндидер шәхси мөнәсәбәтләргә бәйле булмыйча, Вәлидинең татар җәмгыятен каралтырга тырышуы – бу язмаларга тәфсиллерәк тукталырга мәҗбүр итә.

Әмирхан «Зәки хәлфәң нишләтте!» (Аң, 1913, 15 февраль) мәкаләсендә Вәлидинең кайсы гыйбарәләре хаксыз, ялган булганны күрсәтеп бара. «Казан халкы – эшсез көйгә шөһрәт чыгарырга сөя торган халык», «Гимназия өчен мөгаллимәләр юк; бу кадәр мөһим мөәссәсәнең (*оешма, учреждение*) уставын, программаларын әсаслы (*төпле, нигезле*) сурәттә тәфтиш итеп (*тикшереп*)... эшләп чыгарырлык кешеләр дә юк», «Гимназиянең киләчәге өмидле бер сурәттә булып чыгуы бик шөбһәле» [6: 201] кебек гыйбарәләрдә ул алгарыш юлына чыккан татар милләтеннән көлү күрә.

Ф. Әмирхан мәкаләсе З. Вәлиди тарафыннан да, башка кайбер зыялылар тарафыннан да игътибарсыз калмый: җавап языла. Әмирхан да берничә язмада («Үз-үзеңне “эре” тот» (Аң, 1913, 5 март), «Муса әфәнде Бигиев һәм Шакир әфәнде Мөхәммәдьяровка минем җавабым» (Аң, 1913, 5 март), «Кәрлә дустка» (Аң, 1913, 14 март), «*** (Муса әфәнде...)» (Аң, 1913, 29 март), «Агач телле ташкурчаклар» (1913, 7 апрель), «Гайре мәҗбүри нәсыйхәт» (Аң, 1913, 17 апрель)) фикерен дәвам итә, милли мәсьәләләрне тикшергәндә әдәпкә, үзара ихтирам итешүгә чакыра.

Шуңа охшаш хәл Әмирханның «Мирза һәм рус теле» (1914, 11 сентябрь) сатирик мәкаләсенә – Сәетгәрәй Алкинның (1867–1919) татар вакытлы матбугатын сугыш хәбәрләрен бозып басуда, анда эшләүчеләрне рус телен белмәүдә гаепләп чыгуына җавапка – нисбәтле кузгалып ала.

Тукайга багышланган санда Ф. Әмирхан «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун» (Аң, 1913, 4 апрель) дигән, татарның вакытсыз бакыйлыкка күчкән сөекле шагыйре хөрмәтенә хушлашу яза. «Тукаев – кайгы-хәсрәт баласы, моңнар шагыйре, авыр тойгылар, авыр мәшәкатьләр җырчысы иде. Ул шуларны җырлап үскән, шуларны җырлап торды, шуларны җырлый-җырлый вафат та итте. Милләтемезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас иде. Менә шуңар күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды» дип, әдип бу үлемнең үзе өчен дә, татар дөньясы, милләт өчен дә гаять зур югалту булуын ассызыклый, кайгысы белән уртаклаша. Бер елдан соң Әмирхан «Тукай үлем алдыннан (Хатирә)» (Аң, 1914, 2 апрель) дигән истәлеге белән уртаклаша.

1913–1917 елларда «Кояш»та басылган аерым бер публицистик мәкаләләрдә Әмирхан кайбер шәхесләр белән очрашуларын бәян итә, аларның игелекле гамәлләрен бәяли. Әйтик, «Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләре белән “Кояш” сайфиясендә мосахәбә»дә сүз (Кояш, 1913, 5 август) хокук белгече, язучы, дәүләт эшлеклесе Мәхмүд Әсгадь бине Әмин Сәеди Шәһринең Казанга килүе турында бара. Әдип үзара гәпләшүне тасвирлап бирә, әңгәмәдәшенең карашлары белән таныштыра. «Вамбери» (Кояш, 1913, 4 сентябрь) язмасында шәркыятчы, лингвист, язучы Арминий Вамбери (1832–1913) турында мәгълүмат җиткерелә. «Наил бәк һәм иптәше белән мосахәбә» (Кояш, 1914, 28 апрель) Төркиядән Катанов китапханәсен сатып алырга килгән Наил Рәшид бәк һәм Гомәр әфәнде бин Хаҗи Рамазан белән аралашу хакында сөйли.

1915 елда әдип Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланган берничә эчтәлекле һәм күләмле язма әзерли. «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе» (Кояш, 1915, 9 гыйнвар) Ш. Мәрҗанинең тууына 100 ел тулуга нисбәтле язылган. Автор аны фикер иясе һәм галим, үзе өчен идеал дип атый, аның образы татарның якты киләчәгенә өмет уята дип белдерә. «Мәрҗани хатирәсенә мәҗмуга» (Кояш, 1915, 16 апрель) бөек мәгърифәтченең тууына 100 ел тулуга багышлап чыгарылган җыентыкка бәяләмә итеп язылган. Әлеге эшне хуплап һәм куанып, Әмирхан: «Бу көнгә кадәр үзенең мөхлисләренә (*дусларына)* дә бихак мәгълүм булмаган Мәрҗани бу мәҗмуга аркасында бөтен татар әһле галәмендә ап-ачык мәгълүм була алачактыр» [7: 135], ди. Ул җыентыкка кергән һәр мәкаләгә җентекле анализ ясый, уңай һәм җитешмәгән якларын күрсәтә. Язма: «Моннан соң Каюм Насыйри, Тукай һәм Гаспринский хәзрәтләре хакында шушындый җитди вә фәнни мәҗмугалар чыгуын өмид итәргә каладыр» [7: 137] дигән сүзләр белән тәгәлләнә.

Газетада Ф. Әмирхан төрле жанрларда мәкаләләр бастыра. Әйтик, «Хыял галәменнән» (Кояш, 1913, 20 август) – ярым әдәби, ярым публицистик планда татарның киләчәге турында сөйли: имеш, хикәяләүче көннәрдән бер көнне уянып китсә, Русия мөселманнарының берьеллык тиешле садакалары исәбенә зур бер «милли фонд» төзелгән; шуның акчалары ун мең мәхәлләдәге ун мең башлангыч мәктәпкә бүлеп бирелгән, калганнары ятим балалар һәм картларны тәрбия итәргә тотылган. Шул рәвешле, көлү, уен формасында әдип үзенең милләт киләчәге турындагы хыяллары белән таныштыра.

Тагын бер күләмле язма – «Кыска бер сәфәрдә» (Кояш, 1913, 20, 22, 25, 26, 27 сентябрь һәм 6 октябрь) – сәяхәтнамә рәвешендә иҗат ителгән. Ул Ф. Әмирханның 1913 елның сентябрендә Сембер губернасында күргәннәре турында сөйли. Рус авылын, мондагы көнкүрешне татар авыллары белән чагыштыру хикәяләүчегә күпмедер канәгатьлек бирсә дә, язучы юлда очраган татарлар көнкүрешендәге күп кенә тискәре күренешләргә игътибар итә. Аерым алганда, татарларның үз исемнәрен русчалаштырып әйтүне табигый кабул итүе, татар-

лар өчен – үз, руслар өчен – бозык исемдә йөрүләре шундыйлардан. Әдип моны милли үзаңны җимерә торган күренеш дип атый. Юлда баргандагы сөйләшүгә сылтап, ул Н.Ф. Катановның И.Н. Харитонов әлифбасы хакындагы дөреслеккә туры килмәгән мәкаләсен тәнкыйтьләп уза, бу әлифбаны бертуган Рәмиевләр эшләгәнне искәртә. Харитонов календарьларының бәһале һәм заманнан артта калган булуын күрсәтә. Шуларга бәйле, чит милләтләрнең татарлар хакында рус матбугатында чыккан һәм дөреслеккә туры килмәгән язмалар аша фикер йөртүен олы бер мәсьәлә итеп мәйданга куя. Аның артында – рус матбугатына татарларга кагылышлы яхшы язмалар әзерләү дә, татар мәдәниятенең иң матур үрнәкләрен рус теленә тәрҗемә итү дә, аерым бер татар шәхесләре хакында мәгълүматлар әзерләү дә калкулана.

Ф. Әмирханның «Мәдрәсәләремездә әдәбият дәресләре» (Кояш, 1913, 29 сентябрь) шул исем белән «Әлислах»та басылган язманың дәвамы кебек тоела. Әдип кабат мәдрәсәләрдә әдәбият укытуга мөрәҗәгать итә, моны алда торган иң мөһим эшләрнең берсе итеп карый. «Әүвәлге мәдрәсәләр никадәр тормышка истигъдадсыз (*сәләтсез*) кешеләр чыгарсалар, хәзерге мәдрәсәләремез дә тормыштан шулкадәр ерак кешеләр җитештерәләр», дип, әдип «Моның сәбәбе нәрсә?» дигән сорау куя. «Мәдрәсәләремезнең хәяттан бик ерак булуларының күп сәбәпләре арасында, занымча, боларда татар әдәбияты укытылмавы – иң баш сәбәпләрнең берседер» [7: 124], ди ул.

«Милли көтепханә һәм музәханә» (Кояш, 1913, 10 ноябрь) шулай ук татар дөньясы өчен актуаль бер мәсьәләгә игътибар юнәлтә. «Үз-үзләрен сөя торган милләтләрдә бер гадәт бар: алар үзләренең тарихларына, тарихларына мөтагалликъ асаре гатикаләренә (*бәйле борынгы әйберләренә*) бик зур әһәмият бирәләр» [6: 237] дип, әдип кавемдәшләренең моны кирәк санамауларына сызлана. Үзенең борынгы нәселләрдән Габдулла Апанаевка мөрәҗәгать итүен, Хәсән Акчуриннарда, Мәрҗанидә, Галимҗан Барудида зур китапханә барлыгын телгә ала һәм, «хәзер иске китапларымызны вә әсәрләремезне саклар өчен бер көтепханә вә музәханә вөҗүдкә китерергә бик вакыт җиткән икәнлеге күренәдер» дип, боларны бер урынга туплаган бер музей оештыру тәкъдиме белән чыга.

Ф. Әмирхан язмаларының географиясе элеккечә үк бик киң. «Төркестан шивәсендә матбугаты мувәкъкатә» (Кояш, 1913, 4 октябрь) язмасында ул Урта Азиядә төрки телләрдә матбугат булдыру мәсьәләсенә кагыла. «Бәйлис эше мөнәсәбәте белән» (Кояш, 1913, 8 октябрь) дигән баш мәкаләдә патша хөкүмәте тарафыннан 1913 елда Киев шәһәрендә яһүд Менахем-Мендел Бейлиска каршы оештырылган суд процессының ни өчен дөньяда бер символик вакыйга буларак кабул ителүе аңлатыла. «Бездә вә кардәшләремездә сөтрә (*пәрәнҗә*) мәсьәләсе» (Кояш, 1913, 11 декабрь) Кавказ мөселманнарында хатын-кызларның качуларына мөнәсәбәт белдереп язылган. Әдип кавказлы ирләрнең ватаныннан күчеп китүен, чит милләт хатыннарына өйләнүен дә – бу җирлектә хатын-кызга ирек бирелмәүгә бәйләп

карый. Казан татарларындагы вазгыять белән чагыштырып, болай ди: «Сөтрә мәсьәләсе без, Казан татарлары, арасында да бервакыт зур низаглы бер мәсьәлә булып тора иде. Ләкин тугры вә куәтле миллият тойгысы уяну, халыкта милли аң арту белән хәзер инде ул мәсьәлә үз-үзеннән хәл ителү юлында бара. Бу мәсьәләнең иң низаглы көннәрендә халкымызның бер дәрәҗә игътидал (*уртачалык)* саклап вә фикер йөртеп хәрәкәт иткәнен хәтеремезгә алып, без бу акыллы халыкны яхшырак аңларга вә аның гакыллылыгы алдында ихтирам итәргә мәҗбүрмез».

Әмирхан күп кенә яшерен, матбугат мәйданына чыкмый торган мәсьәләләргә кагылудан да курыкмый. Әйтик, каршылыклы кабул ителә торган «Кызганыч бу тәнасеб!»тә (Кояш, 1913, 9 октябрь) Санкт-Петербург мәчетенә Бакудан затлы люстралар бүләк ителүгә бәйле, Аллаһ йорты – мәчет – зиннәтле булырга тиешме, әллә анда кеше аскетлык фикерен ныгыту өчен килергә бурычлымы дигән сорау тирәсендә фикер йөртелә. «Җилгә киткән батырлык» (Кояш, 1913, 11 октябрь) Кавказ мөселманнарындагы кан үче традициясенә мөнәсәбәт белдереп язылган. Аларда, тормыш-чынбарлык күренешләреннән бигрәк, әдипнең фәлсәфи уйланулары, милли һәм дини традицияләр, гадәтләр, карашларны – кешелек язмышы ноктасыннан бәяләү алга чыга.

«Дини мәктәп һәм мәдрәсәләр хакындагы истифсарга даир» (Кояш, 1913, 15 октябрь) Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Чит диннәрнең рухани эшләре буенча департамент директорының мөфти хәзрәтләренә конфессиональ яки дини мәктәпләрнең хәленә һәм киләчәгенә кагылышлы сорау белән мөрәҗәгатенә нисбәтле язылган. Әмирхан бу сорауга җавап булырлык берничә мәсьәләгә игътибар юнәлтә. Аныңча, шәригать күзлегеннән караганда, бу мәктәпләр дин гыйлеменнән һәм фәннәрдән мәгълүматлы кешеләр әзерләргә тиеш, шуңа да аларның программаларына фәннәр кертелү зарур. Тәрбияне ана телендә бирү – пәйгамбәрдән килә торган фарыз, мөгаллимнәр исә дин әһеле дә, гыйлем кеше дә, ышанычлы һәм абруйлы шәхес тә булырга тиешләр.

1913 елда И.Н. Харитонов матбагасында басылган Коръәндә хаталар, ялгышлар табылу уңае белән Ф. Әмирхан берничә мәкалә бастыра. «Коръән бозу» (Кояш, 1913, 14 ноябрь) дигән беренче язмада ул үзе тапкан хаталарны күрсәтеп уза, монда аның дин гыйлемен тирән үзләштергән булуы күренә. «Харитонов җавабы мөнәсәбәте белән» (Кояш, 1913, 2 декабрь) дә набирнең фикере белән килешмәвен белдерә. «Харитоновның судка мөрәҗәгате»ндә (Кояш, 1914, 9 июль) Харитоновның Коръәнне бозу хакында мәкаләләр бастырган өчен «Кояш» һәм «Йолдыз» мөхәррирләрен судка бирү вакыйгасы сөйләнә.

1913 елда эшләнгән милли мәдәни эшләргә күзәтү ясаган «1913 нче ел. Милли эшләр» (Кояш, 1914, 1 гыйнвар) аналитик язмасы – сугыш алды хәвефләрен, бәйрәмнәр һәм җыеннарны, югалтулар-

ны санап, әдәбиятның матур әсәрләр бирә алмавын, күп кенә матбугат органнарының ябылуын әйтә, елның уңышсыз булуын искәртеп тәмамлана.

Әдип алга таба да бәйрәмнәр, яңа китаплар хакында язуын туктатмый. «Бәйрәм итик»тә (Кояш, 1914, 22 гыйнвар) Мәүлид бәйрәмен зурлап уздыруны хупласа, «“Мөгаллим”»дә (Кояш, 1914, 27 гыйнвар) Гаяз Исхакыйның шул исемдәге пьесасы буенча куелган спектакльгә бәя бирелә. «Балалар кичәсе» (Кояш, 1914, 28 гыйнвар) Мәүлид бәйрәме уңаеннан Шәрык клубында Балалар кичәсе уздырылуга багышлана. «Уфада әдәбият кичәсе (Үз мөхбиремездән)» дә (Кояш, 1914, 7 февраль) мәкалә исеменә чыгарылган чара турында сөйли. «Сабан туенда» (Кояш, 1914, 11 май) Казанда Сабан туен уздыру, соңгы елларда бу чарага килеп кергән яңалыклар хакында. Корбан гаете белән котлап, сугышка ачынып язылган «Йа, Аллаһы, галәбә вә тынычлык җибәр!» (Кояш, 1914, 17 октябрь) язмалар арасында эмоциональлеге белән аерылып тора. «Театр һәм музыка» (Кояш, 1916, 8 март) татар артистлары тарафыннан Кариев бенефисына багышлап «Ревизор» комедиясе уйналу мөнәсәбәте белән язылган. «Икенче адым» (Кояш, 1916, 30 октябрь) мәкаләсе 1916 елның 29 октябрендә Фатиха ханым Аитованың кызлар гимназиясе ачылу уңаеннан әзерләнгән. Әдип аның татар кызлары өчен татар телендә укытыла торган урта мәктәп булуын алгарыш юлында зур җиңү дип бәяли.

Татарларның чит милләтләр гадәт-йолаларына ияргүен тәнкыйтьләп, Әмирхан «Мәгънәсез тәкълид» (Кояш, 1914, 12 февраль), «Май чаптык...» (Кояш, 1914 ел, 18 февраль) кебек язмалар бастыра. Җәмгыятьтәге кимчелекләрдән көлеп язылган «Театрдан килгән акча хәрәм» (Кояш, 1914, 9 май) җәмгыяте хәйриядә театр уйнаудан кергән акчаны хәрәм дип белдерүләрнең нигезсезлеген дәлилли. «Шаккатыргыч сәяси» (Кояш, 1914, 15 июль) «Йолдыз» мөхәррире Ә. Максудиның белер-белмәс сәяси фаразлар әйтүеннән көлеп иҗат ителгән. «Бергәме, аерыммы?» (Кояш, 1914, 17 август) «Йолдыз» газетасының сугышта әсир төшкәннәр файдасына акча җыю максаты белән «Мөселман комитеты» төзү тәкъдименә кагыла: Әмирхан бу эшне мөселманнар аерым түгел, руслар белән бергә башкарырга тиеш дигән фикерен җиткерә. Шушы ук мәсьәлә кабат «“Йолдыз”га җавап» (Кояш, 1914, 10 сентябрь) язмасында дәвам итә.

Бүген дә актуальлеген җуймаган «Кабиләлек низаглары» (Кояш, 1915, 25 февраль) Мәхбүбҗамал Акчуринаның «Имля мәсьәләсе» мәкаләсенең, телдәге аерым күренешләргә багышланган булса да, мишәрлек-татарлык мәсьәләсен кузгатып җибәрүенә игътибар итә. Әмирхан моның татарларны бүлгәләүгә китерергә мөмкин булган куркыныч күренеш икәнлеген әйтә. Шуңа күрә, бер яктан, бу мәкаләне бастырганнары өчен «Ил» газетасы хезмәткәрләрен гаепли. Бик кечкенә күренешкә нигезләнеп («й» һәм «җ» хәрефләренең төрлечә кулланылышы) зур нәтиҗә ясаган авторга да тәнкыйть сүзләре белдерә. Тел ягыннан Г. Рәхимнең «Җим мәсьәләсе» мәкаләсен телгә

алып, бу проблеманың фәнни аңлатылышына туктала. Нәтиҗә ясап, болай ди: «Әүвәл шималь төреге була белергә кирәк, аннан соң да әле мишәр, татар, башкорт, казакъ булырга өлгерермез. Әүвәл бер мәдәният астына кереп, кеше төсле торып карарга кирәк, әгәр ул тормыш ошамаса, аннан соң да төрле кабиләләргә бүленеп сугыша башлауны булдыра алырмыз, оеша башлаган әдәби тел, җөйләнә башлаган милли барышка үзләре генә баш булырга теләүче кабиләләр табылалар икән, болар инде башка кабиләләр тарафыннан тәэдиб ителергә (*әдәпкә кертелергә*) тиешләрдер. Әгәр махсус кабиләнең хосусый мактанчык балалары шундый хәтәрле дәгъвалар белән матбугатка чыгалар икән, бу фәрд иң башлап шул кабиләнең алдынгы әфрады (*затлары*) тарафыннан авызлыкланырга тиештер» [6: 287].

Гомумән алганда, 1915 елдан әдип мәкаләләрендә тәнкыйть тагын да көчәя. Ул татар дөньясындагы күп кенә күренешләргә мөнәсәбәт белдерә. «Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар»да (Кояш, 1915, 26 июнь) 1915 елның 12 июнендә вафат булган мөфти М. Солтанов урынына яңа мөфти кую мәсьәләсе турында сүз бара. Әмирхан татар җәмәгатьчелегендә башланган фикер алышуларга туктала, хөкүмәт татар дөньясы фикеренә колак салырмы-юкмы дигән мәсьәләгә хокукый яктан карап, фараз ителгән кандидатлар хакында сөйләп уза. «Мәдәни ганганәсезлек хурлыгы» (Кояш, 1915, 30 июль) Ишми ишаннарның донос белән шөгыльләнүенә ачынып язылган. «Кыз балаларымыз мәктәпләрендә» (Кояш, 1916, 25 март) имтиханнар алуның кирәклеге шик астына ала. «Бездә һөҗү» (Кояш, 1916, 18 июль) татар көлке журналларындагы тупаслыкны, үсеш-үзгәреш булмауны тәнкыйтьләп язылган. «Безнең Казан» (1916 ел, 24 сентябрь) Казанның дини мәдрәсәләренең матди хәле авыр булуга ачынып иҗат ителгән.

Ф. Әмирханның 1917 елга кадәрге татар матбугатында башка газета-журналларда дөнья күргән мәкаләләре күп түгел. Алар да заказ белән язылалар, күрәсең. Әйтик, «Йолдыз»да «Уфада лекция» (Йолдыз, 1914, 18 февраль) мәкаләсе басыла. Анда Әмирхан Уфада Габдулла Шөнаси (1885–1938) лекциясе оештырылуны хупласа да, кимчелекләрен дә барлый, сүзен: «Гавам өчен булган лекция булдыгыннан мөмкин мәртәбә татарча итеп, һәркем аңлардаерак булуына игътибар ителсә яхшы булыр иде», дип тәгәлли.

«Мәктәп»тә Ф. Әмирхан «Исемнәрне татарчалаштыру мөнәсәбәте белән» (1914, 20 март) дигән язма бастыра, анда балаларга матур-матур татарча исемнәр куюны хуплый.

1917 ел инкыйлаблары Ф. Әмирханның көндәлек тормышын да, эшчәнлеген дә зур үзгәрешләргә китереп кертә. Аның бу дәвергә караган беренче публицистик мәкаләләре шушы вакыйгаларны татар халкының алгарышы өчен файдаланырга омтылып һәм алда торган бурычларны халыкка аңлату максаты белән язылганнар.

Күләмле «Инкыйлаб вә без» аналитик хезмәте «Кояш» газетасының 1917 елгы 7, 9, 12, 14, 17, 19, 21, 23, 27, 30 март һәм 4, 9,

11 апрель саннарында нәшер ителә, анда Февраль инкыйлабыннан соңгы вазгыятькә аналитик күзәтү ясала.

Әмирхан сүзне инкыйлабка кадәрге көннәрдән үк алып китә, Беренче бөтендөнья сугышы зур үзгәрешләргә китерәчәге сизелә иде, дип: «Без, сугыш башланып, аның йөзе ачык күренә башлаган көннән бирле, Русия мөселманнары өчен бер гомуми мөәссәсә вөҗүдкә китерү вә шуны хәятлы сурәттә эшләп тора торган җанлы бер организация уларак дәвам иттерүгә халыкны кызу-кызу өндәп карадык: мәҗрухларга (*яралыларга*) ярдәм өчен мәркәз комитет, мөселман фракциясе хозурында бюро ясау мәсьәләләренең куптарылулары, шаулатылулары, алар хакында әллә никадәр гасаби (*көчле)* нәрсәләр язып караулар – болар һәммәсе дә менә шундый бер организациягә оеткы ясап җибәрергә тырышу иде», татар иҗтимагый хәрәкәтенең, барыр кыйбласын ачык күзалласа да, максатына ирешмәвен, инкыйлаб дәверендә татар-мөселманнарга җитәкче булырлык бер үзәк, «Петроградтагы күземез, колагымыз» оешмауны зур үкенеч белән белдерә. «...менә шуның нәтиҗәсендә без ватанымыз хәятының иң куркынычлы, иң тантаналы вә иң олуг дәкыйкасында (*вакытта)* үземезнең башымызда тора торган, үземезнең кирәк дәкыйкада хәрәкәткә кушылып китәргә мөстәгыйд булуымызны тәэмин итә торган мөәссәсәдән мәхрүм булдык». Шул рәвешле, вакытлар үткән саен әһәмияте күбрәк күренә торган шушы сәяси җитешсезлекнең нинди нәтиҗәләргә китерәчәгенә ул үз заманында ук төшенә, бу безнең киләчәккә өметебезне шик астына куя дип әйтә.

Материалда Әмирханның вакыйгалардан бик яхшы хәбәрдар икәнлеге күренеп тора. Әйтик, ул: «Бу революцияне эшләп чыгаручы элемент, башлыча, рус демократиясе булса, Петроград гарнизоны арасында, иске идарә белән көрәшкән солдатларның йөз мең кадәрлесе татар һәм чирмеш вә чуваш милләтләренә мәнсүб (*караган*) солдатлар булган икәнлеге дә хәзер инде мәгълүм», дип искәртә. Кавемдәшләре кан коеп та, татарларның ил киләчәген билгеләүдә руслар һәм яһүдләр белән бертигез катнаша алмавы аның борчылу сәбәбенә әйләнә.

2 нче бүлек кавемдәшләрен берләшергә, ил һәм милләт язмышы хәл ителгән бер заманда вак ызгышлар белән вакыт уздырмаска чакырып башлана. Әмирхан 1905 елда милләтне оештырган һәм берләштергән «Иттифак әл-мөслимин» партиясен искә төшерә, шундый партия кирәклекне көн тәртибенә куя, «Иттифак...»ны тергезү яңа партия оештыруга караганда җиңелрәк дип санаганын әйтә, әлеге эшнең үзе күзаллаган планын да аңлатып уза.

3 нче бүлектә әдип Февраль инкыйлабына бәя бирә: «Ватанымыздагы соңгы ихтилал (*баш күтәрү*) үзенең тибы белән гаҗаиб, моңар кадәр тарихта мисалы күрелмәгән бер ихтилал булып чыкты: бу – бер сыйныфка гаид ихтилал түгел. Бу – аристократия ихтилалы булмаган шикелле, демократия ихтилалы гына да түгел; хәрби ихтилал гына да түгел, бәлки бөтенрусия гражданнарының, игътикадларда

(*инануларында)*, фикерләрдә, төп максатларда бер-берсеннән гаять ерак тора торган бөтен сыйныфларның ихтилалы иде»; аны бөтен халык, аның барлык катлаулары гамәлгә куйган хәрәкәт дип атый. Әмирхан кабат татарлардагы таркаулыкка кайта, аларның шушы хәлиткеч вазгыятьтә дә үзара каршылыкларын мәйданга чыгаруына ачынып, «Алдымызда милләтнең бер уч кадәр зыялы сыйныфы алдында, зурлыклары белән коточыргыч мәсьәләләр торган вакытта, бу мәсьәләләрнең һәрберсе иҗаби (*уңай)* эш таләп итеп торган дәкыйкадә, халыкның вакытын бушка сарыф иттерү, аның фикерен вак мәсьәләләргә бору – җинаятьтер».

Шушы фикерне 4 нче бүлектә үстерә барып, бердәмлекнең сәяси ягына күз ташлый: әдип төп өлешен сәясәттән ерак булган авыл халкы тәшкил иткән татар халкына бу вазгыятьнең нинди бурычлар йөкләгәнен күзәтеп бара, аңлату эшен көчәйтергә, вак фетнәләргә иярмәскә өнди. «Халкымызның олуг вә кечеге бер нәрсәне аңлап җитәргә тиеш: Безнең бөтен истикъбалемез, бөтен бәхетемез – хәзерге яңа тарзы идарәнең ныгып калуындадыр».

Әмирханның яңа идарәдән ни көткәнлеге алдагы 5–7 нче бүлекләрдә ачык күренә. Ул Россия империясендәге сәясәтне тәнкыйтьли, укучыларына Учредительное собраниенең әһәмиятен аңлата һәм аңа сайлауларда катнашуның мөһимлеген күрсәтә. 8 нче бүлектә әдип шул оешма хәл итәчәк дип фаразланган илдәге киләчәк хакимият идарәсе турында сөйли, падишаһлык (монархия) һәм җөмһүрият (республика) рәвешләренең уңай һәм тискәре якларын аерым-аерым күзәтеп чыга. Монархиянең Россия өчен үткән көн булуын ассызыклап, болай ди: «...халыкны берләштерә торган нәрсәнең падишаһ булмыйча, бәлки ватан мәхәббәте вә ватанның халкына бирә алган рәхәт вә сәгадәте булганлыгын уйларга тиеш буладыр». Татар халкының – ислам динендә яшәгән кавемдәшләренең – дөньяга карашларын бик яхшы аңлаган Әмирхан республика формасын мөселман дәүләтләренең тарихи чынбарлыгына каршы килми торган бер идарә рәвеше кебек тәкъдим итә. 9 нчы бүлектә исә кабат дөньядагы падишаһсыз идарә итела торган мәмләкәтләр хакында сүз алып бара һәм республика идарә системасын яклап, болай ди: «Төрле идарәләр белән яши торган мәмләкәтләр арасында, үзенең халкына иң күп иркенчелек, иң күп рәхәт вә сәгадәт бирә торган мәмләкәтләрнең бу көнге көндә җөмһүрият тарзы идарәсе белән идарә ителә торган җирләр икәнчелеге әхвәле галәм белән таныш булган һәркемгә мәгълүм хакыйкатьтер»; «җөмһүрият тарзы идарәсендә мәмләкәтнең баш хуҗалыгы бер кешенең мөстәбид (*үзенчә*) теләвенә тапшырылмыйча, халыкның үз кулында буладыр».

10 нчы бүлек газета укучыларын төрле илләрдәге сайлау системалары белән таныштыра, аларны икегә бүлеп, берсендә – сайлауда халыкның катнашуы аның салым түләү мөмкинлегенә бәйле икәнлеген, икенчесендә – «мәмләкәт идарәсе чын-чынлап бөтен халык теләгәнчә була», дип әйтеп, Әмирхан бу форманың «халык җөмһүрияте

(демократическая республика)» дип аталуын кабат искәртә. Аның фикеренчә, татарлар – «без – Русиядә тора торган милләтләрнең иң фәкыйре вә икътисади иң зәгыйфемездер. Безнең сәүдәгәрләремез – вак сәүдәгәрләр; безнең һөнәрмәндләремез – вак һөнәрмәндләр; милләтемезнең йөздән туксанын тәшкил итә торган крестьяннарымыз да малсыз, мөлексез фәкыйрьләрдән гыйбарәттер. Шуңар күрә, әгәр сайлауларга катышу өчен мал вә милек, яхуд мәгълүм бер микъдардан ким булмаган налог түләү шарт ителде исә, бу шарт һәрбер милләткә караганда безнең милләткә зарарлы тәэсир итәчәк, безнең милләтнең тавышын киметәчәктер». Әлеге икътисади эчтәлекле дәлилгә таянып, әдип татарларга дәүләт идарәсендә халык җөмһүрияте юлын сайларга кирәклекне төшендерә. Бу юлны ул Россиянең икътисади әхвәлен, андагы крестьяннарның матди хәлен яхшыртырга мөмкинлек бирү дип каравын да яшерми.

12 нче бүлектә автор бу юлны сайлауның әһәмиятенә «милли нoктаи назардан, үземезнең милли бөтенлегемезне саклавымыз ноктаи назарыннан» карый һәм болай дип белдерә: «Без Русия мөселманнарына үземезнең бөтенлегемезне саклар өчен иң әүвәлге вә иң мөһим чара – бөтен милли мәсьәләләремезнең үз кулымыз, үз ихтыярымызда булучылыгымыздыр; моның өчен безгә дини, милли һәм мәдәни автономияләр зарурдыр. Безнең миллиятемез генә түгел, динемез дә Русиянең башка әһалисенекенә караганда бөтен асылыннан бам-башка (*бөтенләй башка*) булганга, безнең хәзергә кадәр килгән бөтен ганганәтемез (*традицияләребез*), бөтен гадәтемез, бөтен тереклегемезнең рәвеше ватанымызда әксәрияты (*күпчелек*) тәшкил итә торган олуг рус милләтенекеннән бөтенләй аерым булганга күрә, безнең бу автономиямезгә гаскәри бүлекләремезнең аерым, махсус булучылыгы да кирәргә тиешдер. Ягъни безнең өчен ватанымызның миллиятләр федерациясе буларак идарә ителүе лябед (*котылгысыз*)».

Калган ике бүлектә Әмирхан Россиянең халыкара мәйдандагы сәясәтен игътибар үзәгенә куя һәм мөселман дәүләтләренә мөнәсәбәт, Төркестандагы мөселманнарның хәлен сөйли. Шушы урында Әмирхан тагын бер кат инкыйлабны яклап чыга: «Хода белә, әгәр бу инкыйлаб булмыйча, яңадан 25 ел бу хәл дәвам иткән булса, бу бичара мәмләкәтләр вә бичара Русия Төркестаны нинди мөдһиш (*куркыныч*) бер хәрабәгә әйләнер вә нинди бер терелмәслек рәвештә мөнкариз булып (*юкка чыгып*) өлгерер иде». Автор фикеренчә, шушы хәрабәләрне тергезер өчен күп көч һәм хезмәт сорала. «Тарихның барышы, гомуми әхвәлнең оешуы шул иҗади хезмәткә безне чакыра, шул иҗади хезмәтнең зур бер кыйсемен, шуның авыр башлангычын бездән, Урта Русия төркиләреннән, таләп итә; чөнки бу көндә без – Русиядәге төрки кабиләләрнең “иң” мәдәнисе, иң аңлысы вә зыялы көчләргә баерагымыз. Хәзерге әхвәлне аларга кирәкле рәвештә аңлатырга мөстәкыйд (*сәләтле*) бер халык булса, ул да – бездер. Аларны оештырырга, аларга һушларына килергә әүвәлге ярдәмне бирә торган бер табиб

булса, ул да бездән гыйбарәттер. Без моны бер төркестанлылар монафәга (*файда)* өчен генә түгел, бәлки үземезнең чын монафәгамыз өчен дә, бөтен милли монафәгамыз өчен эшләргә тиешләрмез».

Бу мөрәҗәгатьтә Ф. Әмирханның Февраль инкыйлабының Русиягә яңа якты тормыш алып киләчәгенә өмете дә, үз халкының акылы, көче, оештыру сәләте белән горурлануы да, татарларның үзләрен һәм башка төрки милләтләрне үсеш юлына куячагына ышаныч та ачык күренеп тора.

Шушы күләмле аналитик хезмәт артыннан ук Әмирхан «Аң» журналының 1917 елгы 3–4 нче (20 апрель) санында ярым әдәби, ярым публицистик «Богаулар өзелделәр» мәкаләсен (аны нәсер буларак бәяләргә мөмкин) бастыра. Бу әсәрне М. Мәһдиев: «Ф. Әмирхан публицистикасының Октябрь революциясенә кадәрге югары нокталарыннан берсе, – дип бәяли. – Самодержавиенең бәреп төшерелүен ул “богаулар өзелү”, “коллык мөһере” ватылу дип бәяли, царизмның моңа кадәр татарлар арасында алып барган реакцион политикасын гаепли» [5: 314].

Әдәби-эмоциональ рәвештә әдип: «Богаулар өзелделәр. Коллык мөһере ватылды! Олуг ватан Русиянең тарихта мисле күрелмәгән дәрәҗәдә муаффәкыятьле ихтилалы (*уңышлы чыккан революциясе*) бу көндә безне бөтен мөселман галәменә караганда мөстәсна (*аерым*) бер хәл алдына бастырды: безнең алда хәзер мең төрле якты вә нурлы имкяннар (*мөмкинлекләр*) торалар; бу көндә без, бөтен ислам галәменнән ялгыз без, бәни адәмнең дөньяда бәхетле яши торган кыйсеме белән бертөрле сәяси әхвәл эченә килеп кердек. Бу көннән соң безгә, ялгыз Русия мөселманнарына, Европада бөтен Европа әһалисе (*халкы)* белән бертигез хокуклы буларак көн итәргә имкян ачыладыр» [6: 324], – дип шатлана. Үткәндәге кысуларны санап уза һәм киләчәккә бурычлар билгели: «Менә ил корылтае (Учредительное собрание), менә җөмһүрият тәэсис итеиелү (*төзелү)*, менә җирләр мәсьәләсен катгый сурәттә хәл итеп, халыкның иң зур әксәриятен (*күпчелеген*) тәшкил итә торган крестьянны адәм хәяты белән тора алырлык икътисади хәлгә күтәрү, менә милләтләргә гадәдләренә мөтәнасиб (*халык санына карап)* вәкилләр сайлау хакы бирү, менә милләтләр автономиясе мәсьәләсе... Менә автономия мәсьәләсе, шул мәсьәлә генә, дини, милли, мәдәни автономия генә ватанда экаллият (*азчылык*) тарафында калган милләтләрнең бөтен ихтыяҗларын үти ала вә үтәгәндә дә инде шул милләтләрнең истикъбальләрен мәңгегә тәэмин итәрлек итеп үти аладыр» [6: 326]. Әмирхан менә шушы эшләрне мәйданга китерергә, моның өчен тырышырга, хезмәт куярга чакыра, «чөнки, – ди ул, – без Русиядә руслардан кала иң зур милләт, чөнки без башка гайре русларның һәммәсеннән артык автономиягә мохтаҗмыз». «Русиядәге гайре рус милләтләргә милли вә мәдәни автономия бирелү дигән сүз – безнең телемез, дарелфөнүннәрне хави (*эченә алган*) булган хәлдә ана телендә мәктәпләремез, дини эшләремезне идарә, бөтен дини вә милли хаҗәтләремез өчен милли фонд,

бәйрәмнәремез һәм мөселман гаскәрләрне хосусый полкларга аеру вә илх, вә илх (*һәм башка*) мәсьәләләремезнең һәммәсенең без теләгән рәвешчә хәл итүләре дигән сүздер ки, моның белән инде без истикъбальләре тәэмин ителгән бәхетле милләтләрнең берсе булып киткән буламыз» [6: 327].

Мондый аналитик һәм риторик, халыкны кузгатуга, берләштерүгә, аңа юл күрсәтүгә юнәлтелгән күләмле язмалар белән беррәттән, Ф. Әмирхан көн мәйданга чыгарган вакыйгаларга мөнәсәбәт белдерүдән дә туктамый. «Кояш» газетасында аның бер-бер артлы язмалары пәйда була. Габдулла Кариев бенефисы уңае белән сәхнәдә Г. Исхакыйның «Зөләйха» драмасы куелу хакындагы «“Зөләйха”» (Кояш, 1917 ел, 19 март); Г. Исхакыйның Казанга килү хөрмәтенә унбиштән артык татар оешмасыннан 160 тан артык кеше җыеп банкет оештыру турында – «Гаяз әфәнде шәрәфенә» (Кояш, 1917 ел, 11 һәм 13 апрель) һ. б. Әмирхан күзеннән тәнкыйтьләрлек күренешләр дә читтә калмый. «Вакытлы мөфти» (Кояш, 1917 ел, 23 март) руханилар С. Баязитов һәм Г. Капкаевның өй күзәтүе астына алынуы хакында сөйли. Аеруча «Епископ Андрейның каралыгы» (Кояш, 1917 ел, 27 март) мәкаләсе Әмирханның карашларын аңлау ягыннан кызык. Ул Вакытлы хөкүмәтнең Петроградка метрополит епископ Андрейны (Ухтомский) чакыруына нисбәтле. Әдип руханины эш-гамәлләре белән милләтара низаг чыгаруда, Февраль революциясеннән соң элекке фикерләреннән кайткан булып кылануда – икейөзлелектә гаепли, мондый кешеләрнең хөкүмәттә постлар биләргә тиеш түгеллеген мәсьәлә итеп куя. «Оят булды!» язмасы да (Кояш, 1917 ел, 1 август) игътибарны җәлеп итә. Ул 1917 елның 21 июль – 2 август көннәрендә Казанда узган Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаендагы бер күренешкә – Милли Шура исеменнән доклад укыган Мамлиев белән Токымбәтовның русча сөйләвенә мөнәсәбәт белдереп язылган. Бу мәкаләләр Ф. Әмирханның әле киләчәккә ышаныч белән янып, яңа вакыйгалар эчендә кайнавы турында сөйли.

Әмма хәл үзгәрә: 1918 елда Ф. Әмирхан «Шәрык кызы» журналында (1918 ел, № 2 (апрель)) бердәнбер мәкалә – «Тукай вә хатынкыз» дигән истәлеген бастыра. Бу хәлнең бер сәбәбе мәкалә астында аның үзе тарафыннан аңлатып узылган: анда Тукайның вафатын искә төшереп махсус әзерләнгән, Г. Исхакыйның һәм С. Рәмиевнең Тукайга багышланган мәкаләләре кергән «Ил» газетасының 13 нче саны «Галимҗан әфәнде Ибраһимов вә иптәшләре тарафыннан конфисковать ителгән» булу искәртелә. Күрәсең, цензура чиктән тыш көчәеп, Әмирханның турысын әйткән мәкаләләрен басмага уздырмый башлый. Бу хакта кайбер мәгълүматлар әдипнең көндәлекләрендә дә бар.

Инкыйлабтан соң да әдип Тукай иҗаты хакында язудан туктамый. «Тукай шигъриятенә багышланган мәкаләләр циклын йомгаклаган “Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим” (1923) мәкаләсе, тезислар рәвешендә булса да, шагыйрь тормышының әһәмиятле баскычларын, иҗатының төп сыйфатларын билгели. Ф. Әмирхан

Тукай иҗатын ул яшәгән татар мохите, иҗтимагый тирәлек белән тыгыз бәйләнештә карый. Кыскача гына тәрҗемәи хәленнән соң иҗат сызыкларына күчә. Аның кайгы-хәсрәт, моң баласы булуы искәртелә. Мәктәп-мәдрәсәләрдә алган тар гыйлем, төньякның “ярлы, мескен” табигате, “Казан белән Уральск арасында чикләнгән дөнья белән танышлык”, түбән зәвыклы, түбән фикерле, начар гыйлемле даирә, Ф. Әмирхан карашынча, Тукайның тумыштан бирелгән сәләтенә агылырга мөмкинлек бирмиләр» [7: 175–177]. Мондый каршылыклы кабул ителә торган һәм үтә кырыс тәнкыйтьнең бер сәбәбен Т.Ш. Гыйлаҗев әдипнең Тукай иҗатын «реаль тормыш, милли хәят, иҗтимагый тирәлек белән бәйләнештә аңлатырга» омтылуда, шулай ук совет идеологиясе тәэсирендә күрә [4: 118]. Моннан тыш, язманы укыганда Ф. Әмирханда Тукайга гына түгел, үзенә дә, XX гасыр башының илһамлы һәм милләтпәрвәр башка вәкилләренә дә сызланулы караш урнашуны, милләткә төшкән авырлыкларны – фәлсәфи күзлектән, язмыш сынавы итеп аңларга тырышуны да күрми мөмкин түгел.

1919 елда Ф. Әмирхан берничә генә, нигездә, татар дөньясындагы аерым вакыйгалар хакында хәбәр иткән мәкаләләр нәшер итә. Алар арасында әдипнең ялкынлы каләме Октябрь инкыйлабы булганнан соң, шуны хуплап, бер үк вакытта бер төркем коммунистларның татар-башкорт җөмһүриятен төзүгә каршы чыгуларына, шулай ук татарларда өстенлекле сыйныф буларак пролетариат сыйныфын игълан итүләренә тискәре мөнәсәбәт белдереп язылган «Ләфызпәрәстлек кенәме, лакейлыкмы?» (Кызыл Армия, 1919, 14 декабрь) мәкаләсендә генә күренә.

1920 елда Әмирханның публицист активлыгы terелгән, үзенә рух күтәренкелеге кайткан кебек тоела. «Кызыл Армия», «Эш» кебек газеталарда ул инкыйлабны яклап («Гражданнар сугышы һәм зыялылар»; Эш, 1920, 21 гыйнвар); Кызыл гаскәрнең җиңүен, Россиядән икътисади блокаданың алынуын котлап («Революциядә яңа дәвер»; Кызыл Армия, 1920, 28 гыйнвар) мәкаләләр бастыра. «Сәгать сукты!» (1920, февраль) мәкаләсендә, Әмирханга хас кайнарлык, эмоциональлек белән, ачлык бетеп туклык килеренә, төрле баскычтагы уку йортлары үсү-камилләшүгә, гыйлем, мәдәният, нәфис сәнгать чәчәк атасына ышаныч белдерелә. Әмирхан боларның барысын хезмәт кенә тәэмин итә ала дип яза. Алга таба иҗади хезмәткә өндәү аның һәр язмасында диярлек сызылып бара.

Шушы елны Әмирханның ярым-әдәби, нәсергә тартым берничә язмасы дөнья күрә. «Революция балалары (Яшь кызыл командирларга багышлана)» (Кызыл Армия, 1920, 18 март); «Шәрык уяна» (Кызыл Шәрык, 1920 ел, № 1) – шундыйлардан. Бәлки, монда әдәби барышның тәэсире дә роль уйнагандыр: заман алып килгән вакыйгаларны революцион пафос белән сурәтләү (М. Максуд, К. Нәҗми, Ф. Әсгать,

Ф. Бурнаш, Ш. Госманов һ. б.) ул еллар татар лиро-эпик әдәбиятында үзенчәлекле бер күренешкә әйләнә.

Әдип халыкара мөнәсәбәтләр мәйданындагы хәлләргә шатлануын да белдерә («Төрек милләтчелеге һәм Русия Советлар власте»; Кызыл Армия, 1920, 22 июнь), тәнкыйтен дә кызганмый («Яңа сугыш хәзерлеге һәм нефть»; Кызыл Армия, 1920, 15 апрель). Мәкаләләреннән аның, ихластан, «Татар Шуралар җөмһүрияте» – төзелеп, хезмәт белән халыкның якты киләчәккә чыгасына ышануы, шул хактагы өмете күренә әле. «Яңа имкяннар алдында» (Кызыл Армия, 1920, 25 июнь) мәкаләсендә ул моны туп-туры әйтә: «Бу җөмһүрият безгә үземездә калган тереклек теләге, тереклек омтылышы һәм тереклек куәтенең тышка чыгуына нәтиҗәле имкян бирергә тиештер. Бу җөмһүрият безгә, һәм җисмән, һәм рухан тәрәккый итеп, бәйнәлмиләлнең тигез хокуклы һәм тигез хәлле бер әгъзасы булу имкянын тудырырга тиештер. Бу җөмһүрият бездә адәмчелекнең чынлап та тәрәккыйга таба баруына ышанычны ныгытырга тиештер ки, шул имкяннар вә шул ышаныч кына адәмнәргә тереклек һәм тәрәккый юлында хезмәт итәргә көч бирә алалар» [6: 391]. Нәкъ менә 25 июньдә Татарстан АССР төзелә.

Әмирхан тормыштагы аерым күренешләргә бәйле язмалар бастыруын дәвам итә. Әмма аларда тәнкыйди караш кими бара, аны революцион пафос торган саен ныграк алыштыра. Узып киткән елга йомгак ясаган «1920 елда Шуралар Русиясе» (Кызыл дәфтәр, 1921, № 1) язмасы мондый нәтиҗә белән төгәлләнә:

«*Шулай итеп*

Без, хәзер генә үткәреп җибәргәнемез 1920 елдагы әхвәлемезне тикшереп карасак, бер нәрсә күрәмез: 20 ел безнең өчен әхвәлемезнең яхшыга таба үзгәрә башлау елы булды, мәшәкатьләрнең иң зурлары, газапларның иң ачылары инде артта калдылар, инде уздырылып җибәрелделәр. Бу мәшәкать, бу газапларны җиңеп чыккан революция инде һичбер вакытта җиңелмәслек дәрәҗәдә ныгыды.

*Яңа елга кергәндә*

Яңа елга кергәндә инде без гаять зур өмид һәм ышаныч белән керәбез. Бу ел безгә бер-бер артлы муаффәкыятьләр китереп торыр дип ышанамыз. Бу елга кергәндә без искиткеч дәрәҗәдә зур хуҗалык вә гыймарәт (*төзү*) планнары төзибез һәм эшче-крестьянның, Русия хезмәт халкының шул зур планнарны эшкә чыгарырлык көчкә малик икәнлекләрен дә бер дә генә дә шөбһә итмимез!

Эш! Эш! Армый-талмый хезмәт! Гайрәт, дәрт һәм киләчәккә ышаныч белән хезмәт!»

1921 елда Ф. Әмирханның, ачлар файдасына җыентыкка материал сорап мөрәҗәгать иткән Г. Ибраһимов үтенечен кире кагуы билгеле. Язучы үзе моны көндәлегендә хакыйкатьне күрсәткән язманы бастырмаячакларын белүе, ә ялган язарга теләмәве белән аңлата [3: 52–54].

Шуңа күрә бу елларда газета-журналларда басылган материалларының күбесе каләм тибрәтми тора алмаган шәхеснең күңелендәгесен түгел, мохит ишетергә теләгәнне язу булып тоела. Әдипнең көндәлекләрендә инкыйлабның максатына ирешә алмавы, советчыл системаның халыкны буйсындыруга корылуы, халыкның исә тагын да куркынычрак бер хаос мохитенә килеп керүе турында сызланулар теркәлә. Бу хакта Ф. Бәшировның фикере әдипне аңларга тырышуы белән игътибарга лаек: «Февраль революциясеннән соң “Богаулар өзелделәр. Коллык мөһере ватылды!” дип сөенеп, канатланып хәбәр биргән Ф. Әмирхан аннан соңгы вакыйгаларны инде якты хисләр белән генә кабул итә алмый. Беренчедән, үзе гомер буе хезмәт иткән, дөньяга килүләренә бар көчен куйган газета-журналлар ябылуын шатланып каршы алырга тиеш идемени ул? Халыкка озак еллар һәм нәтиҗәле, игелекле хезмәт итеп килгән “Шура”, “Аң”, “Кояш”, “Вакыт” кебек дәрәҗәле матбугатның 1918 елда чыгудан туктаулары, бик күп татар зыялыларын тәрбияләгән “Галия”, “Мөхәммәдия” кебек олуг мәдрәсәләрнең 1918–1920 елларда ябылулары, аерым китап нәшриятларының эшчәнлеге бетерелү – болар барысы да бөтен гомерен, бәхетен, сәламәтлеген татар халкына хезмәт итүгә багышлаган Ф. Әмирханга авыр тәэсир ясый» [2: 133]. Боларны дөрес шәрехләр өчен, Ф. Әмирханның көндәлекләре белән танышырга кирәк, әлбәттә.

Татар халкына мәхәббәте, олы ышанычы җуелмаган Әмирхан бу елларда да татарның зур шәхесләре хакында төпле язмалар белән чыгыш ясый. Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулу уңае белән Гыйльми үзәк тарафыннан 1925 елның 15 февралендә Татар дәүләт театры бинасында юбилей кичәсе уздырылу мөнәсәбәте белән язылган «Бу рухта беренче...» (Безнең юл, 1925, 3 (март)) язмасы татар мәгърифәтчесенә дәлилләп олы бәя бирүе белән аерылып тора.

Ф. Әмирхан татар тормышында да, ил язмышында, дөньяда да давыллы-гарасатлы дәвердә яши. Илдәге олы үзгәрешләр аның тормышына да, иҗатына да килеп орыла, аның үзен сынаулар, үкенечсызланулар аша узарга мәҗбүр итә, тик рух ныклыгын, татар милләтенең якты киләчәгенә ышанычын тулысынча юк итә алмый. «Октябрь инкыйлабыннан соң ул очар канатлары каерылган тау бөркетенә охшап калды. Күбрәк җан асрауны күздә тотып гамәл кылган публицистикасында шактый гына үрләр яуласа да, “Татар кызы”, “Хәят”, “Кадерле минутлар” кебек сәнгать әсәрләренә торырлык яңа җәүһәрләр иҗат итү аның өчен вөҗүдкә ашмаслык хыялга әверелде. “Хәят”ның икенче кисәге дә, “Урталыкта” романының дәвамы да күренмәде. Аның 1917 елдан соңгы иҗат җимешләрен нинди генә бизмәннәргә салып үлчәсәк тә, әсәрләреннән, бигрәк тә көндәлек һәм хатларыннан, тыенкы рәвештә акланмаган өмет, яуланмаган ирек, җәрәхәте җуелмас фаҗига сулышы бөркелеп тора» [1: 332].

Әмма 40 яшендә бакыйлыкка күчкән, шуның соңгы 7–8 елын изоляциядә, теләгәнен яза алмыйча яшәгән Ф. Әмирхан калдырган

әдәби мирас, публицистик байлык үзенең тирәнлеге, колачы белән дә, хәтта күләме белән дә таң калдыра. Һәр хәрефне кулдан язып, кулдан җыеп бастырган заман бит бу! Әмирхан кебек үз милләтенә, халкына хезмәт итәр өчен, аны никадәр яратырга кирәк!...

**Әдәбият**

1. *Әмирханов Р.* Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 384 б.

2. *Бәшир Ф.* Сөйлә, каләм! Әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 142 б.

3. *Вәлиев Н.М.* Фатих Әмирхан һәм совет хакимияте (Әдипнең куен дәфтәрләре. 1921–1926) // Фатих Әмирхан: традицияләр һәм заманчалык: Тууына 120 ел тулуга багышланган республикаара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2006. Б. 52–54.

4. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман: Тукай фәне. Әдәби тәнкыйть. XX гасыр башы татар әдәбиятында традицияләр һәм яңачалык / Кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

5. *Мәһдиев Мөхәммәт.* Сызып ак нур белән...: шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр / [төз. Г. Хәсәнова; кереш сүз авт. Д. Заһидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 583 б.

6. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т.: Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

7. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Загидуллина Дания Фатиховна,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник*
*отдела литературоведения Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*zagik63@mail.ru*

УДК 82(093.3)

*Э.М. Галимҗанова*

# ФАТИХ ӘМИРХАН КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ НИ СӨЙЛИ?

Дневниковые записи выдающегося татарского писателя, публициста и общественного деятеля Фатиха Амирхана хранятся в Центре письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова. Эти материалы, хотя и были написаны в короткий промежуток времени – с октября по декабрь 1921 года, – имеют огромное историческое значение. Они служат важным источником, раскрывающим трагическую реальность эпохи советской власти. Кроме того, эти записи позволяют оценить Фатиха Амирхана как личность, критически относящуюся к некоторым аспектам советской политики.

Основная часть дневников посвящена событиям голода 1921 года. Автор называет эту трагедию «третьим голодом за четверть века» и особо отмечает её тяжёлые последствия для татарского народа Поволжья (Идель-Камы). В своих записях он резко критикует партию большевиков и татарских коммунистических деятелей за их роль в ухудшении положения татарских крестьян.

В представленной дневниковой записи Ф. Амирхан поднимает проблему свободы печати в советский период. Как следует из этих материалов, автор отказывается предоставить статью для сборника под названием «Ярдәм мәҗмугасы» (Сборник помощи), организованного под руководством Галимджана Ибрагимова для оказания поддержки голодающим. То, что отрывки из этих записей были опущены в ранее изданных многотомниках Фатиха Амирхана, затрудняло выяснение причин его отказа. В действительности же, автор написал статью о голоде. В ней он не оправдывал действия советской власти и не желал представлять бедствие голода, пришедшее в Поволжье, исключительно как «наследие самодержавия». По этой причине статья не была опубликована.

Таким образом, Ф. Амирхан, работая журналистом с 1906 года, сравнивает цензуру царского периода, Временного правительства (которое он называет «эпохой подлинной свободы печати») и советского времени. Он демонстрирует беспрецедентное подавление свободы слова и мысли, отмечая, что даже царская цензура не казалась ему такой суровой, как «нынешняя большевистская свобода печати».

Записи в дневниках стали для Фатиха Амирхана единственным способом зафиксировать свои мысли в условиях ограниченной свободы слова. К сожалению, «Дневниковые записи» автора до сих пор не были опубликованы в полном объеме. Впервые они были представлены в 6-м томе шеститомного академического издания Фатиха Амирхана.

**Ключевые слова:** татарская литература, текстология, свобода печати, Фатих Әмирхан, дневники.

The personal records of the prominent Tatar writer, publicist, and public figure Fatih Amirhan are preserved in the Written Heritage Center of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and Art. Although these materials were written within a short period – from October to December 1921 – they hold immense his-

torical significance. They serve as a crucial source, revealing the tragic reality of the Soviet era. Furthermore, these entries allow Fatih Amirhan to be assessed as an individual who held a critical stance towards certain aspects of Soviet policy.

The main part of the diaries is dedicated to the events of the 1921 famine. The author refers to this tragedy as the “third famine in a quarter-century” and specifically highlights its severe consequences for the Tatar people of the Volga-Kama region. In his notes, he sharply criticizes the Bolshevik party and Tatar communist figures for their role in exacerbating the plight of the Tatar peasants.

In the presented diary entry F. Amirhan addresses the problem of press freedom during the Soviet period. As these materials indicate, the author refused to provide an article for a collection titled “Yärdäm mäjmugasï” (Aid Collection), organized under the leadership of Ghalimjan Ibrahimov to support the starving. The omission of these excerpts from Fatih Amirhan’s previously published multi-volume works made it difficult to ascertain the reasons for his refusal. In reality, the author had submitted an article about the famine to a newspaper. In it, he did not justify the actions of the Soviet authorities and did not wish to present the famine that struck the Volga region solely as “the legacy of autocracy.” For this reason, the article was not published.

Consequently, F. Amirhan, who had worked as a journalist since 1906, compares the censorship of the Tsarist period, the Provisional Government (which he calls “the era of genuine press freedom”), and the Soviet era. He demonstrates an unprecedented suppression of freedom of speech and thought, noting that even Tsarist censorship did not seem as severe to him as “the current Bolshevik press freedom”. This passage also examines the everyday hardships faced by Amirhan, linked to the Soviet government’s policy of “housing compaction” (uplotneniye). Writing in his diaries became Fatih Amirhan’s only means of recording his thoughts in conditions of restricted freedom of speech.

Unfortunately, the author’s “Diary Entries” had not been published in full until now. They were first presented in the 6th volume of Fatih Amirhan’s six-volume academic edition.

**Keywords:** Tatar literature, textology, freedom of the press, Fatih Amirhan, diaries.

Күренекле татар язучысы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның көндәлекләре Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана. Бу язмалар кыска вакыт аралыгына, – 1921 елның октябрь–декабрь айларына гына карасалар да, тарих өчен гаять зур әһәмияткә ия. Алар совет хакимияте чорының фаҗигалы чынбарлыгын ачыклауда мөһим чыганак булып хезмәт итә. Шулай ук әлеге язмалар Фатих Әмирханны совет сәясәтенең кайбер якларына тәнкыйди караштa торган шәхес буларак бәяләргә мөмкинлек бирә.

Көндәлекләрнең төп өлеше 1921 елдагы ачлык вакыйгаларына багышлана. Әдип бу фаҗиганы «чирек гасыр эчендә өченче ачлык» дип атый һәм ачлыкның Идел-Кама буендагы татар халкы өчен авыр нәтиҗәләрен ассызыклый. Биредә ул большевиклар партиясен һәм татар коммунист эшлеклеләрен татар крестьяннарының хәлен авырайтудагы роле өчен кискен тәнкыйтьли.

Тәкъдим ителгән көндәлек язмада Ф. Әмирхан совет чорында матбугат иреге проблемасын кузгата. Язмадан аңлашылганча, ул Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендә ачларга ярдәм итү өчен оештырылган «Ярдәм мәҗмугасы» исемле җыентыкка материал бирүдән баш тарта, һәм әдипнең элек басылган күптомлыкларында көндәлектән бу өзекләрнең төшереп калдырылуы моның сәбәбен ачыклауны кыенлаштыра иде. Чынлыкта исә, әдип бер басма өчен ачлык хакында мәкалә язган була инде. Анда ул совет хакимиятенең гамәлләрен акламый һәм Идел буена килгән ачлык афәтен «самодержавие мирасы» гына итеп күрсәтүдән баш тарта. Шул сәбәпле мәкаләне бастырмыйлар.

Шуңа күрә 1906 елдан бирле журналист булып эшләгән Ф. Әмирхан, патша чоры, Вакытлы хөкүмәт (аны ул «чын матбугат иреге чоры» дип атый) һәм совет чоры цензураларын чагыштырып, сүз һәм фикер ирегенең моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә бастырылуын күрсәтә һәм патша цензурасы да аңа «хәзерге большевистик матбугат иреге» кадәр авыр тоелмаганын ассызыклый.

Беренче тапкыр көндәлекләр тулысынча Фатих Әмирханның алты томлы академик басмасының 6 нчы томында тәкъдим ителде.

*7.X.1921*

Күптән инде мин бер көндәлек дәфтәр башлап җибәрүне кирәксенеп йөрим. Революция башыннан бирле шундый бер дәфтәр язып килгән булсам, хәзергә кадәр нихәтле хатирәләр, нихәтле хиссият, нихәтле көндәлек иҗтимагый вакыйгалар анда әбъят ителгән[1] булыр иде инде. Ничә мәртәбәләр омтылдым, ләкин кыйсмән обломовлык, кыйсмән бик күп шәхси хиссиятемнең үз вафатымнан соң булса да матбугатка чыгу ихтималын теләп бетермәү хәзергә кадәр моңар манигъ[2] булып килделәр. Менә бүген инде «Бисмилла» дип башлап багам. Дәвам иттерә алырмынмы, юкмы – киләчәк күрсәтер.

Бу «Көндәлек»тә вакыйгаларны мин үз шәхесемә булган мөнәсәбәтләре ягыннанрак язачакмын: шулай итмәгәндә, халис[3] нәзари фәлсәфә сатуга керешелеп кителү ихтимал – бу бер. Икенче – «Көндәлек»нең вазифасы да, минемчә, шул бит: ягъни вакыйгаларга минем шәхси мөнәсәбәтемне белдерү. Бу «Көндәлек»тә мин кайбер бик вак нәрсәләрне дә әбъят итәчәкмен. Ләкин аларның я бер, я икенче ноктаи нәзардан[4] характерный бер вакыйгалар булучылыкларын күз алдында тотачакмын: мәсәлән, бүген базарда шалкан ни бәһа булганын язам икән – аның инде үземчә гомуми тормышны күрсәтүдә бер әһәмияте булган булыр.

[1] Әбъят ителгән – теркәлгән.
[2] Манигъ – тоткарлык.
[3] Халис – чиста, чын.
[4] Ноктаи назардан – караштан, күзлектән.

*8.X.1921*

Галимҗан Ибраһимов редакциясе астында ачлар файдасына бер мәҗмуга чыгарырга карар биргәннәр икән. Галимҗан миңа бер табаклык материал хәзерләп, шул мәҗмугада мөшарәкәт итәргә[1] әйттергән. Хәбәрне алгач та, мин бер нәрсә дә язмаска карар бирдем. Әле моннан ун гына көн әүвәл ачлар файдасына олуг гәүдәле бер гәзитә номеры чыгарганнар иде. Бу гәзитәгә миннән дә бер мәкалә сораганнар, мин һәм язып җибәргән идем. Ләкин басылмады. Мәкаләнең мөндәриҗәсе[2] болай иде: «Менә соңгы чирек гасыр эчендә генә инде бу ачлык Русиядә өченче мәртәбә. (Боларның һәр өчесендә ачлыкка иң каты мәгъруз калган[3], аннан иң каты җәфа чиккән гонсыр[4] Волга һәм Кама буйлары тирәсенәрәк утырган татар халкы булды. Истибдад[5] дәверендә ачлыктан иң күп җәфа чиккән татар халкының инде революциядән соңгы әүвәлге ачлыкка да мәгъруз калуы, бу яктан социальный революциянең без татарларның хәлен үзгәртә алмавы безнең икътисади яктан иң зәгыйфь гонсыр икәнебезне күрсәтә. Социальный революциянең һәм аның белән власть башына килгән партиянең вазифасы – икътисади иң зәгыйфь гонсырларны артыграк күтәрергә тырышу, аларны Бәйнәлмиләлнең[6] тигез әгъзасы хәленә китерүгә зур әһәмият бирү. Менә безнең власть тирәсендә тора торган партияле иптәшләр шуны ачык аңлыйлармы, юкмы? Бер кыйсме аңлый, бер кыйсме аңламый. Менә шуны әүвәл үземез аңлап бетеп, аннан соң башкаларга аңлатсак, безнең тарафтан ачларга иң зарури ярдәм һәм бүләк бирелгән булыр» – менә шушы мәфһүмнән[7] иде мәкалә. Партияле иптәшләр минем ул мәкаләне укучыларга гарыз итәргә[8] теләмәделәр. Алар миңа «әүвәлге еллардагы ачлыклар» мәүзугысына[9] язарга заказ биргәннәр иде. Аларча партиясез бер мөхәррир каләме белән «Бу елгы ачлык – бары самодержавиедән калган мирас, бу тугрыда хәзерге властьның һичбер төрле гөнаһы юк, ачлыктан шәһәр урамнарында үлә торган крестьянның әхвәлдән бераз хәбәрдар булган кыйсме юкка гына Сәедгалиев – Борһан Мансуровлар партиясен ләгънәтләп үлә», дип язылып калырга кирәк иде.

Мин алай дип яза алмадым. Чөнки моннан әүвәл властьта торган, мәркәзнең менгезүе белән властьта торган Сәедгалиев – Борһан Мансуровлар агымының бу ачлыкны татар гонсыры башына китерүдә бик зур рольләре барлыгын, мәркәзләр алдында тәлинкә тоту наменә

[1] Мөшарәкәт итәргә – катнашырга.

[2] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.

[3] Мәгъруз калган – дучар булган.

[4] Гонсыр – токым.

[5] Истибдад – деспотизм.

[6] Бәйнәлмиләл – Интернационал, Халыкара оешма.

[7] Мәфһүмнән – мәгънәдән, эчтәлектән.

[8] Гарыз итәргә – җиткерергә, тәкъдим итәргә.

[9] Мәүзугысына – темасына.

аларның татар крестьяннарыннан, хәтта мәркәздән тәгайен ителгән[1] микъдардан артык иген гасблауларын[2], җирле большевикларның татар авылларына разверстканы гаять тарафгиранә[3] салып, бөтен крестьян хуҗалыкларын аяктан екканлыкларын, әүвәлге татар кеч-кенә чиновник һәм татар полиция ундерлары тибының бары иләк ягы белән әйләндереп, кызыл буяуга буялганнарыннан гыйбарәт булган Сәедгалиев – Мансуров фиркасенең бу эштә бер дә шөбһәсез кабахәт бер гамәлләр икәнлекләрен мин бик яхшы беләидем.

Галимҗан Ибраһимов мәҗмугасында мин ачлык турысында ул теләгән рәвештә язылган мәкалә бирә алмыйм. Бу мәсьәлә минем өчен артык үткен һәм артык газаплы мәсьәлә. Үзләре генә буялсын-нар, халыкка эшләгән кара җинаятьне яшерүенә үзләре генә мәсьүл[4] калсыннар.

Мин – 1906 елда журналистлыкка аяк баскан кеше, ягъни нисбәтән шактый карт татар журналисты. Мин – Николай цензура-сының иң кара вакытында, Керенский заманасында да гәзитәләрдә эшләгән кеше, ләкин мин һичвакытта матбугат хөрриятенең бу кадәр тапталганын, матбугат һәм фикер хөрриятенә бу кадәр богау салын-ганын үз өстемдә хис иткәнем юк иде. Николай вакытында безнең теңкәгә тия иде. Ашмарин, яисә Катанов өйдә булмаган вакытларда алар урынына калып тора торган Миргаяз Иманаев, шуннан башка-ларның цензорлыгы минем өчен хәзерге большевик хөррияте матбу-гатыннан авыр түгел иде. Керенский дәверендә исә мин чын-чынлап хөррияте матбугатны хис итеп калган идем.

*Басмага әзерләде:*

***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире*

*К печати подготовила:*

***Галимзянова Эльмера Махмутовна,***

*кандидат филологических наук, заведующий отделом текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*elmera.galimzyanova@mail.ru*

[1] Тәгайен ителгән – билгеләнгән.

[2] Гасблауларын – тартып алуларын, талауларын.

[3] Тарафгиранә – тарафдарча, үз кеше буларак.

[4] Мәсьүл –җаваплы.

УДК 398

*К.М. Миңнуллин*

# ХАЛЫК ИҖАТЫНДА ХУҖА НАСРЕТДИН ОБРАЗЫ
## (Хуҗа Насретдин мәзәкләренең Казанда басылуына 180 ел тулу уңаеннан)

Статья посвящена исследованию образа Ходжи Насретдина и корпуса татарских народных мэзэков, связанных с этим персонажем. Цель исследования – определить значение мэзэклэр о Ходже Насретдине в контексте восточной фольклористики и выявить специфику их изучения в рамках татарского народного творчества. Актуальность работы подчеркивается 180-летием со дня первой публикации сборника текстов этого жанра в Казани в 1845 году и недостаточной изученностью этой темы в татарской фольклористике. В исследовании проанализирована динамика публикаций текстов о Ходже Насретдине на татарском языке. После первого издания 1845 года последовал перерыв, после которого в 1881 году был выпущен тиражом 4200 экземпляров сборник «Лэтаиф Хуҗа Насретдин», переиздававшийся вплоть до Октябрьской революции около тридцати раз. Выделен период стагнации в 1920-е годы XX века, когда и публикация текстов, и их научное изучение практически прекратились. Особое внимание уделено новому этапу в исследовании жанра, связанному с деятельностью писателя Абдуллы Ахмата и ведущих татарских фольклористов. Образ Ходжи Насретдина, уходящий корнями в классическую восточную литературу и фольклор, рассматривается как межнациональный культурный феномен, с особым вниманием к его месту в татарской фольклорной традиции.

**Ключевые слова:** фольклор народов Востока, Ходжа Насретдин, татарская фольклористика, мэзэки.

This article examines the image of Khoja Nasreddin and the corpus of Tatar folk mezeks associated with this figure. The aim of the study is to determine the significance of mezekler about Khoja Nasreddin in the context of Eastern folklore studies and to identify the specifics of their study within the framework of Tatar folklore. The relevance of the study is emphasized by the 180th anniversary of the first publication of a collection of texts in this genre in Kazan in 1845 and the insufficient study of this topic in Tatar folklore studies. The study analyzes the dynamics of the publication of texts about Khoja Nasreddin in the Tatar language. After the first publication in 1845, there was a hiatus, after which in 1881 the collection «Lataif Khoja Nasreddin" was published in a print run of 4,200 copies and was reprinted approximately thirty times until the October Revolution. A period of stagnation in the 1920s is highlighted, when both the publication of texts and their scholarly study virtually ceased. Particular attention is given to a new stage in the study of the genre associated with the work of the writer Abdullah Akhmat and leading Tatar folklorists. The image of Khoja Nasreddin, rooted in classical Eastern literature and folklore, is examined as a transnational cultural phenomenon, with particular attention to his place in the Tatar folklore tradition.

**Keywords:** folklore of the peoples of the East, Khoja Nasreddin, Tatar folklore studies, mezeki.

Фольклор дөньясында халык мәнфәгатьләрен яклаучы, аның әдәп-әхлак нормаларын һәм күңел тойгысын яктыртучы образ булып формалашкан Хуҗа Насретдин персонажы гасырлар дәвамында Якын Көнчыгыш, Урта диңгез буе дәүләтләре, Урта Азия һәм, гомумән, Евразия континенты халыкларында киң тарала.

Көнчыгыш классик әдәбияты һәм борынгы фольклоры нигезендә туып, алга таба күп халыкларның иҗат җимешенә әйләнгән бу образ һәр халыкның үз гореф-гадәте, шаян-тапкырлык сыйфатлары, җирле характер белән баетыла, шундагы сүз осталары, халык геройлары белән янәшә яши, аларга конкурент була, популярлык казана. Һәр халык аны үзенчә исемләп йөртә. Төрекләрдә ул – Хуҗа Насреддин яисә Бу Адәм, таҗик һәм үзбәкләрдә – Әфәнде яисә Насреддин Хуҗа, азәрбайҗаннарда – Мулла Насреддин, карачай-балкарларда – Хуҗа, Хуҗа Насреддин, Мулла, Әфәнде, казахларда – Кужанасыр, кытайларда – Аванти (ягъни Әфәнде).

Хуҗаның кайчан һәм кайда тууы, нинди һөнәр иясе булуы, хәтта кайда җирләнүенә багышланган күптөрле эзләнүләр, фаразлы язмалар басыла тора. Һәр халык аны үзенеке дип таный. Әмма, әйтергә кирәк, бу сорауларга җавап ниндидер ышандырырлык мәгълүматларга, документларга нигезләнмәгән. Дөньяның төрле илләрендә әлеге фольклор герое турындагы мәзәк җыентыклары дөнья күрә, сәхнә әсәрләре иҗат ителә һәм сәхнәләштерелә, кинофильмнар төшерелә, аның образын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр дә языла тора.

Бу популярлык Хуҗа Насретдин мәзәкләренең халыкара фольклорга әйләнеп киткәнлеген күрсәтә дә инде. Шуннан чыгып, 2022 елда Азәрбайҗан, Иран, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Төркия һәм Үзбәкстан дәүләтләре тәкъдиме белән Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләрне сөйләү традициясе ЮНЕСКОның Дәүләтара комитеты сессиясендә Кешелекнең материаль булмаган мәдәни мирасы җәүһәрләре исемлегенә кертелә [8].

Хуҗа Насретдин татар халкында да бик популяр. Аны бездә Хуҗа Насретдин дип тә, Хуҗа әфәнде яисә Хуҗа гына дип тә йөртәләр. Татарларның Көнчыгыш халыклары белән бик күптәннән килгән икътисади бәйләнешләре мәдәни байлыкларга бер халыктан икенчесенә күчү мөмкинлеге бирә. Хуҗа мәзәкләре дә безгә әнә шул бәйләнеш аркасында килеп кергән. Ләкин аларның татар халкына кайсы гасырларда үтеп керүен анык билгеләү кыен [11: 6]. Ә менә Хуҗа Насретдинның, фольклорчы Х. Мәхмүтов сүзләре белән әйткәндә, Казанга беренче «рәсми визиты» 180 ел элек була, ягъни 1845 елда татар телендә махсус мәзәкләр китабы басыла [11: 6; 5: 103]. Әмма моңа кадәр әле Хуҗага күп гасырларга сузылган озын юллар үтәргә кирәк була.

Тикшеренүчеләр әйтүенчә, Хуҗа Насретдин образы инде XI–XIII йөзләрдә үк гарәпләрнең көлкеле хикәяләрендә Джуха исеме белән танылган герой булып яшәп, сәлҗукларда, аннан инде төрекләрдә яңача формалаша, яңа исем ала [2: 244]. Хуҗага бәйле беренче

гыйбрәтле хикәяләр исә 1480 елда Төркиядә «Салтукнамә» дип аталган китапта, соңрак, XVI гасырда, язучы һәм шагыйрь Джами Рума Ламия җыентыгында дөнья күрә [2: 249]. XVII гасыр ахырында исә Насретдинның Европа буйлап сәфәре башлана. Аның турындагы әсәрләр француз тәрҗемәчесе һәм Шәрык белгече Антуан Галланның Парижда чыккан «Paroles remarcables et maximes des orientaux» («Замечательные высказывания и изречения народов Востока») дип аталган мәзәкләр җыентыгында урын ала [4: 62] Шунысын да әйтик: әлеге тәрҗемә остасының исеме тарихка Европа халкына тәүге тапкыр «Мең дә бер кичә» әкиятләрен тәкъдим итүче буларак та кереп калган. XVIII гасырның 40 нчы елларында билгеле дәүләт эшлеклесе һәм галим Дмитрий Кантемир үзенең «История османского государства» хезмәте аша европалылар белән бергә россиялеләрне дә төрек теленнән тәрҗемә ителгән берничә мәзәк белән таныштыра [4: 62]. Әлеге хезмәт 1743 елда – француз, 1745 елда немец телләрендә дә басыла [10: 26].

Рус телендә махсус җыентыклар басылу турында мәгълүматыбыз юк, әмма XIX гасырның икенче яртысында әлеге мәзәкләрнең үрнәкләре, алар фәнни яктан өйрәнелә башлаган язмалар Кавказ, Кырым якларында, Киев, Санкт-Петербург һәм башка төбәкләрдә чыгып килгән «Кавказ», «Теркские ведомости», «Киевская старина», «Новое обозрение» кебек басмаларда еш күренә башлый [4: 63].

Мәгълүматларга караганда, Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләр җыентык булып тәүге тапкыр 1837 елда Истанбулның «Матбаа-и Амире» (Королевская типография) басмаханәсендә «Летаиф-и-Ходжа Насреддин» исеме белән дөнья күрә [2: 252] һәм алга таба төрек телендә Хуҗа Насретдин мәзәкләре җыентыклары шушы исем белән һәм башкача аталып, күп тапкырлар басыла.

Төркиядә махсус җыентык нәшер ителүгә озак та узмый, Хуҗа Насретдин мәзәкләре, тәрҗемә ителеп, 1845 елда Казанда Л. Шевиц атлы чит ил эшлеклесе типографиясендә басылып та чыга. Әйтергә кирәк, бу Казандагы беренче хосусый типография да булып тора. «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде» исемле әлеге җыентыкта 124 мәзәк урын алган. Китапның тиражы күрсәтелмәгән. Бу җыентык татар телендә беренче мәзәкләр китабы була.

Ләтаиф, берлек санда «ләтыйфә (гарәпчә-фарсыча-төркичә – мәзәк, анекдот, көлкеле, үткен мәгънәле кыска хикәят) – Шәрык халыклары фольклорында һәм әдәбиятында кече эпик жанр атамасы. <...> Башка халыклардагы кебек үк, бу жанрдагы әсәрләр татарларда элек-электән киң таралган. <...> XIX гасыр азакларында ләтыйфәгә параллель рәвештә мәзәк, “мәзах”атамасы кулланыла башлый. Бу хәл 20–30 нчы елларына кадәр дәвам итә» [1: 86], ягъни мәзәк сүзе киң таралыш алганчы, ләтыйфә атамасы көлкеле кыска хикәя мәгънәсендә йөри.

Шуннан соң татар телендә мәзәкләр бастыру эше шактый вакытка тукталып тора. Моңа Казандагы хосусый типографияләрдә татар

китабы бастыруның патша әмере белән берничә елга тыелуы, алга таба цензураның көчәюе дә тәэсир итми калмагандыр [3: 41, 44–46]. Нибары 1870 елда гына «Җамигъ әл-ләтаиф», 1873 елда «Мәҗмәгъ әл-ләтаиф» дип исемләнгән мәзәк җыентыклары басылып чыга. Хуҗа Насретдин мәзәкләренә исәноширләр 36 ел узгач кына әйләнеп кайталар. 1881 елда «Ләтаиф Хуҗа Насретдин» басмасы кабат нәшер ителә (күләме 32 бит, тиражы 4200 данә). «Татар фольклоры. Библиографик күрсәткеч»ендәге мәгълүматларга караганда, XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында Хуҗа Насретдин мәзәкләре 31 мәртәбә басыла [9; 6: 8]. Алар «Ләтаиф Хуҗа Насретдин», «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде», «Хикәят Хуҗа Насретдин», «Хикәятел Шәех Насретдин», «Шәех Насретдин әфәнде хикәясе» «Рәсемле ләтаиф Хуҗа Насретдин» һәм башка исемнәр белән дөнья күрәләр. Аерым басмаларның тиражы 10, 12 мең данәгә җитә һәм сериядәге җыентыкларның гомуми тиражы исә 100 меңнән арта. Октябрь инкыйлабына кадәр Хуҗа Насретдин мәзәкләренең соңгы басмасы 1916 елда «Кәримия» нәшриятында дөнья күрә. 1919 елда исә Казанда Ш. Хөсәенов варислары нәшерендә (ул вакытта 1-я государственная типография статусында) әлеге мәзәкләр сериясенә нокта куйган «Хуҗа Насретдин» җыентыгы басыла.

Бу җыентыклар күп тапкырлар басылып чыкса да, аларда аз гына үзгәрешләр белән бер үк текстлар кабатлана. Шуңа күрә 13 томлы «Татар халык иҗаты» тупламасының «Мәзәкләр» томын әзерләүчеләр аеруча беренче басмага нигезләнүләрен ассызыклыйлар [6: 350]. Шулай да, әкренләп, әсәрләрдәге тормыш-көнкүреш детальләре, вакыйга барган урыннар җирле шартларга якынайтыла, Хуҗа аралашкан даирә яңара. Беренче басмаларның тулысынча тәрҗемә әсәрләр икәнлеге, чор таләпләренә дә бәйле рәвештә аларның теле бүгенге укучы өчен шактый авыр булуы, XX гасыр башларындагы җыентыкларның исә тел-стиль ягыннан заманга яраклаша баруы билгеләнә [11: 219; 4].

1920 еллар башыннан халык авыз иҗатын җыю, бастыру, фәнни эзләнүләр алып баруга идеологик төсмер өстәлсә дә, төрле жанрлар буенча җыентыклар дөнья күрә тора, күпсанлы газета һәм журналларда халык иҗатына бәйле материаллар актив урын ала. Шул ук вакытта мәзәкләр аерым басма буларак кына түгел, вакытлы матбугат битләреннән дә югала. Әйтик, фольклор буенча библиографик күрсәткечтә югарыда телгә алынган мәзәкләр сериясе чыгу туктаганнан соңгы егерме елда мәзәк текстлары кергән басмалар теркәлми. Бары тик 1939 елда «Пионер каләме» журналының 5, 7 нче саннарында икешәр мәзәк тексты бирелә. 1941 елда шул ук журналның 1–3 нче саннарында «Хуҗа Насретдин әкиятләре» исеме белән мәзәк текстлары басыла.

Хаклы рәвештә, мәзәкләргә мондый карашның сәбәбе нәрсәдә булды икән соң дигән сорау туа. Жанр таләпләреннән чыгып, тормыштагы социаль мәсьәләләргә кагылу, төрле тискәре күренешләрне

сатира-юмор ярдәмендә генә фаш итүме?! Алай дисәк, нәкъ шушы елларда илнең төрле төбәкләрендә Хуҗа Насретдин мәзәкләрен төрекчәдән актив тәрҗемә итеп бастыру, халыктан яңаларын язып алып туплау, киң таралган фольклор образының тарихын, әсәрләрнең идея-эстетик кыйммәтен өйрәнү башлана. Әйтик, 1936 елда Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләрендә урнашкан, үз вакытында абруй казанган «Academia» нәшриятында 300 битлек «Анекдоты о Ходже Насрэд-дине» дип исемләнгән җыентык чыга. Мәзәкләрнең төрекчәдән тәрҗемәсе атаклы Шәрык белгече В.А Гордлевский тарафыннан башкарылган. Аның китаптагы бай һәм тирән эчтәлекле кереш мәкаләсе һәм искәрмә мәгълүматлары исә бүген дә зур фәнни әһәмияткә ия. Әлеге җыентык белән бер үк вакытта Кырым АССР дәүләт нәшриятында Алупка Дәүләт Музей-йорты тарафыннан «Анекдоты о Ходже Насреддине и Ахмет Ахае» исемле җыентык әзерләнә һәм 1937 елда басылып та чыга. Биредә урын алган Хуҗа Насретдин һәм Кырымның үз популяр фольклор персонажы Әхмәт Ахай[1] мәзәкләре исә шул елларда Музей-йорт фольклорчылары төркеме тарафыннан Кырым татар авылларында язып алынганнар. Оешманың яшь фәнни хезмәткәре С.Д. Коцюбинский ике йөз егермедән артык мәзәкне (унга якыны гына Әхмәт Ахай турында) рус телендәге басмага әзерләгән һәм «Оджа Насреддин и его место в крымском фольклоре» исемле сүз башы һәм искәрмәләрне язган. Күпсанлы чит ил чыганакларына да таянып язылган кереш мәкалә (50 биттән артык) юмор-сатираның дөнья әдәбиятында урын алуын, Хуҗа Насретдин образының барлыкка килүен, төрле халыклар иҗатында, аерым алганда Кырым җирлегендә аның таралу-популярлашу тарихын яктырта. Болардан тыш «Кабардинский фольклор» (М.-Л., «Academia», 1936), «Сто сказок о проделках муллы Наср-Эддина» (Пятигорск, 1937) басмаларын да атап узарга була.

Шулай да Хуҗа Насретдин образы татар халкы күңеленнән җуелмый. Язучы Абдулла Әхмәт, матбугат битләрендә мәзәк текстлары белән күренмәсә дә, 1942 елда «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» исемле җыентыкны дөньяга чыгара. Хуҗа мәзәкләренең Октябрь инкыйлабыннан соңгы беренче басманы төзүченең кереш сүзе «Данлыклы Хуҗа һәм аның турындагы атаклы мәзәкләр» дип аталган. Барлыгы өч тематик һәм мәзәк вариантлары бүлекчәләрендә 200 әсәр урнаштырылган. Элеккеге басмалардагы мәзәкләр белән бергә халыктан тупланганнары да бар. Информантлар исемлегендә язучы Абдулла Алиш, фольклорчылардан Гомәр Разин (язучы Гомәр Бәширов псевдонимы), Хәмит Ярми, Вәли Хаҗиевларны да күрәбез. Шушы рәвешле Хуҗа Насретдин мәзәкләре яңадан офыкларын киңәйтә.

50 нче елларда «Совет әдәбияты», «Чаян», «Азат хатын» «Ялкын», «Пионер» журналларында да ара-тирә Хуҗа турындагы

[1] Ахай Озынбашский (Хуҗа Насретдинның оныгы дип тә йөртәләр) Озынбаш авылында туган, диелә.

мәзәк текстлары басыла. Ә инде 1962 һәм 1966 елларда А. Әхмәт җыентыкның тулыландырылган икенче һәм өченче басмаларын әзерләп чыгара. Ике басманың да кереш мәкалә авторы – танылган фольклорчы Хәмит Ярми. Ул үз язмасында Хуҗа мәзәкләренең күпгасырлык үткән юлын, билгеле булган төп чыганакларны, татар телендә нәшер ителгән җыентыкларны барлый. Китапларның икенче басмасындагы «Төзүчедән бер-ике сүз» дип аталган язмасында мондый юллар бар: «Бу китапка, беренчедән, татар халкы арасында сөйләнеп йөри торган мәзәкләр тупланды. ...Аннары революциягә кадәр «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде» исеме белән басылып чыккан җыентыктан сайлап алып эшкәртелде. ...Шулай ук, ...рус телендә 1958 елда чыгарылган «Хуҗа Насретдин турында мәзәкләр» җыентыгыннан да күп кенә мәзәкләр тәрҗемә итеп алынды. Аларның барысы да төрек теленнән тәрҗемә ителгәннәр» [11: 219].

Хәмит Ярми мәзәкләрне барлау һәм җәмәгатьчелеккә тәкъдим итүгә карата фольклорчы галим буларак үз фикерен җиткерә һәм киләчәккә бу юнәлештәге бурычларны да билгели: «Хуҗа мәзәкләрен бастыру, аларны төрлеләндерүдә, башка барлык халыклар кебек үк, татар халкы да актив катнаша. Бигрәк тә Октябрьдан соң басылып чыккан җыентыкларда безнең халыкның тормыш-көнкүрешен һәм аның гореф-гадәтләрен чагылдырган мәзәкләр дә байтак очрый. Ләкин безнең халык арасында Хуҗа исеме белән туган мәзәкләрнең махсус рәвештә җыйналганы, өйрәнелгәне юк әле. Киләчәктә Хуҗа Насретдин мәзәкләре җыентыкларын үзебездә туган мәзәкләр хисабына баету якындагы мөһим бурычларның берсе булырга тиеш» [11: 9].

Хуҗа Насретдин мәзәкләре нигезле урын алган чыганакларның тагын берсе – «Татар халык иҗаты» тупламасының 1979 елда нәшер ителгән «Мәзәкләр» томы. Җыентыкның кереш, искәрмәләр һәм чыганаклар өлешендә Хуҗа мәзәкләренең тарихы, төп чыганаклары, образның татар дөньясында таралуы һәм аның татар халкы тарафыннан үз репертуарына иҗади үзләштерелеп кабул ителүе ассызыклана. Җыентыктагы 230 мәзәкнең күпчелек өлеше А. Әхмәт төзегән басмалардан сайлап алынса, дүрттән бере – татар вакытлы матбугатында чыккан, яисә фольклор фондларында теркәлгән материаллар. Тупламадагы искәрмәләр һәм чыганакларны анализлау да кызыклы гына мәгълүматлар бирә. XIX гасыр урталарында ук чыккан басмалар аша таралган мәзәкләрнең байтагы, эчтәлек һәм бигрәк тә тел-стиль ягыннан аерым үзгәрешләр кичереп, халык телендә яши һәм бүгенге китапларда да басыла икән. Биредәге Хуҗа турындагы мәзәкләрнең 40 тан артыгы 1845 елда нәшер ителгән беренче басмада ук урын алган булган, охшаш яки якын сюжетлылыгы ягыннан 70 тән артык мәзәк Азәрбайҗанда чыккан «Анекдоты Моллы Насреддина» (Баку, 1975) җыентыгындагы әсәрләр белән тәңгәл. Бу исә Хуҗа Насретдин мәзәкләренең чын мәгънәсендә халыкара фольклор байлыгы икәнен тагын бер кат раслый.

Фольклор әсәрләренең халыкара дәрәҗәгә күтәрелүендә яисә аерым персонажларның популярлык казануында басма хезмәтләрнең дә роле зур. Без моны Хуҗа Насретдин мәзәкләре төрек, Европа халыклары телләрендә дөнья күргән китапларга бәйле рәвештә дә күрдек. 1940–1950 елларда Л.В. Соловьев язган «Возмутитель спокойствия» һәм «Очарованный принц» әсәрләренең басылуы һәм шул ук елларда экранлаштырылуы, Хуҗа Насретдинны СССР киңлекләрендә яшәгән халыклар арасында гаҗәеп дәрәҗәдә популярлаштыруы – моның тагын бер ачык мисалы. Ә инде XIX гасыр урталарында Казанда «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде» җыентыгының нәшер ителүе һәм дистә еллар дәвамында зур-зур тиражлар белән кат-кат басылуы татар халкын гына түгел, Россиядагы күпсанлы мөселман халыкларына да мәгърифәтчелек, китапчылык юлына чыгарга этәргеч биргәндер. Төрек теленнән тәрҗемә аша кергән Хуҗа мәзәкләре чит җирлектә барлыкка килеп, башка тормыш-көнкүреш вакыйгаларын сурәтләсә дә, тора-бара халык телендә-күңелендә нык үзләшеп, төп герое милли персонаж булып китә һәм татар фольклорындагы мәзәк жанрын популярлаштыруда да зур роль уйный.

Әмма Хуҗа Насретдин мәзәкләренең татар телендә чыккан басмалары тарихын барлау аларның ил буенча фәнни әйләнешкә керү-кермәү мәсьәләсен дә китереп чыгара. Әйтик, В.А. Гордлевский, С.Д. Коцюбинскийларның 1930 елларга караган фәнни язмаларында күпсанлы басма чыганаклар барлана. Әмма дистә еллар дәвамында даими чыгып килгән һәм киң таралган Казан басмалары телгә алынмый. Соңгырак вакытка килсәк, 1986 елда Мәскәүдә 1200 дән артык мәзәкне эченә алган 622 битлек «Двадцать четыре Насреддина» исемле китап (төзүчесе М.С. Харитонов) дөнья күрә [10]. Басманың «Указатель текстов по национальностям» дип аталган күрсәткечендә мәзәкләрнең егерме дүрт халыктан тупланганлыгы күренә. Күпчелеге – СССРда яшәүче халыклар. Идел буе татарларыннан бары ун мәзәк алынган. Алар – әдәбият белгече, фольклорчы М.А. Васильевның 1928 елда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте басмасында чыккан «Татарские версии анекдотов Ходжи Насреддина» язмасына мисал буларак китерелгән мәзәк текстлары. «Ләтаиф» сериясе дә, А. Әхмәт төзегән җыентыклар да, академик басманың «Мәзәкләр» томы дә читтә калган. Димәк, һәр очракта да рус телле чыганаклар гына файдаланылган. Мәзәк жанрын фәнни яктан соңлап, 1960 елларда гына өйрәнә башлау, халык иҗаты әсәрләрен рус телендә бастыруның сүлпәнлеге – әлеге хәлнең төп сәбәпләредер.

Соңгы елларда «Татар халык иҗаты» тупламасының 15 томлыгы рус телендә чыгып килә. Шул исәптән «Мэзэки (народные шутки)» томы (Казань, 2017), кереш мәкалә, искәрмәләр һәм чыганаклары белән, аның нигезендә әзерләнгән «Татарская хитрость: Мэзэки (народные шутки)» (Казань, 2023) китабы рус телле җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Мондый басмаларны файдаланып, мәзәк жанрын

өйрәнү буенча махсус тикшеренүләр дә булыр һәм болар барысы да татар Хуҗа Насретдинына багышланган һәр төр чыганакны илкүләм фәнни әйләнешкә кертүгә уңай йогынты ясар.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.

2. *Гордлевский В.А.* Послесловие к сбор. «Анекдоты о Ходҗе Наср-эддине». Изд. 2. М., 1957. 278 с.

3. *Кәримуллин Ә.* Китап дөньясына сәяхәт. Татар басма сүзенең сәхифәләреннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 208 б.

4. *Коцюбинский С.Д.* Предисловие к сбор. «Анекдоты о Ходже Насреддине и Ахмет Ахае». Симферополь: Госиздат Крым. АССР, 1937. 367 с.

5. *Мәхмүтов Х.Ш.* Мәзәкләр // Татар фольклоры жанрлары. Казан, 1978. Б. 102–123.

6. *Мәхмүтов Х.Ш.* Татар халык мәзәкләре // Татар халык иҗаты: Мәзәкләр / төз.: Х.Ш. Мәхмүтов, А.И. Садыйкова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 390 б.

7. *Мәхмүтов Х.Ш.* Хуҗа Насретдин – Казанда // Социалистик Татарстан. 1983. 25 март.

8. Список шедевров устного и нематериального культурного наследия человечества – Википедия. URL: https://ru.wikipedia.org/wiki (дата обращения: 21.08.2025)

9. Татарский фольклор: 1612–2022: Библиографический указатель = Татар фольклоры: 1612–2022: Библиографик күрсәткеч. Казань, 2022. 480 с.

10. *Харитонов М.С.* Двадцать четыре Насреддина. М.: Наука, 1986. 622 с.

11. *Ярми Хәмит.* Хуҗа Насретдин мәзәкләре // Хуҗа Насретдин мәзәкләре / төз. һәм әдәби эшкәртүче А. Әхмәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. 232 б.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Миннуллин Ким Мугаллимович,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*minnullin.kim@yandex.ru*

УДК 81.272, 811.512.145

*А.Ф. Юсупов*

# АРХЕОЛОГИЯ, ТАРИХ ҺӘМ ЭТНОГРАФИЯ ҖӘМГЫЯТЕ: ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ РУХИ МӘДӘНИЯТЕН ҺӘМ ЭТНИК ТӨРКЕМНӘРЕН ӨЙРӘНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается роль Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете (*далее* – Общество) в изучении духовной культуры татарского народа. С момента основания Казанского университета одним из приоритетных направлений исследования стало изучение народов Поволжья и Приуралья, в том числе татар. Общество вело свою деятельность в 1878–1931 гг. и внесло большой вклад в изучение археологии, истории и этнографии народов данного региона, собрало вокруг себя крупных ученых, в том числе известных татарских специалистов.

Одним из основных направлений деятельности членов Общества было выявление образцов народной словесности, а также изучение живой речи, фиксация материалов, относящихся к отдельным говорам и диалектам татарского языка, сбор фактического материала, его научное толкование. Осуществлялись проверка и сопоставление текстов, публикация результатов исследований в нескольких вариантах: на языке оригинала, в транскрипции, в переводе на русский язык.

В ходе анализа выявляются основные этапы изучения проблем татарской диалектологии и этнографических групп татар в Казанском университете; установлены основные причины снижения интенсивности этнографических исследований в 20-е годы XX в. В работе особое внимание уделяется исследованию научной, издательской и экспедиционной деятельности членов Общества: анализируются научные исследования, определяется и подчеркивается их вклад в изучение проблемы этнографических групп татарского народа.

**Ключевые слова:** Общество археологии, истории и этнографии; археология, Казанский университет, духовная культура татар, диалектология, этнографические группы, татары-мишари, тептяри.

The article examines the role of the Society of Archaeology, History and Ethnography at Kazan University (hereinafter referred to as the Society) in studying the spiritual culture of the Tatar people. Since the founding of Kazan University, one of the priority areas of research has been the study of the peoples of the Volga and Ural regions, including the Tatars. The Society operated in 1878–1931 and made a great contribution to the study of the archaeology, history and ethnography of the peoples of this region, gathering around itself leading scientists, including famous Tatar specialists.

One of the main areas of activity of the Society members was the identification of examples of folk literature, as well as the study of living speech, recording of materials related to individual dialects and subdialects of the Tatar language, collection of factual material, its scientific interpretation. Verification and comparison of texts was carried out, publication of research results in several versions: in the original language, in transcription, in translation into Russian.

The analysis reveals the main stages of studying the problems of Tatar dialectology and ethnographic groups of Tatars at Kazan University; the main reasons for the decline in the intensity of ethnographic research in the 1920s are established. The work pays special attention to the study of scientific, publishing and expeditionary activities of the Society members: scientific research is analyzed, their contribution to the study of the problem of ethnographic groups of the Tatar people is determined and emphasized.

**Keywords:** Society of Archaeology, History and Ethnography, archaeology; Kazan University, spiritual culture of the Tatars, dialectology, ethnographic groups, Mishar Tatars, Teptyari.

Татар халкының рухи мәдәниятен, аерым этник төркемнәрнең формалашу тарихын, аларның яшәешен, тел мәсьәләләрен һәм этнографиясен өйрәнүнең бай тәҗрибәсе бар, әлеге юнәлештәге эш берничә гасыр дәвамында максатчан рәвештә алып барыла. Билгеле булганча, «татар сөйләм теленә һәм җирле сөйләшләргә, татар диалектларына караган материалларны теркәү, аларга теге яки бу күләмдә аңлатма бирү XVIII гасырның беренче яртысында ук башлана» [19: 37]. 1804 елда Казан университеты ачылу тюркология өлкәсендә фәнни эзләнүләрнең активлашуына этәргеч бирә. Уку йортында 1810 еллардан ук әлеге юнәлештә җанланыш күзәтелә, Казан университеты төрки тел белеме һәм тюркологик тикшеренүләр үзәгенә әверелә.

XIX гасырда Казан университетында татар халкының рухи мәдәниятенә һәм аерым этнографик төркемнәргә бәйле материалларны туплау, җирле сөйләм теленә һәм татар диалектологиясенә кагылышлы мәсьәләләрне тикшерү юнәлешендә алып барылган эшчәнлекне ике этапка бүлеп карый алабыз: «1) XIX гасырның беренче яртысы – университет ачылганнан алып, Көнчыгыш разряды Санкт-Петербург университетына күчерелгәнгә кадәр булган чор (1804–1854 еллар). Бу чор университетта татар телен укыта башлау; татар халкы тарихын, аның этнографиясен, татар телен өйрәнү юлындагы фәнни тикшеренүләрне киңәйтү, университетта Көнчыгыш разряды ачылу һәм аның эшчәнлеге белән бәйле; 2) XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы (1855–1917) – Көнчыгыш разряды Санкт-Петербург университетына күчерелгәннән алып, Октябрь инкыйлабына кадәр булган вакыт аралыгы. Бу этапта татар диалектларын өйрәнүдә университет каршында оешкан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзалары эшчәнлеге әһәмиятле роль уйный» [19: 38–39].

XIX гасырда татар диалектологиясе мәсьәләләренең фәнни югарылыкта өйрәнелә башлавы, җирле сөйләм үзенчәлекләрен туплау өчен мөмкинлекләр арту һәм кызыксынуның көчәюе дәүләт сәясәте, Россия хөкүмәтенең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнгән. Әлеге чорда татарлар компактлы яшәгән төбәкләрдә татар теле укытыла башлый һәм, «русларга татар теле укыту ихтыяҗыннан чыгып, ягъни миссионерлык максатларында, күптөрле практик кулланмалар төзелә, аларда җирле тел үзенчәлекләре дә чагылыш таба» [18: 11–12].

XIX гасырның икенче яртысында аерым этнографик төркемнәрне һәм татар сөйләшләрен фәнни өйрәнүгә Казан университеты каршында оешкан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (1878–1931, алга таба *Җәмгыять* яки *АТЭҖ*) эшчәнлеге зур этәргеч бирә. Ул 1877 елда Казанда узган IV Археология съездында (июль-август айларында) катнашучылар тәкъдиме белән оештырыла. Съездда Җәмгыятьнең уставы эшләнә һәм ул 1878 елның 18 мартында халык мәгарифе министры тарафыннан раслана. Әлеге көн Җәмгыятьнең оешу көне буларак тарихка керә. Аның беренче рәисе Казан уку округы попечителе П.Д. Шестаков (1826–1889) була, ул 1878–1883 һәм 1886 елларда идарә итә; алга таба АТЭҖ белән Казан университеты профессорлары җитәкчелек итәләр: 1884–1885 елларда С.М. Шпилевский, 1887 елда – Н.Н. Булич, 1888–1896 елларда – Н.А. Фирсов, 1896–1898 елларда – Ф.Г. Мищенко, 1898–1914 елларда – Н.Ф. Катанов, 1914–1918 елларда – М.М. Хвостов, 1919–1922 елларда – Б.Ф. Адлер, 1922–1924 елларда – К.В. Харлампович, 1924–1931 елларда – Н.Н. Фирсов. Җәмгыять җирле тарих һәм этнографияне өйрәнүче һәм яратучыларны, традицион халык мәдәнияте ядкәрләре белән кызыксынучыларны, Казан университеты профессорларын, төрле уку йортлары укытучыларын, дәүләт ведомстволарында эшләүчеләрне һәм белгечләрне, руханиларны һ. б. берләштерә. 50 елдан артык эшчәнлек дәвамында барлыгы 600 дән артык кеше анда әгъза булып тора, аерым елларда әгъзалар саны 100 дән 200 гә җитә.

Җәмгыять Идел буенда яшәгән халыкларның рухи мәдәниятен, тарихын һәм этнографиясен төрле аспектта өйрәнүне үзәккә куя. АТЭҖ элекке Болгар-Хәзәр һәм Казан-Әстерхан патшалыклары территориясендә, шулай ук аларга буйсынган җирләрдә яшәгән рус һәм рус булмаган башка халыкларның үткәнен һәм хәзергесен өйрәнү [11] максатын куя. Җәмгыять составында өч бүлек (археология, тарих һәм этнография бүлекләре) оеша, Археология һәм этнографик карта төзү комиссиясе эшли. Җәмгыять эшчәнлегендә 1920 елларга кадәр татар сөйләшләре буенча материаллар туплау, фәнни командировкалар оештыру һәм татар диалектологиясен өйрәнү традицияләре дә үсеш-үзгәреш кичерә.

Җирле халыкның тарихын һәм этнографиясен тикшерү процессында АТЭҖ әгъзалары халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлау һәм туплау юнәлешендә дә эзлекле эшчәнлекне башлап җибәрә. Текстларны филологик аспектта анализлау, фәнни әйләнешкә кертү (гадәттә, текстлар 3 вариантта тәкъдим ителә: чыганак телдә, транскрипциядә һәм рус теленә тәрҗемәдә) һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү белән дә шөгыльләнәләр. Җәмгыятьнең ярты гасырлык эшчәнлеге тарихында Идел буе халыкларының рухи мәдәниятенә кагылышлы бай мирас туплана, аерым этник төркемнәрнең һәм халыкларның фольклоры чагыштырма аспектта өйрәнелә. «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә басылган фәнни мәкалә һәм язмаларның бер өлешендә җирле халык теле тарихы, диалектология мәсьәләләре

тикшерелә, шулай ук палеография һәм текстология буенча хезмәтләр басыла.

XIX гасырның соңгы чиреге – XX гасыр башында Идел буенда һәм Урал алдында яшәгән рус булмаган халыкларның тарихын һәм этнографиясен өйрәнү өлкәсендә җанлану күзәтелә. Әлеге шартларда җирле этник төркемнәрне, шул исәптән татар этнографик төркемнәрен өйрәнүгә игътибар арта. АТЭҖ әгъзалары, шулай ук җәмгыять белән тыгыз элемтәдә торган галимнәр – В.В. Радлов, Е.А. Малов, Н.И. Золотницкий, В.К. Магницкий, В.А. Казаринов, Н.Ф. Катанов, Г.Н. Әхмәров һ. б. татарлар компактлы яшәгән төбәкләрдә булып, җирле халыкның сөйләм теле үрнәкләреннән материаллар туплыйлар, татар сөйләшләрен экспедицияләр оештыру юлы белән беренче мәртәбә өйрәнә башлыйлар. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: Идел буенда һәм Урал алдында яшәгән төрки халыклар арасында татарларның төрле этнографик төркемнәрен (көнбатыш диалект вәкилләре, типтәрләр, керәшен татарларын) тикшерүгә аеруча зур игътибар бирелә, аларның этнографиясенә караган шактый гына материаллар туплана һәм сөйләм теле үзенчәлекләре дә ачыклана.

Әлеге чорда татар сөйләшләрен тикшерүгә багышланган хезмәтләрдә һәм «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә басылган күпчелек мәкаләләрдә этнографик һәм тел үзенчәлекләре ягыннан Казан татарларыннан аерылып торган сөйләшләрне өйрәнү үзәккә куела. Мәсәлән, көнбатыш диалектны этнографик һәм лингвистик аспектта өйрәнүгә багышланган хезмәтләрнең күп булуы күзгә ташлана, аларда сөйләм үрнәкләреннән мисаллар китерелеп, фонетик һәм грамматик үзенчәлекләр күрсәтелә. Шуны билгеләп үтү зарур: Җәмгыятьнең гомуми утырышларының берсендә мишәрләр телен өйрәнү өчен махсус экспедиция оештыру турында карар кабул ителә [15: 449–450], шуннан соң көнбатыш диалект сөйләшләре максатчан рәвештә өйрәнелә башлый. Тикшеренүләрдә беренчел чагыштырма анализлар да ясала, аларның тел үзенчәлекләре казан арты һәм керәшен татарлары сөйләшләренә хас фонетик, грамматик үзенчәлекләр белән чагыштырыла. Шушы юлда Җәмгыять әгъзаларының, җәмгыять белән тыгыз элемтәдә торган галимнәрнең, миссионерларның аерым көнбатыш диалект сөйләшләрен өйрәнү юнәлешендә шактый гына тикшеренүләр үткәргәнлеге мәгълүм.

В.А. Казаринов (1841–1893) – археолог, тарихчы, төбәкне өйрәнүче, Казан губернасының халык училищелары инспекторы, археологлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Ул 1879 елның 16 апреленнән Җәмгыятьнең әгъза-хезмәткәре; археология белән шөгыльләнә, Болгарда казу эшләре алып бара. В.А. Казаринов Чистай өязендә яшәгән мишәрләрнең этнографиясен һәм сөйләм теле үзенчәлекләрен тикшерә [5]. Ул аларның сөйләмендә рус сүзләренең аеруча еш кулланылуына игътибар итә һәм керәшен татарлары теле белән белән чагыштырганда рус алынмаларының күбрәк булуын билгели: мәсәлән, *веник – миник, кочерга – кучерга* һ. б. Татар сөйләшләрендә

әлеге сүзләрнең башкача аталышлары да сакланып калган. Мисаллардан күренгәнчә, көнбатыш диалект вәкилләре күбесенчә рус теленнән көндәлек тормышта кулланыла торган сүзләрне һәм көнкүреш җиһазлары белән бәйле лексиканы (каралты-кура, йорт-җир, хуҗалык кирәк-яраклары, авыл хуҗалыгы кораллары, ат җигү дирбиясе атамаларын) үзләштергәннәр.

Е.А. Малов (1835–1918) – православие динендәге тюрколог-миссионер, язучы, протоиерей, Казан руханилар академиясенең атказанган профессоры. 1862 елда Казан руханилар академиясен тәмамлый һәм Казан руханилар семинариясенә укытучы итеп билгеләнә. 1863 елда Казан руханилар академиясенә күчерелә. Е.А. Малов 1869 елдан, профессор вазифасын саклап, руханилык эшчәнлеген башлап җибәрә, 1880 елдан протоиерей итеп билгеләнә. 1883–1895 елларда «Казан епархиясе хәбәрләре» журналы мөхәррире була.

Галим-миссионер үзенең «Сведения о мишарях: этнографический очерк» (1885) хезмәтендә [8] көнбатыш диалект вәкилләренә этнографик характеристика бирә: китапта аларны һәм Казан татарларын аерып карарга тырышу, бер-берсенә капма-каршы куярга омтылу сизелә. Хезмәтнең максаты – этнографик төркемнең «үзгәлеген» исбатлау, аларның аерым мөстәкыйль милләт булуын күрсәтү. Галим тарафыннан мишәрләр Казан татарлары йогынтысында гына мөселман булып калалар дигән фикер алга сөрелә. Хезмәтнең икенче өлешендә җирле сөйләм үзенчәлекләре тасвирлана, автор аеруча киң таралган лексик берәмлек һәм әйтелмәләрнең сүзлеген китерә, аларның шул чор татар әдәби телендәге аналогларын бирә. Е.А. Малов фикеренчә, этнографик төркемнең теле, башлыча, татар теле, ләкин анда рус теленең йогынтысы нык сизелә. Моннан тыш, диалект вәкилләре сөйләмендә татар телендә кулланылмаган яки аерылып торган сүзләрнең күп булуын, аларның кычкырып һәм каты сөйләшүләрен билгеләп үтә, бу үзенчәлек аеруча Рязань, Пенза, Түбән Новгород, Саратов һәм Сембер губерналарында яшәгән җирле халыкка хас.

Е.А. Маловның улы танылган тюрколог С.Е. Малов (1880–1957) 1902 елның җәендә Казан губернасының Чистай өязендә экспедициядә булып, биредәге халыкның сөйләм теле үзенчәлекләрен өйрәнә. С.Е. Малов, нигездә, цылаштыручы мишәрләр сөйләше буенча материаллар туплый. Ул Чистай өязенең биш авылында була, 5 июньнән 14 июльгә кадәр өязнең төньягында урнашкан Каргалы һәм Дүртөйле авылларында (хәзерге Татарстан Республикасының Чистай районы) яши һәм күзәтүләр ясый [9: 3].

Аның «Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда)» (1904) хезмәтендә өяздә көнбатыш диалект вәкилләре яши торган авылларның исемлеге (исемлектә барлыгы 46 авыл; автор билгеләгәнчә, исемлек тулы түгел) бирелә; сөйләшкә хас фонетик үзенчәлекләр күрсәтелә; халык авыз иҗаты үрнәкләреннән (җырлар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар) мисаллар һәм аларның рус теленә тәрҗемәләре бирелә; сөйләмдә кулланылган рус алынмалары һәм

җирле лексика тупланган сүзлекчә (рус теленә тәрҗемәдә) тәкъдим ителә. Ахырда, кушымта буларак, этнографик төркемне өйрәнү өчен әдәбият урын ала. Шунысы әһәмиятле: һәр хезмәткә аңлатма бирелеп, аларның үзенчәлеге, проблеманы өйрәнүгә керткән өлеше төгәлләштерелә.

В.К. Магницкий (1839–1901) – рус этнографы, тарихчы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе; чуваш халкының иң зур тикшеренүчеләренең берсе. Ул Чабаксар руханилар училищесын (1854), Казан руханилар семинариясен (1857), Казан университетының юридик факультетын (1858–1862) тәмамлый. 1862 елдан Казан җинаятьчелек палатасы канцеляриясендә хезмәт итә, 1863 елдан Казан губернасының Казан һәм Чабаксар өязләрендә мәхкәмә тикшерүчесе. 1877–1894 елларда Вятка губернасының Уржум, Алабуга өязләре, Казан губернасының Лаеш, Спас, Тәтеш, Зөя, Чабаксар өязләре халык училищеларында инспектор вазифасын башкара.

В.К. Магницкий Казан университеты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте (*рус.* Общество естествоиспытателей (1869–1967)) әгъза-хезмәткәре (1874 елдан), Археологик комиссия әгъзасы (1877 елдан), Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең мөхбир әгъзасы (1881 елдан) һәм хакыйкый әгъзасы (1885 елдан) булып тора. В.К. Магницкий Казан һәм Сембер өязендә яшәгән халыкны этнографик юнәлештә өйрәнә [6]. Галим А.Ф. Риттих, Н.И. Золотницкий, Е.А. Малов, В.А. Казаринов хезмәтләренә таянып, Казан һәм Сембер өязендә яшәүче этнографик төркемнәр турында мәгълүмат бирә, көнбатыш диалект вәкилләре яшәгән авылларның исемлеген китерә. В.К. Магницкий үзенең күзәтүләре һәм галимнәрнең хезмәтләре нигезендә, мишәрләрнең килеп чыгышын фин-угор халыкларына мөнәсәбәтле аңлата, шул ук вакытта алар сөйләменең казан татарларыныкына якын булуын күрсәтә [7: 12].

Н.И. Золотницкий (1829–1880) – чуваш лингвисты, чуваш тел белеменә нигез салучыларның берсе, тюрколог-компаративист, этнограф, педагог, җәмәгать эшлеклесе. 1851 елда Казан университетының филология факультетын тәмамлый. Ул Казан дәүләт милке палатасында (1851–1854), аннары Нократ шәһәрендәге дәүләт милке палатасында (1855–1865) эшли, шунда ук гимназия каршында якшәмбе мәктәбе оештыра һәм аның белән җитәкчелек итә. 1865 елда Н.И. Золотницкий Халык мәгарифе министрлыгында хезмәт куя башлый. 1867 елда аны Казан уку округына билгелиләр. Ул чуваш мәктәпләре инспекторы вазифасын башкара, ә 1875 елдан Казан миссионерлар мәктәбендә эшли.

Н.И. Золотницкий, үзенең күпьеллык эш тәҗрибәсенә һәм күзәтүләренә таянып, «Корневой чувашско-русский словарь, сравненный с языками и наречиями разных народов тюркского, финского и других племен» (1875) хезмәтен яза. Сүзлектә чуваш сүзләренең килеп чыгышы һәм мәгънәләре башка төрки (шул исәптән татар) һәм фин-угор халыклары телләре белән чагыштырма аспектта аңлатыла [3: 5].

Хезмәттә аерым этнографик һәм тарихи мәгълүматлар урын ала, кайбер топонимнарның (мәсәлән, Буа, Тархан һ. б.) килеп чыгышы аңлатыла. Галимнең АТЭҖ утырышында укылган доклады *болгар, биләр* атамаларының этимологиясен тикшерүне максат итеп куя, анализ вакытында тарихи мәгълүматлар да китерелә [4].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казан университетында халыкның сөйләм үзенчәлекләрен, татар диалектологиясен өйрәнүдә чагыштырма тел белеме докторы, этнограф, фольклор белгече, танылган тюрколог Н.Ф. Катанов (1862–1922) эшчәнлеге әһәмиятле. Ул 1894 елда университетның тарих-филология факультеты төрек-татар кафедрасы профессоры итеп билгеләнә, 1898–1914 елларда АТЭҖ рәисе була. Галимнең күпкырлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә университетта Шәрыкны өйрәнү традициясе сакланып кала һәм яңарыш кичерә. Казан университетының Россиядә Көнчыгышны өйрәнү үзәге буларак үсеп китүендә дә Н.Ф. Катанов хезмәтләренең әһәмияте бәяләп бетергесез.

Н.Ф. Катановның Казан чоры фәнни эшчәнлегендә аның төрки халыклар яшәгән төрле регионнарга кыр экспедицияләре оештыруы һәм аларда катнашуы аерым урын тота. Галимнең Уфа губернасының Минзәлә (1897 ел) һәм Бәләбәй (1897, 1898 еллар) өязләренә махсус экспедицияләр оештыруы билгеле [12, 13]. Экспедицияләр вакытында халкы *татар, типтәр, мишәр, башкорт, чын башкорт* дип күрсәтелгән авылларның сөйләме чагыштырма аспектта тикшерелә, галим «чын башкортлардан тыш булган авылларның сөйләше барысыныкы да бертөсле икәнлеген, һәм аларның татар теленә бик якын булуларын таный» [18: 13]. 1899 елның җәендә Н.Ф. Катанов Себергә (Енисей губернасына) оештырылган экспедициядә катнаша, биредә ул Себер татарларының сөйләм телен өйрәнә, экспедициядән соң ясалган фәнни хисапта татар теленең көнчыгыш диалектларына күзәтү ясала [14].

Г.Н. Әхмәров (1864–1911) – тарихчы, этнограф, педагог. 1881–1885 елларда Г.Н. Әхмәров Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. 1885–1903 елларда Алабуга өязе Биектау авылында, Тәтештә балалар укыта. 1903 елдан – Казанда, 1905–1911 елларда – Иске Татар бистәсендә мәдрәсә мөгаллиме.

Г.Н. Әхмәровның Җәмгыятьтәге эшчәнлеге (1893 елдан АТЭҖдә әгъза-хезмәткәр, 1904 елдан хакыйкый әгъза булып тора) аның чын белгеч буларак формалашып китүендә зур роль уйный. Галимнәр белән даими аралашу аңа булган белемнәрен тулыландырырга, фәнни күзаллауларын киңәйтергә мөмкинлек бирә. Күренекле галимнәр белән бергә ул төрле мәсьәләләрне ачыклауда катнаша, профессиональ галимнәрнең докладларына өстәмәләр белән чыгыш ясый.

Г.Н. Әхмәров татар халкы тарихын өйрәнә, аның этнографик һәм археологик мирасын туплау белән шөгыльләнә. Галим Җәмгыятьтә археология өлкәсендә дә зур тәҗрибә туплый. Сәламәтлеге начар булуга карамастан, ул гомеренең күп өлешен кыр тикшерүләрендә үткәрә. Татарлар арасында беренче археолог буларак та танылу ала [17: 126].

Г.Н. Әхмәровның Идел буенда һәм Урал алды территорияләрендә яшәгән субэтносларны һәм татарларның аерым этнографик төркемнәрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләре безнең өчен аеруча әһәмиятле. Галимнең көнбатыш диалект сөйләшләре буенча тикшеренүләре һәм татар-типтәрләр турында язылган хезмәтләре кызыклы. Шул чор миссионер галимнәренең (Е.А. Малов, В.К. Магницкий һ. б.) фәнни язмаларыннан аермалы буларак, аның хезмәтләрендә фәнни командировкаларда татар кешесе тарафыннан җентекләп җыелган һәм анализланган этнографик һәм лингвистик материал тәкъдим ителә.

Галимнең әлеге юнәлештәге хезмәтләре арасында «О языке и народности мишарей» (1903) [1] исемле мәкаләсе аеруча әһәмиятле. 1894–1895 елларда Г.Н. Әхмәров Казан губернасының Спас һәм Тәтеш өязләрендә фәнни командировкаларда була [16: 349] һәм җирле халыкның көнкүреше, этнографиясе һәм тел үзенчәлекләре турында мәгълүматлар туплый. Фактик материалны анализлау эше шактый озакка сузылып, бары 1903 елда гына галим фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен Җәмгыять утырышында тәкъдим итә ала. Әлеге тикшеренүнең төп максаты – тел үзенчәлекләре, риваятьләр, традицияләргә нигезләнеп, мишәрләрнең килеп чыгышын билгеләү [10: 184]. Этнографик төркемнең килеп чыгышы турында фикер әйткәндә, Г.Н. Әхмәров тел материалларын нигез итеп ала, мишәрләрнең гореф-гадәтләре турындагы язмаларны файдалана һәм риваятьләргә таяна. Тикшеренү нәтиҗәләрен гомумиләштергәннән соң, галим үзенең чордашлары арасында беренчеләрдән булып, көнбатыш диалект вәкилләренең төрки чыгышлы булуын фәнни нигезли. Шуны искәртеп узарга кирәк: әлеге заманга караган кайбер (мәсәлән, В.В. Вельяминов-Зернов, Е.А. Малов) хезмәтләрдә мишәрләрнең килеп чыгышы фин-угор халыкларының тарихы белән тыгыз бәйләнештә аңлатыла.

Г.Н. Әхмәровның шулай ук типтәрләр һәм аларның килеп чыгышын тикшерүгә багышланган хезмәте [2] дә игътибарга лаек. Галим әлеге этнографик төркем вәкилләре белән 1880 елларда, Нократ губернасының Алабуга өязендә укытучы булып эшләгәндә таныша [16: 355]. Типтәр, башкорт һәм мишәрләрне өйрәнү максатыннан, Г.Н. Әхмәровның 1904 елның 1 маеннан махсус экспедиция оештыруы билгеле, ләкин, билгесез сәбәпләр аркасында, экспедиция 1906 елның 26 маена күчерелә һәм 31 июльгә кадәр дәвам итә. Әлеге экспедиция вакытында аның Уфадагы Үзәк диния нәзарәте архивы документлары белән танышуы да мәгълүм.

XX гасыр башында әлеге этнографик төркем һәм аларның килеп чыгышы турында фәнни хезмәтләрнең аз булуы сәбәпле, Г.Н. Әхмәровка үзе туплаган мәгълүматларга таянырга туры килә. Галим типтәрләргә тулы этнографик характеристика бирү максатын куймый. Типтәрләр һәм татарларның төрле этнографик төркемнәренә, шулай ук күрше халыкларның рухи мәдәниятләре элементларына (гореф-гадәтләр һәм бәйрәмнәр, халыкларның көнкүреше, көндәлек

тормышта кулланыла торган лексикага) тарихи-чагыштырма анализ ясый. Хезмәттә, нигездә, *типтәр* атамасы, аның этимологиясе тикшерелә; этнонимның килеп чыгышы беренче мәртәбә гарәп һәм фарсы телләренә мөнәсәбәттә карала һәм *дәфтәр* сүзе «исемлек, реестр» белән бәйләп аңлатыла. Г.Н. Әхмәровның әлеге фикере бүгенге лингвистик тикшеренүләрдә раслана, татарларның төрле этнографик төркемнәрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләре хәзерге вакытта да фәнни даирәдә актуальлеген югалтмый.

1920 еллардан АТЭҖ хәбәрләрендә татар халкының рухи мәдәниятенә кагылышлы мәсьәләләрне өйрәнүне үзәккә куйган мәкаләләр сирәк басыла башлый. Җәмгыять эшчәнлегендә әлеге юнәлештәге фәнни тикшеренүләрнең кискен кимүе 1923 елда Көнчыгыш педагогия институты составында «Татароведение фәнни җәмгыяте» (1923–1929) оешуга бәйләп аңлатыла. Әлеге җәмгыять татар халкын һәм аның төрле этник төркемнәрен, аларның телен, мәдәниятен, тарихын өйрәнүче белгечләрне туплый. Үзенең эшчәнлегендә бу өлкәгә кагылышлы мәсьәләләрне фәнни яктан тикшерүне, тиешле мәгълүмат таратуны һәм җәмәгатьчелектә җәмгыять белән кызыксыну уятуны максат итеп куя.

Шулай итеп, XIX гасырның соңгы чирегендә татар диалектологиясе мәсьәләләрен фәнни өйрәнүгә нигез салына. Татар халкының рухи мәдәниятен, аерым этнографик төркемнәрне һәм татар сөйләшләрен системалы тикшерү, фактик материал туплау барышында Казан университеты каршында оешкан Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең эшчәнлеге аеруча әһәмиятле. Җәмгыять әгъзаларының хезмәтләрендә татар теленең диалект һәм сөйләшләргә бүленеше, аларны классификацияләү юлында тәүге адымнар ясала, алар системага салына һәм фәнни нигездә аңлатыла башлый.

**Әдәбият**

1. *Ахмаров Г.Н.* О языке и народности мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1903. Т. 19. Вып. 2. С. 91–160.

2. *Ахмаров Г.Н.* Тептяри и их происхождение // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1908. Т. 23. Вып. 5. С. 340–364.

3. *Золотницкий Н.И.* Корневой чувашско-русский словарь, сравненный с языками и наречиями разных народов тюркского, финского и других племен. Казань, 1875. 279 с.

4. *Золотницкий Н.И.* Лингвистическая заметка о названиях Булгар, Биляр и Морквашы: (читана в Общем собрании гг. членов Общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те, 30 ноября 1878 г.) / [соч.] Н.И. Золотницкого. Казань: Тип. имп. ун-та, 1879. 24 с.

5. *Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1885. Т. 4. С. 1–12.

6. *Магницкий В.К.* Несколько данных о мишарях (мещера, мещеряки) и селениях их в Казанской и Симбирской губерниях // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1896. Т. 13, Вып. 4. С. 245–257.

7. *Магницкий В.К.* Несколько данных о мишарях и селениях их в Казанской и Симбирской губернии. Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1896. 15 с.

8. *Малов Е.А.* Сведения о мишарях: этнографический очерк // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1885. Т. 4. С. 13–91.

9. *Малов С.Е.* Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда) // Приложение к «Ученые записки Казанского университета». Кн. 4. Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1904. 24 с.

10. *Марданова Ф.Ф.* Роль Казанского университета в изучении духовной культуры татар Поволжья // Ученые записки Казанского университета. Сер. Гуманит. науки. 2020. Т. 162, Кн. 3. С. 181–195.

11. Онлайн-энциклопедия Tatarica [Электронный ресурс]. – URL: mgyyatlr/arheologiya-tarih-m-etnografiya-mgyyate (мөрәҗәгать итү көне: 28.08.2025).

12. Отчет о поездке, совершенной с 1 июня 1897 г. по 20 августа того же года в Белебеевский и Мензелинский уезды Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Кн. 11. Казань, 1898. С. 1–37.

13. Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 г. в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Кн. 7 и 8. Казань, 1900. С. 1–30.

14. Отчет о поездке в Минусинский уезд Енисейской губернии, совершенной по поручению историко-филологического факультета Императорского Казанского университета, летом 1899 года. Казань, 1900. 59 с.

15. Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии за 1898 г. // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1899. Т. 15, Вып. 4. С. 442–482.

16. *Салахова Э.К.* Проблема происхождения татар-мишарей и тептярей в трудах Г.Н. Ахмарова // Историческая этнология. 2016. Т. 1. № 2. С. 349–362.

17. *Салахова Э.К.* Деятельность Г. Ахмарова в Обществе археологии, истории и этнографии при Казанском университете // Из истории казанской этнографии. 2017. С. 121–133.

18. Татар халык сөйләшләре: ике китапта / [авторлар коллективы: Ф.С. Баязитова һ. б.]. Казан: Мәгариф, 2008. Кит. 1. 2008. 461 б.

19. *Yusupov A.F., Fayzullina G.Ya.* Tatar Dialectological School in Kazan University: Origins, formation and development // Tatarica. 2024. 22(1). P. 26–48.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Юсупов Айрат Фаик улы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле белеме кафедрасы профессоры*

***Юсупов Айрат Фаикович,***
*доктор филологических наук, профессор кафедры татарского языкознания Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета*

*faikovich@mail.ru*

УДК 351.85; 379.8

***Д.И. Әхмәтов,***
***Л.Г. Мөхәммәдиева***

# КЕРӘШЕН ВАКЫТЛЫ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ

В статье исследуется формирование кряшенских средств массовой информации с начала 1990-х годов до настоящего времени, пути их развития, правовые и общественные основы и деятельность. Кряшены (тат. *керәшеннәр* от рус. *крещён; крещёные татары*) – этноконфессиональная группа в составе татар Волго-Уралья, исповедующая православие.

Через анализ истории и современных проблем кряшенской периодической печати автор раскрывает роль данных изданий в обществе, их значение в сохранении национальной культуры и самосознания. В ходе исследования выявляются исторический опыт и современные аспекты создания и развития кряшенской периодической печати, основные проблемы и перспективы на будущее. В статье освещается история создания и деятельности газет «Керәшен сүзе», «Керәшен хәбәре», «Туганайлар». Также показана общественная роль кряшенской прессы, ее тематические направления, аудитория и значение в сохранении национальной культуры.

**Ключевые слова:** кряшены, периодическая печать кряшен, «Керәшен сүзе» («Слово кряшен»), «Керәшен хәбәре» («Новости кряшен»), «Туганайлар» («Сородичи»), культурное наследие.

The article examines the formation of Kryashen mass media from the early 1990s to the present day, their development paths, legal and social foundations and activities. Through an analysis of the history and contemporary problems of the Kryashen periodical press, the author reveals the role of these publications in society, their significance in preserving national culture and self-awareness. The study reveals the historical experience and contemporary aspects of the creation and development of the Kryashen periodical press, its main problems and future prospects. The article covers the history of the creation and activities of the newspapers «Kereshen suzze», «Kereshen khabere», «Tuganaylar». The public role of the Kryashen press, its thematic areas, audience, and importance in preserving national culture are also shown.

**Keywords:** Kryashens, periodicals of the Kryashens, “Kereshen suse” (“Word of the Kryashens”), “Kereshen khabəre” (“News of the Kryashens”), “Tuganaylar” (“Kindreds”), cultural heritage.

Массакүләм мәгълүмат чаралары – милли азчылыкларның мәдәниятен, телен, үзаңын саклап калуда һәм үстерүдә нәтиҗәле механизмнарның берсе булып тора. Керәшеннәр өчен әлеге мәсьәлә аеруча актуаль, чөнки бу этник төркемнең матбугаты тарихи яктан катлаулы һәм каршылыклы юл үткән. 1990 елларга кадәр керәшеннәрнең үз массакүләм мәгълүмат чаралары булмаган (1917–1930 елларда кыска гына вакыт эчендә яшәп алган «Киняш» газетасын исәпкә алмаганда). Советлар Союзы таркалган чорда милли үзаң үсеше, демократик үзгәрешләр һәм мәдәни хокукларны киңәйтү шартларында

керәшеннәрнең үз массакүләм мәгълүмат чараларын булдыру мөмкинлеге туды.

Мәкаләнең максаты – хәзерге чорда керәшен массакүләм мәгълүмат чараларының формалашу үзенчәлекләрен һәм аларның керәшен җәмгыятенең милли үзаңын саклаудагы ролен ачыклаудан гыйбарәт.

Әлеге тикшеренүнең нәтиҗәләре керәшен тарихын, мәдәниятен өйрәнү өлкәсендәге фәнни белемнәрне баетуга һәм Татарстанда этник массакүләм мәгълүмат чаралары үсеше стратегиясен камилләштерүгә ярдәм итәчәк.

1980 еллар ахыры – 1990 еллар башында Советлар Союзында һәм аннан соң Россиядә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр, «ачыклык» сәясәте, милли-мәдәни үзаң үсеше, демократик хокук һәм ирекләрнең киңәюе керәшеннәргә үз массакүләм мәгълүмат чараларын булдыру өчен мөмкинлекләр тудырды.

1992 елның 23 маенда Казанда Татарстан Республикасы халыкларының Беренче съезды узды. Анда Казан шәһәре керәшен оешмасы җитәкчесе А.В. Фокин тарафыннан керәшен вакытлы матбугаты мәсьәләсе күтәрелде. Керәшеннәрнең җирле оешмалары конференциясе (Казан, 1992 елның 12 апреле) Татарстан Республикасы Югары советына керәшен нәшрият эшләрен, вакытлы матбугатын яңарту һәм радио һәм телевидениедә үз редакцияләрен оештыру мөмкинлеге турында мәсьәләләрне карарга тәкъдим итте.

Моннан тыш, милли үзаң үсеше, керәшен иҗтимагый хәрәкәте активлашу, 1990 елларның башында Яр Чаллы, Казан, Алабуга, Түбән Кама һәм башка шәһәрләрдә керәшен мәдәни-агарту оешмалары төзелү керәшен массакүләм мәгълүмат чараларын яңарту өчен уңай шартлар тудырды. Керәшеннәрнең тарихи үткәнгә, үз мәдәни мирасларына кызыксынулары арту, традицияләрен, милли үзенчәлекләрен саклап калу теләге – болар барысы да керәшен матбугатын булдырырга этәрде.

1993 елның 4 февралендә Яр Чаллы шәһәрендә «Керәшен сүзе» иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газетасының беренче саны дөнья күрде. Газетаның гамәлгә куючысы – «Металлургстрой» җитештерү берләшмәсенең әйдәп баручы белгече Н.П. Антонов. Беренче мөхәррире – шагыйрь һәм публицист Ананий Малов (Ямаш Игәнәй) (1938–1997).

«Керәшен сүзе» газетасы формаль яктан татар һәм рус телләрендә нәшер ителергә тиеш булса да, гамәлдә күбесенчә татар телендә чыкты. Газета куйган бурычларның берсе – Россиядә яшәгән керәшеннәрне берләштерү, аларның үзаңын яңарту һәм саклау, мәдәни һәм рухи мирасын пропагандалау.

Газета төрле елларда 500 дән алып 1000 данәгә кадәр тираж белән басыла, бу редакциянең матди хәле белән бәйле була. Башта газета айга – ике, аннары айга бер тапкыр чыга.

«Керәшен сүзе» газетасының тематикасы бик төрле. Газета керәшеннәрнең Россиянең төрле төбәкләрендәге тормышын яктырта,

тарихы, этник үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, традицияләре, дини ышанулары турында материаллар бастыра. Газетада күренекле мәдәният һәм сәнгать, әдәбият эшлеклеләре турында мәкаләләр урын ала.

Мисал өчен, газетада керәшен авыллары турында тарихи очерклар («Безнең авыл тарихы» рубрикасы), халык авыз иҗаты үрнәкләре, сәнгать һәм музыкага караган материаллар, халык бәйрәмнәре (Питрау, Нардуган һ.б.) турында мәкаләләр басыла.

«Керәшен сүзе»ндә танылган шәхесләр турында истәлекләр дә дөнья күрә. Мәсәлән, газета күренекле мәгърифәтче И. Тимофеев, композитор Т. Гайнуллин, рәссам И. Михайлов, галим М. Глухов һ. б. турында язмалар бастыра.

1996–1997 елларда газета матди кыенлыклар кичерә, шул сәбәпле даими рәвештә чыгудан туктый. Әмма керәшен җәмәгатьчелеге һәм спонсорлар ярдәме белән газетаны саклап кала алалар, һәм ул 2001 елга кадәр яшәп килә.

1996 елның икенче яртысында Яр Чаллы шәһәрендә «Керәшен хәбәре» иҗтимагый-сәяси газетасы теркәлә һәм чыга башлый. Газетаның гамәлгә куючысы – Яр Чаллы мәдәни-агарту этнографик керәшен җәмгыяте. «Керәшен хәбәре»нең баш мөхәррире шулай ук А.Н. Малов була.

«Керәшен хәбәре» газетасы «Керәшен сүзе»н тулыландыручы басма буларак барлыкка килә. Бу ике газетаның идарә составы шактый охшаш булып, «Керәшен хәбәре» – күбрәк иҗтимагый-сәяси, «Керәшен сүзе» мәдәни-агарту һәм этнографик мәсьәләләргә игътибар бирә.

«Керәшен хәбәре» газетасы керәшен иҗтимагый хәрәкәтенең үсеше, керәшеннәрнең хокукларын яклау, керәшен мәдәни автономиясе мәсьәләләре, керәшеннәрнең сәяси һәм иҗтимагый тормышта катнашуы кебек темаларга зур урын бирә. Газета керәшен җәмәгать оешмаларының эшчәнлеген дә, алар үткәргән чаралар, җыелышлар, конференцияләрне дә яктыртып бара.

«Керәшен хәбәре» газетасында тарихи һәм мәдәни мирас турындагы язмаларга да зур урын бирелә. Газета Россиядәге керәшен авылларының үткәне һәм бүгенгесе, рухи мирасы турында материаллар бастыра.

Газетаның тиражы якынча 500–700 данә була. Ул айга бер тапкыр чыга. Матди кыенлыклар булу сәбәпле, газета даими рәвештә чыга алмый, 1999 елда чыгудан туктый.

2002 елда Яр Чаллы шәһәрендә «Туганайлар» мәдәни-агарту газетасы ачыла, ул – чынлыкта «Керәшен сүзе»нең дәвамчысы. «Туганайлар»ның беренче баш мөхәррире булып Л.Д. Белоусова билгеләнә. Газетаның исеме («туганнар» дигән мәгънәгә ия) керәшеннәрне туган, бер-берсенә якын кешеләр буларак берләштерү теләген чагылдыра.

«Туганайлар» газетасы башлангыч чорда иҗтимагый-сәяси басма буларак теркәлсә дә, соңрак рәсми рәвештә мәдәни-агарту газетасы

дип үзгәртелә. Газета укучыларның күбесе «Туганайлар»ны «Керәшен сүзе»нең дәвамчысы яки үзгәртелгән исем астында чыккан «Керәшен сүзе» буларак кабул итте.

Газетаның үзенчәлеге шунда: ул православие динендәге керәшеннәрнең рухи тормышын яктыртуга зур игътибар бирә. «Туганайлар»да православие бәйрәмнәре, дини йолалар, керәшен чиркәүләренең тарихы һәм бүгенгесе турында материаллар даими рәвештә басыла. Газета керәшеннәрнең дини үзаңын ныгытырга һәм православие традицияләрен сакларга ярдәм итә.

«Туганайлар» айга ике тапкыр чыга һәм газетаның тиражы төрле елларда 1000–1500 данә тирәсе була. Газета Татарстан Республикасының дәүләт ярдәмен ала, бу аның финанс хәлен ныгыта.

«Туганайлар» газетасы керәшеннәрнең бер-берсе белән аралашу, мәгълүмат алмашу, үз тарихларын, мәдәниятләрен, традицияләрен өйрәнү һәм саклау өлкәсендә мөһим коммуникация чарасына әйләнде.

Керәшен газеталарының («Керәшен сүзе», «Керәшен хәбәре», «Туганайлар») барлыкка килүе һәм үсеше керәшен җәмгыятенә зур йогынты ясый. Алар керәшеннәрнең тарихы, мәдәнияте, дини үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре турында мәгълүмат тарата, төрле төбәкләрдә яшәүче керәшеннәргә бер-берсе белән аралашу, мәгълүмат алмашу, үз проблемаларын уртаклашу, аларны хәл итү юлларын бергәләп эзләү мөмкинлеге бирә. Газеталар керәшен җәмәгать оешмаларының, мәдәни үзәкләренең эшчәнлеген яктыртып, аларның эшен координацияләргә булыша. Авыл хуҗалыгындагы проблемаларны, авыл инфраструктурасы, авыл тормышын яхшырту мәсьәләләрен күтәреп, авылларның социаль-икътисади үсешенә дә игътибар бирә.

Массакүләм мәгълүмат чараларының үсеш перспективалары берничә юнәлешне колачлый. Беренчедән, бу – газета-журналларны цифрлаштыру. Хәзерге вакытта «Туганайлар» газетасының үз сайты бар, социаль челтәрләрдә аккаунтлары эшли. Киләчәктә электрон форматны үстерү, онлайн-контентны арттыру, интерактив элементлар кертү, яңа цифрлы форматларны (подкастлар, видеоконтент һ. б.) үзләштерү мөһим булачак.

Икенчедән, массакүләм мәгълүмат чараларының аудиториясен киңәйтү.

Өченчедән, массакүләм мәгълүмат чараларының төрлелеген арттыру.

Дүртенчедән, массакүләм мәгълүмат чараларын финанслау чыганакларын диверсификацияләү. Дәүләт ярдәме белән генә чикләнмичә, грантлар, иганә акчалары, коммерция проектлары, реклама һәм башка финанс чыганакларын эзләү керәшен газеталарының финанс хәлен ныгытачак.

Бишенчедән, бу – массакүләм мәгълүмат чараларының эчтәлеген һәм сыйфатын яхшырту. Яңа рубрикалар, заманча темалар, укучылар

өчен актуаль проблемаларны яктырту, интерактив элементлар кертү газеталарны кызыклырак итәчәк.

Хәзерге чорда керәшеннәрнең массакүләм мәгълүмат чаралары милли мәдәниятне үстерүдә, гореф-гадәтләрне, традицияләрне саклауда, милли үзаңны ныгытуда мөһим роль уйный.

**Әдәбият**

1. *Антонов Н.П.* Керәшен сүзе: тарих һәм хәзерге заман // Керәшен сүзе. 1999. № 6 (66). Б. 4–7.

2. *Әхмәтов Д.И.* Хәзерге чорда керәшен массакүләм мәгълүмат чараларын яңарту һәм формалаштыру проблемалары // Ученые записки Казанского университета. 2024. Т. 166. Кн. 2. С. 138–146.

3. *Әхмәтов Д.И.* Яр Чаллы шәһәрендә керәшен газетасы «Туганайлар»ның барлыкка килүе һәм эшчәнлеге (2002–2008) // Кеше. Социум. Җәмгыять. 2024. № 12. Б. 24–33.

4. *Белоусова Л.Д.* Керәшен матбугатының яңарышы // Туганайлар. 2012. № 10 (240). Б. 3–5.

5. *Глухов М.С.* Tatarica. Энциклопедия. Казан: Ватан, 1997. 504 с.

6. *Малов А.Н. (Ямаш Игәнәй).* Керәшеннәр мәдәнияте һәм матбугаты // Керәшен сүзе. 1997. № 8 (56). Б. 3–4.

7. *Насыров Т.М.* Беренче керәшен газетасы // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2009. № 1. Б. 242–246.

8. *Фокин А.В.* Керәшен милли хәрәкәте һәм матбугат // Казан утлары. 2001. № 5. Б. 145–152.

***Әхмәтов Данир Илгизәр улы,***
*ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты кече фәнни хезмәткәре*

***Мөхәммәдиева Лилия Габделәхәт кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

***Ахметов Данир Ильгизарович,***
*младший научный сотрудник Института проблем экологии и недропользования АН РТ*
*ahmetov-danir@mail.ru*

***Мухамадеева Лилия Абдулахатовна,***
*кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ*
*zgel21@mail.ru*

УДК 821

***В.Ф. Макарова***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ПРОЗАСЫНДА БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫН КҮЗАЛЛАУ (Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..» романы мисалында)

С наступлением перестройки тема Великой Отечественной войны в татарской прозе стала рассматриваться как трагическая история советской системы, во фронтовой действительности которой явственно отразились многие проблемные моменты во взаимоотношениях власти и человека.

В современной татарской прозе, развивающей эти традиции, характерной чертой представлений о Великой Отечественной войне является оценка военных и общественно-политических событий в тесной связи с национальными проблемами через призму общечеловеческой философии, преобладание глубокого психологизма.

Анализ романа Зульфата Хакима «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..» («Сколько мгновений в одном часе?..», 2022) позволяет проследить особенности современного татарского романа о Великой Отечественной войне. Писатель выбирает путь философского осмысления, а не художественного пересоздания действительности. В романе преобладает жизнеописание в форме внутреннего монолога или глубокого философского обобщения споров героев, что является удачным приемом для отображения духовного мира персонажей, особенностей их характера, противоречий во взглядах.

Оценка Великой Отечественной войны в плоскости общечеловеческой философии не нова для татарской литературы. В новом романе автор затрагивает важность выбора каждого: поступок в мгновении может быть важным решающим моментом для судьбы своего народа, будущих поколений, для человечества. Представление концепции сильного человека в лице солдата-татарина, бойца – центральная точка зрения, позволяющая почувствовать возможность сохранения национальной идентичности. Вокруг этого складывается созвучная традиционным для татарской литературы мотивам проблематика. Таков, например, мотив несправедливо осужденных, многократно прозвучавший в постсоветской литературе, мотив сохранения человечности, милосердия в критических условиях, пренебрежение интересами отдельной личности во имя общественных интересов.

В статье рассматриваются сюжет, мотивирование характера героя, роль художественной детали, подтекста, ассоциативных параллелей, сна, песен, стихов, пародоксов, авторской маски в расскрытии идеи произведения. Отмечается, что философичность, лиризм, глубина психологизма, которые передаются через «поток сознания», помогли автору глубже расскрыть лейтмотив романа.

**Ключевые слова:** татарская литература, Великая Отечественная война, философичность, психологизм, подтекст.

With the advent of perestroika, the theme of the Great Patriotic War in Tatar prose began to be viewed as a tragic history of the Soviet system, in the frontline real-

ity of which many problematic moments in the relationship between power and man were clearly reflected.

In modern Tatar prose, developing these traditions, a characteristic feature of ideas about the Great Patriotic War is the assessment of military, socio-political events in close connection with national problems through the prism of universal philosophy, the predominance of deep psychologism.

An analysis of the novel by Zulfat Khakim "Ber sagatte niche mizgel bar?.." ("How many moments in one hour?..", 2022) allows us to trace the features of the modern Tatar novel about the Great Patriotic War. The writer chooses the path of philosophical understanding and not artistic recreation of reality. The novel is dominated by biography in the form of an internal monologue or a deep philosophical generalization of the heroes' disputes, which is a successful technique for displaying the spiritual world of the characters, their character traits, and contradictions in their views.

The assessment of the Great Patriotic War in the plane of universal philosophy is not new for Tatar literature. In the new novel, the author touches upon the importance of everyone's choice: an act in an instant can be an important decisive moment for the fate of one's people, future generations, and humanity. The presentation of the concept of a strong man in the person of a Tatar soldier, a fighter, is the central point of view that allows one to feel the possibility of preserving national identity. Around this, a problematic consonant with traditional motives for Tatar literature is developing. Such, for example, is the motive of the unjustly convicted, which has repeatedly sounded in post-Soviet literature, the motive of preserving humanity, mercy in critical conditions, disregard for the interests of an individual in the name of public interests. The article examines the plot, motivation of the hero's character, the role of artistic detail, subtext, associative parallels, dreams, songs, poems, paradoxes, the author's mask in revealing the idea of the work. It is noted that the philosophical nature, lyricism, depth of psychologism, which are transmitted through the "stream of consciousness", helped the author to more deeply reveal the leitmotif of the novel.

**Keywords:** Tatar literature, the Great Patriotic War, philosophical nature, psychologism, subtext.

Татар прозасында Бөек Ватан сугышы темасы 1980 еллардан тарихка рәсми идеология контекстыннан арынып бәя бирүнең бер юлына әйләнде. Д. Заһидуллина фикеренчә, үзгәртеп корулар башлангач, сугышка башкача, аны совет тоталитар режимының фаҗигалы тарихы итеп карау, фронт хакыйкатен әдәбиятта тулысынча яктырту мөмкинлеге туа [3: 58].

Татар әдәбиятында сугышны бизәмичә, объектив якын килеп сурәтләгән тәүге әсәрләр рәтендә Н. Фәттахның сугыш чорының тылдагы кырыс чынбарлыгын сурәтләгән «Кырык дүртнең май аенда» (1965) повестен атап булыр иде.

Галимнәр бу юнәлештә татар әдәбиятында үзгәреш китереп чыгарган әсәр буларак М. Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна (Биектә калу)» (1979) повестен да билгелиләр. Аны Ф. Миңнуллин сугыш һәм тынычлык, яшәү, үлем турындагы фәлсәфә тирән, сәнгатьчә югары тасвирланган, эмоциональ тәэсир көче зур булган әсәр дип бәяләгән иде [5: 125]. Әлеге повестьта властька омтылган, максатына

ирешү өчен бернинди пычрак алымнардан да чирканмаган, башка милләт кешеләренә «икенче сорт» итеп караган Филимонов, Соколов, Орловларны күрсәтеп, Марсель Ялчинский гаиләсенең баржада батырылуы турында сөйләгәндә, туган җирләреннән сөрелеп, үлемгә хөкем ителгән Кырым татарлары язмышын күтәреп, язучы ил җитәкчелегенең милләтләргә карата кылган җинаяте проблемасына кагыла. «“Шәмдәлләрдә генә утлар яна...” әсәре 1960–1980 еллар татар прозасында тәнкыйди юнәлешнең дә иҗтимагый мәйданнан милли проблемаларга таба хәрәкәт итүен дәлилли, татар язучыларының советчыл системаны, социалистик идеологияне милли яссылыкта тәнкыйтьли башлавы хакында сөйли» [4: 312].

Әлеге әсәрдән соң татар әдәбиятында шәхес концепциясен тамырдан үзгәрткән, татар каһарманнарын төп геройлар итеп мәйданга чыгарган әсәрләр шактый язылды. Аларның кайсы – классик романтизм, кайсы кырыс реализм традицияләрен тергезде.

Хәзерге татар прозасында Бөек Ватан сугышын күзаллауда үзенчәлек буларак Ә. Еникидән килгән стиль – сугыш күренешләрен гомумкешелек фәлсәфәсе яссылыгында бәяләү, тирән психологизм өстенлек итү күзгә ташлана.

Бөек Ватан сугышы турындагы бүгенге татар прозасында илдәге иҗтимагый-сәяси барышка бәя фронт һәм тыл тормышы, сугыштан соңгы еллар, Кырым татарлары фаҗигасы, шәхес культы елларының ачы хакыйкате һәм иң әһәмиятлесе – милли яшәештәге проблемалар белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Күпчелек әсәрләрдә чор вазгыятенең милли кыйммәтләрне юк итүе хакындагы фикер ассызыклана. Әйтик, Зөлфәт Хәким «Легионер» (2004–2009) романында сугыш белән бәйле вакыйгалар аша тарихи хәтерне, ватанны, рухи кыйммәтләрне җую турындагы фикерне гомумиләштерә. Яббар тарихы язучыга татар әдәбиятында беренче булып легионерлар – пленга эләккән, Идел-Урал легионына кергән, белорус партизаннары белән иңгә-иң сугышкан, аннары фильтрацион лагерьларны, «илгә хыянәт» өчен тәмуг газапларын кичкән кешеләр темасын күтәрергә мөмкинлек бирә. Автор шундый фикер үткәрә: «Ил үзен сөйгән һәм сакларга сәләтләрне юк итә!»

Шундый әсәрләр рәтендә З. Хәкимнең «Телсез күке» (2002–2003) романын, Зәки Зәйнуллинның «Үрләр аша» (1998), Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» (1980–1990), «Өч аяклы кеше» (2020) повестьларын да атарга булыр иде. Әлеге әсәрләрдә Бөек Ватан сугышы темасы чикләрендә совет хөкүмәтенең кеше гомере белән санлашмаган эчке сәясәтенә, шәхес культының аяныч сәхифәләренә шактый колачлы, тирән, заманча бәя бирелә.

Сугыш кайтавазы буларак туган бүгенге шундый әсәрләрнең берсе – Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..» [6; 7] романы.

Әсәрдә үткәндәге һәм бүгенге вакыйгалар берничә сюжет сызыгында яктыртыла. Германия клиникасына яман чир авыруыннан

дәваланырга килеп, Хәйдәрнең әтисе танышының улы Винфрид Мейер белән очрашуы, терелеп кайтып китүе һәм 1944 елда Хәйдәрнең әтисе Гарипов Самат белән әсир Ортвин Мейерның берничә тәүлектә күргәннәре төп сюжет сызыкларын хасил итә. Ярдәмче сюжет сызыклары геройларның балалары һәм Самат гашыйк булган Светаның язмышларын тергезә.

Романда психологизм алымы кулланып, тип дәрәҗәсендә эшләнгән образ – Самат. Украинаны фашистлардан азат иткәндә шактый батырлыклар күрсәтергә өлгергән, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән сугышчыга кулга алынган немецны һәм рацияне Смерш вәкилләренә илтеп тапшыру бурычы йөкләнә. Дошманын исән-имин тиешле җиргә китереп җиткерү максатыннан, Самат әсирне бандерачылардан, үлемнән коткарып кала, ә инде чарасыз калгач, аны үтерми, ireккә җибәрә (әйтергә кирәк, бу ышандыра, чөнки Ортвин сугышчы түгел, ә радиоҗиһазлар төзәтүче). Ортвин да, мөмкинлеге булып та, Саматны немецларга сатмый.

Геройлар арасында мөнәсәбәтләрнең үзгәрүе мотивлаштырып бирелә – өч тәүлек эчендә татар егете Самат рус кызы Светага олы мәхәббәт хисе кичерә һәм әсир, аларның танышуының сәбәпчесе генә булып калмыйча, матур мизгелләрнең шаһитына әйләнә.

Якты, бәхетле мизгелләр кичергән егет начарлык кыла алмый, явызлыкны, яман чыганакны җиңеп, кеше булып кала. Алай гына да түгел, мәхәббәт Саматка матурлык иҗат итәргә илһам бирә – төрле милләт кешеләре сокланып тыңларлык шигырь языла. Соңрак Ортвинның оныгы шул сүзләргә язылган җырны төрле телләрдә яңгыратыр.

Сөйгәне белән кавыша алмаган, гомере буе Светаны сагынып яшәгән Саматның иртә үлү сәбәбе түбәндәгечә аңлатыла: *«Батыр йөрәкле, орден-медальле солдат ил-көндәге төкселеккә каршы гына көрәшергә үзендә көч тапмады. Яшисе килми башлагандыр аның, юкса китеп бармас иде»* [7: 43].

Саматның исеме гарәпчә «нык, түземле, үзгәрми торган» дигән мәгънәне аңлатса да, «Света үлде» дигән хәбәрдән ул төшенкелеккә бирелә, тыныч тормышта үзенә урын таба алмый. Шул рәвешле, яшәешкә сугыш афәте каршы куела. Әмма геройлар мәхәббәтне сугышның мизгел саен үлем куркынычы янап торган коточкыч фаҗигалы юлларында тапсалар да, тыныч тормышта аны саклап кала алмыйлар. Кешеләр күңеленә яшеренгән көнчелек, усаллык – сугыш афәтеннән дә явызрак, җимергечрәк булып чыга. Саматның иртә үлеме, бер яктан, романдагы үкенечле яңгырашны тирәнәйтсә, икенче яктан, авторның җәмгыять һәм кешелек асылындагы тискәре сыйфатлар хакында уйлануын фәлсәфи гомумиләштерә.

Әсәр Саматның акыллы, сәләтле, таза әхлаклы, милли рухлы балаларының, олыгаеп, безнең көннәрдә очрашуы белән тәмамлана. Романның исеменә чыгарылган сорауны ачыклаган фикер төрлечә бирелеп, әсәрдә яктыртылган тарихны ача. Ул хәтта фатализм яссылыгына

да килеп чыга: *«Кемдер кайбер мизгелләр эчендә кылган гамәлләрне башка берәү гомер буена да булдыра алмаска мөмкин бит...»* [7: 63]; *«Балаларыңның, оныкларыңның язмышы да синең теге яки бу мизгелләрдә нинди карар кылуыңа, нинди адым ясавыңа бәйледер»* [7: 14–15]. Димәк, Самат белән Ортвинның сугышта бер-берсен коткарып калулары тикмәгә булмаган – Самат улы Хәйдәрнең гомерен Германиядә Ортвинның нәсел дәвамчысы саклап кала.

Әсәрдә кабат-кабат калкуландырылып дәлилләнгән фикер болай яңгырый: дөньяда явызлык күп, әмма анда бер нәрсә дә очраклы түгел. Вәхшилек хөкем сөргән дөньяда мәхәббәт кешегә яшәү көче бирә, кешелекле, бәхетле булырга ярдәм итә, ярата белгән кеше җан кыймый. Мәхәббәт булган җирдә яман чыганакка урын калмый.

Әлеге лейтмотив яман чыганак – яман күзәнәкләр параллеле белән һәр сюжет сызыгында кабатлана. Хәйдәрдә яман чир барлыкка килү сәбәпләре геройның зур данга ирешеп тә тормыштан канәгатьсезлеге, гомере буе үз халкыннан читтә яшәве һәм курку белән аңлатыла: *«Бер профессорның күптән инде әйткәне бар иде: “Тормышта үзеңә каршы барырга ярамый. Үзенә хыянәт итеп, үзенә хас булмаган рольне уйнарга тырышып, һәрдаим үзенә каршы килеп, минлегеннән читләшеп яшәүче кеше әллә нинди яман авыруларга дучар булырга мөмкин...”»* [6: 11].

Урыны белән язучы моны геройның шәхси тормышына, гаиләдәге хәл-халәтенә дә бәйләп куя: *«Гомер буе сине чукып яшәгән хатын кулына калу ихтималы ник куркыта, котны ала»* [6: 10].

Геройның характеры – бер гаделсезлеккә дә битараф кала алмавы, һәр уңышсызлыкның сәбәбен эзләп яшәве дә искәртелә, әмма тиешенчә үстерелеп бетерелми: *«Фән белән генә шөгыльләнәсе урынга, хөсетләр, булдыксызлар белән көрәшеп, күпме вакыт, күпме көч, күпме сәламәтлек сарыф ителде!»* [6: 10]. *«Башкалардан, тирә-яктагы мохиттән, гомумән, чынбарлыктан гаеп эзләү дә – үз-үзеңнән канәгать булмауның әверелеше ләбаса»* [6: 10]. *«Ә бит Хәйдәр ничәмә еллар буе үз-үзенә каршы килеп яшәде. Үз фикерен әйтергә мөмкинлекләре күп булдымы? Уй-ниятләренең күпмесен гамәлгә ашыра алды? Үз фикерен әйткән очракта да, аны бик сирәк хупладылар түгелме? Үзенең хаклы икәнен ничә тапкыр исбатлый алды соң ул?»* [6: 11].

Хәйдәрдә яман чир чыгуны нигезләү шушы фикерләрдән ары китә алмый. Укучы Гөлсинә белән Хәйдәр мөнәсәбәтендәге аңлашылмаучанлыкларның җанлы вакыйгаларда ачылып бетүен, геройның көрәшче холкы хезмәт урынында да күренүен көтә. Ир-хатын тормышы, геройның әйләнә-тирәсе турында сөйләп бирү – нәсыйхәт белән түгел, ә каршылыклар ярдәмендә җанлы вакыйгаларда ачылырга, яшәештәге тагын бик күп проблемалар яктыртылырга тиешлеге күзгә ташлана.

Язучы чынбарлыкны кабат тергезеп түгел, бәлки фәлсәфи бәяләп бару юлын сайлый. Романда персонажларның күңел дөньясын, холык-фигылендәге үзенчәлекле якларны, каршылыкларны күрсәтеп

куюда уңышлы алым булган эчке монолог рәвешендә яисә геройларның бәхәсләрендә (әйтик, Саматның хирург Иван Константинович, Тимофей белән әңгәмәсе) тирән фикри-фәлсәфи гомумиләштерү ярдәмендә тормыш-яшәешкә бәя бирелә: *«Кеше хәтерендә синең якты хатирә булып саклануың – тарихта уйдырма каһарман булып язылуга караганда, югарырактыр, әһәмиятлерәктер»* [7: 15]; *«Гомерлеккә сузылган өч тәүлекнең бәхетле мизгелләрендә ике кешенең яшәү мәгънәсе табылган»* [7: 62]; *«Әтиләребезнең гомере тулырак, баерак, кызыграк, мәгънәлерәк булган»* [7: 63].

«Язучы – хәбәр җиткерүче, кисәтүче: ул рухи кыйммәтләр югалу, тел бетү һәм туган җир кадере киму, буыннар арасында бәйләнеш өзелү, вөҗдан төшенчәсенең эчтәлеге үзгәрү турында кисәтә» [2: 64].

З. Хәким әсәрендә дә кеше яшәешенең мәгънәсе турында күп сораулар күтәрелә. Арада риторик булганнары да шактый: *«Мәңгелек өчен кайсысы кыйммәтрәк соң – галимнәрнең цивилизациягә керткән өлешләреме, яисә кешеләр арасындагы мәхәббәтме?»* [7: 63]; *«Нигә кешелек дөньясында яман чыганак бар, ник аңардан гел ялкынсыну чыгып тора, ник кешеләр бер-берсен үтерергә омтылалар?»; «Нәрсә ул гомер? Мәңгелектәге мизгел генә ләбаса. Нәрсә ул өч тәүлек? Гомернең мизгеле генә инде»* [7: 62]; *«Кешеләр бер-берсен көнетөне үтереп торгач, синең дөреслеккә ышануыңнан ни мәгънә?!»* [6: 72]; *«Гөнаһлар кыласы булгач, Алла бу вәхши дөньяга кешеләрне ник тудыра икән соң?.. Бомбага тотылып, нигезенә кадәр җимерелгән шәһәрдә меңәрләп кеше һәлак булган икән, нәрсә, шулкадәр күп гөнаһлы кешеләр яшәгән микәнни анда?.. Күпме кайгы, күпме кан!.. Күпме күз яше!.. Бу хәлләрдән соң да алга таба Җирдә кешеләр яши алачаклар микәнни?»* [6: 51]. Язучының матур табышы булган мондый сораулар укучы өчен уйлану юлларын сыза.

Ә. Закирҗанов та романның фәлсәфилегенә игътибар итә һәм романны әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр яктылыгында тикшереп, З. Хәкимнең әлеге әсәре «тормышның мәгънәсе эчке гармониягә ирешүдән һәм кешедә рухи башлангычны саклаудан гыйбарәт булуын раслый», ди [1: 4086].

Бөек Ватан сугышын гомумкешелек фәлсәфәсе яссылыгында бәяләү татар әдәбияты өчен яңа түгел, әмма мизгелдәге халәтнең киләчәк буыннар, кешелек, милләт өчен мөһим булырга мөмкинлеген үтә калку итеп бирү яңача ачыла.

Хәйдәрнең «аң агышы» рәвешендә бирелгән эчке монологларында милли үзаң белән бәйле фикерләр бар: *«Үз халкына ярдәме тидеме соң аның? Олыгайган саен күңел үз милләтенә ныграк тартыла, җан иң якты учак та, бернинди газ казаны да, һичнинди җылыткычлар да бирә алмый торган җылылык сорый. Һәр күзәнәгеңә якын туган телең, шул телдә сөйләшүче кешеләр генә бирә ала торган җылылык кайдадыр бар бит. Кызы татарча сыкы-быкы гына сөйләшә, кияү бөтенләй белми диярлек, ә оныкны һич өйрәтә алмыйлар»* [6: 11].

Фәлсәфи уйлануларда, диалогларда, җанлы вакыйгаларда бирелгән аскы агымдагы фикерләрне тоемлау авыр түгел: сугыш – гади халык өстенә төшә торган фаҗига; сугышларны китереп чыгаруда аерым кешеләрнең мәнфәгать-интереслары роль уйный; татар кешесе халкының мәнфәгатьләрен дә онытмаска тиеш; татарда сәламәт күзәнәкләр бетмәвен туган халкына якынлыгы тәэмин итә һ. б.

Үзәккә куелган көчле кеше концепциясенең татар егете, солдат, көрәшче итеп бирелеше – милләтнең таза күзәнәкләре бар әле, дигән мәгънәне тоярга ярдәм итүче игътибарга лаеклы үзәк момент. Шуның әйләнәсендә әдәбиятыбызда инде традицион яңгыраган фикерләр, мотивлар хасил була. Мәсәлән, постсовет әдәбиятында күп яңгыраган, нахакка хөкем ителгәннәр мотивы (Светаның этисе, абыйсы мисалында); кешелеклелек, мәрхәмәтлелек (Самат һәм Ортвинның бер-берсенең гомерен саклап калуы, командир Егоровның Саматка ялган отчёт яздыруы, Иван Константинович әсир төшкәч, аңа яхшы мөгамәләдәге немец гаиләсе); кешелексезлек фактлары кабатлану (Светаның ире, Саматның хатыны, хирургка кайбер кешеләрнең мөнәсәбәте һ. б.) шундыйлардан. Җәмгыятьнең аерым шәхес мәнфәгатьләрен санга сукмавы алдагы диалогта дәлилләнә: *«Самат үз кире-сен сөрде: – Иптәш Сталинның әйткәнен оныттыңмыни – без хаклы, шуңа күрә без җиңәчәкбез! – Без, без, без... – диде Тимофей, кызып. – Шул без дип, аерым кеше турында оныталар да инде ул»* [6: 72].

Әсәр Ә. Еникинең психологизм тирән бирелгән «Бала», «Кем җырлады», «Бер генә сәгатькә» кебек хикәяләре, фәлсәфи агым өстенлек иткән Ә. Баян әсәрләре белән беркадәр аваздаш. Ю. Семёновның «Язның унҗиде мизгеле» (1968) романының исеме белән дә интертекстуаль бәйләнеш тоемлана. «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..» романында язучының элегрәк язылган «Телсез күке» театраль романындагы мотивлар да яңача аңлатылыш тапкан.

Күп кенә геройларның җәмгыять кануннарына сукырларча ышанмавы һәрдаим күренеп ала. Әсәрдә төрле фикер-карашлар бәхәсе рәвешендә бирелгән каршылыклы дискурслар калкып чыга. Геройларның совет чынбарлыгы тарафыннан сеңдерелгән фәлсәфәне, тарихи күзаллауларны атлап чыкканлыгы, вакыйгаларның 1944 елда Украинаны фашистлардан азат итү турында баруы белән бәйле, әсәрдә бүгенге вазгыять яктылыгында яңа эчтәлеккә юл салына. Милләтләр язмышы турында уйланырга мәҗбүр итүче аскы агымдагы фикерләрне, мәгънәви тәңгәллекләрне аерып чыгарырга мөмкин. Моңа ишарә түбәндәге өзектә: *«...Синең акылың, гомерең кемгә, нәрсәгә хезмәт итүен анык аңлау мәслихәт. Без, сугышта батырлыклар күрсәтеп, тыныч тормышта ат шикелле җигелеп эшләп, аннары һәр кылган гамәлләребез үзебезгә түгел, ә гомуми бер казанга, дөнья яшәешенең казанына салынып, кайнап торса, – безгә моның фәтвасы бармы соң?.. Татар шигырен немецчага тәрҗемә иткәннәренә сөенергәме, көенергәме?.. Туктале, әти Казанга кайткач, шигырен тәкъдим иткән очракта, берәр татар композиторы җыр язган*

*булыр иде микән?.. Аерым алган кешенең гомере дә, кылган гамәлләре дә бу дөньяда үзеңнеке генә, халкыңныкы гына, авылыңныкы яки шәһәреңнеке генә, хәтта үз илеңнеке генә була алмыйдыр инде, күрәсең. Татар кешесенең шигыренә җыр язганнар... Аны Европада яратып тыңлыйлар. Ә татарлар турында европалыларның күбесе белми дә, ишетми дә»* [7: 17].

*«Аерым кешеләрнең сугыш вакытында мәрхәмәтле булып калулары – сәламәт күзәнәкләрнең исән булуына, аларның кешелек дөньясындагы яман күзәнәкләргә каршы көрәшүенә тиң!»* [7: 16], – ди язучы.

Фикерләрне куәтләүдәге поэтик чараларга килсәк, әсәрдә сәнгатьчә алымнар сирәк, әмма уңышлы кулланыла. Әйтик, чагыштырулар: *«Җыр <...> кайбер мизгелләрне, дисбе төймәләрен тезгәндәй, бер җепкә җыйнады»* [7: 63]; *«Дәүләт өчен син бары тик организмдагы бер күзәнәк кенә»* [6: 72]; *«Һәрберебез киләчәк буыннарга ашлама гына»* [6: 50].

Светаның сүзләре Самат белән булган вакыйгаларга ассоциатив параллель күренеш буларак аңлашыла: *«Беркөнне тәрәзә төбендәге гөлемнең тамырлары көчле булсын өчен, өске ботак-яфракларын кыркыдым... Ботакларын кискәч, гөл нигә тамырларын тирәнгәрәк суза икән?.. Якты дөньяга өметен җуеп, аска таба үсә башлый микән әллә ул?..»* [6: 62]. Бу чагыштыруда милләтләр язмышы белән бәйле башка мәгънәләргә дә урын бар.

Әсәрнең лирик-эмоциональ аһәңен билгели торган бизәкләр – шигырь, җыр юллары, буыннар бәйләнешен күрсәтүче сәгать символы, төрле ассоциацияләр уятучы гөл детале, төш алымы (төш Саматның дәвамы булачагын сиздерә: билгесез зат аның улы буларак кабул ителә) – һәммәсе З. Хәкимнең алдагы иҗатындагыча урынлы кулланылган.

Шул ук вакытта, әсәрнең кайбер җитешсезлекләрен дә күрсәтәсе килә: романның ахыры ашыгып эшләнгән дигән тәэсир кала. Соңгы бүлекләр сөйләп чыгуга корылганлыктан, геройлар берьяклы гына ачылып, җанлы вакыйгалар җитми. Геройларның сугыштан соң исән калуы турындагы өлешне алдагы бүлекләргә үк түгел, бәлки, интрига югалмасын өчен, соңрак кую отышлы булыр иде. Җыр дискын тапшыру да ахырдарак кирәк сыман. Хәйдәр клиникада Винфридның этисе Ортвинның исәнме-түгелме икәнен алданрак сорамый, әңгәмәдәшенең якын кешесе турында хәл белешәсе урында, фәлсәфәгә бирелеп утыра.

Әсәрдә пародоксаль фикерләр бар. *«Бәхетле мизгелләр гомердән кадерлерәк»; «Явызлыкка каршы көрәш игълан итәр өчен, үзеңә дә явыз булу кирәк шул... Җиңәр өчен исә явызлыктан да явызрак булу зарур. Димәк, явызлыкны һич кенә дә җиңү мөмкин түгел»* [6: 42]; *«Сугышларда җиңүгә караганда үз-үзеңне җиңү авыррак»; «Гади кешенең күргәннәрен, кичергәннәрен ул кеше фәкать үзе генә белә. Тарих өчен гади кеше язмышы берни түгел һәм тарихта уелып калыр өчен*

*син я изге кеше, я канечкеч тиран булырга тиеш. Кеше генә булсаң, кемгә кызык син?.. Кайсы шәхеснең чынында нинди булганын дистә еллар узгач кем белсен...*» [6: 41] кебекләре укучыда каршылыклы фикерләр уятмый калмый. Язучы махсус автор маскасы куллана дигән фикер кала.

Фәлсәфи һәм сатирик иҗаты белән узган гасыр ахырында татар әдәбиятын яңа баскычка күтәргән, һәрчак актуаль темаларга мөрәҗәгать иткән язучының әлеге романы бирелеп укыла, уйландыра. Төрле милләт кешесендә яман күзәнәкләргә, яман чыганак – явызлыкка каршы көрәшүче, сәламәт күзәнәкләр бетмәвен тәэмин итә торган, кешегә мизгелдәге адымының нәрсәгә хезмәт итүен аңлап яшәргә омтылыш бирә торган әсәр беркемне дә битараф калдырмый.

**Әдәбият**

1. *Закирзянов А.М.* Нравственно-философские проблемы в романе З. Хакима «Сколько мгновений в одном часе?» // Филологические науки. Вопросы теории и практики Philology. Theory & Practice 2024. Т. 17. Выпуск 11. URL: https://www.researchgate.net/publication/386043284_Moral_and_philosophical_problems_in_the_novel_by_Z_Hakim_How_many_moments_are_there_in_one_hour (мөрәҗәгать итү көне: 19.05.2025).

2. *Заһидуллина Д.Ф.* Әмирхан Еники прозасы: поэтик ачышлар // Фәнни Татарстан. 2024. № 4 (44). 60 – 64 б.

3. *Заһидуллина Д.Ф.* Бөек Ватан сугышы – татар прозасы көзгесендә (татар әдәбиятында сугышны тасвирлауның үзгәреше) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2020. № 2. Б. 51–60. URL: https://echovek.ru/ru/article/d-f-zahidullina-boek-vatan-sugyshy-tatar-prozasy-kozgesend-tatar-dbiyatynda-sugyshny (мөрәҗәгать итү көне: 19.05.2025).

4. *Заһидуллина Д.Ф* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

5. *Миңнуллин Ф.* Затлылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 144 б.

6. *Хәким З.* Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?.. // Казан утлары. 2022. № 7. Б. 9–75.

7. *Хәким З.* Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?.. // Казан утлары. 2022. № 8. Б. 8–64.

***Макарова Венера Фәйзи кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Макарова Венера Файзиевна,***
*доктор филологических наук, доцент,*
*ведущий научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*makarova_vf@mail.ru*

УДК 372.882

*Г.Н. Мөхәрләмова*

# МӘКТӘПТӘ ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУ БАРЫШЫНДА УКУЧЫЛАРНЫҢ ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТЫН ҮСТЕРҮ ЮЛЛАРЫ

В статье рассматривается проблема формирования эмоционального интеллекта у обучающихся путем использования средств родной литературы. Развитие эмоционального интеллекта как одного из ключевых навыков человека XXI века способствует профессиональной реализации человека в современном обществе. В основной школе формирование данного навыка является одним из составляющих компонентов регулятивных универсальных учебных действий, прописанных в части метапредметных результатов в федеральных государственных образовательных стандартах. Эмоциональность обучения – это педагогическое явление, обусловленное целями и задачами обучения и воспитания, повышающее эффективность учебно-воспитательного процесса. В частности, учебный предмет «Родная (татарская) литература» выдвигает требование активного включения эмоциональной сферы в процесс ее изучения. Литература, как искусство слова, воздействуя на чувства человека, влияет на его внутренний мир, глубоко волнует, приводит к художественным переживаниям, доставляет эстетическое наслаждение. Формирование эмоционального интеллекта на уроках родной литературы происходит путем развития способности учащихся испытывать переживания в связи с воссозданием литературных образов, воображением себя в той или иной ситуации, описываемой в литературном произведении; нахождения чувств и переживаний, данных в художественном тексте в процессе его выразительного чтения; применение произведений живописи и музыки, выявления их эмоционального воздействия в процессе анализа литературного произведения; комплексное использование всех факторов и средств усиления эмоциональности в обучении литературе.

**Ключевые слова:** эмоциональный интеллект, эмоция, родная (татарская) литература, чувства и переживания, литературное произведение, выразительное чтение, живопись, музыка.

The article discusses the problem of developing emotional intelligence in students through the use of native literature. The development of emotional intelligence as one of the key skills of the 21st century contributes to the professional realization of individuals in modern society. In primary schools, the development of this skill is one of the components of regulatory universal educational actions, which are part of the meta-subject results in the federal state educational standards. The emotional nature of learning is a pedagogical phenomenon that is determined by the goals and objectives of education and upbringing, and it enhances the effectiveness of the educational process. In particular, the requirement to actively involve the emotional sphere in the learning process is promoted by the subject “Native (Tatar) Literature. Literature, as an art of words, affects a person’s emotions, influences their inner world, evokes deep emotions, leads to artistic experiences, and provides aesthetic pleasure. The formation of emotional intelligence in native literature classes is achieved through the development of students’ ability to experience emotions in connection with the re-creation of literary characters and the imagination of themselves in a particular situation

described in a literary work; the identification of feelings and experiences in a literary text during its expressive reading; the use of works of art and music to identify their emotional impact during the analysis of a literary work; and the comprehensive use of all factors and means to enhance the emotional aspect of literature education.

**Keywords:** emotional intelligence, emotion, native (Tatar) literature, feelings and experiences, literary work, expressive reading, painting, and music.

Кешелек җәмгыятендә кешенең эмоциональ культурасы мәсьәләсе һәрвакыт актуаль булды, бүген дә, XXI гасырда да, «эмоция» һәм «эмоциональлек» төшенчәләре белән бәйле булган эмоциональ интеллект кешенең төп сыйфат күнекмәсе булып санала. Эмоцияләр кешенең тормыш эшчәнлегендә мөһим роль уйный, аны яшәүгә, объектив чынбарлыкны танып белүгә, иҗади эшчәнлеккә, хис-кичерешләре аша үз-үзен тануга, тирә-юньдәгеләр белән аралашуга сәләтле итә [5: 58]. Галимнәр күзәтүенчә, эмоциональ интеллектны балачактан үстерү кешенең алга таба һөнәри эшчәнлегендә уңышлырак, инициативалырак, һәр яңалыкка әзер, үз тормышы белән канәгать булган шәхес итеп формалашуын тәэмин итә [6: 4].

Эмоциональ интеллект төшенчәсе 2021 елда беренче тапкыр яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларына кертелде. Биредә ул регулятив универсаль уку гамәлләренең бер компоненты буларак тәкъдим ителеп, «үзенең һәм башкаларның эмоцияләрен тану, атау һәм алар белән идарә итү; эмоцияләрне билгеләү һәм анализлау; үзеңне башка кеше урынына кую, башка кешенең мотивларын һәм ниятләрен аңлау; эмоцияләрне белдерү ысулын җайга салу» буларак билгеләнгән эмоциональ интеллектны үстерү белән бәйләп бирелә [9]. «Туган (татар) телдәге әдәбият» укытуның төп предмет нәтиҗәләренең берсе булып та укучыларның әдәби әсәрдә тасвирланган тормышның сәнгатьчә чагылышын эмоциональ кабул итү һәм интеллектуаль яктан аңлавы тора.

Эмоциональ интеллект – «эмоцияләрне кабул итү һәм белдерү, эмоцияләрне һәм фикерләрне берләштерү, эмоцияләрне төшенү һәм аңлату, башкаларның һәм үз эмоцияләреңне көйләү» [7] дигән сүз. Эмоциональ интеллект үзеңнең эмоцияләреңне һәм башка кешеләрнең эмоцияләрен аңлау, алар белән идарә итү һәм шул нигездә үзара бәйләнешләр төзү сәләтенә ия булуны билгели [1]. Эмоциональ интеллект гамәли бурычларны хәл итүдә нәтиҗәле мотивация һәм коммуникация нигезендә торып, шәхеснең социальләшүенә ярдәм итеп кенә калмый, бүгенге заман кешесенә хас булган «сыгылмалы күнекмәләр»нең үсеше белән дә тыгыз бәйләнә [10: 5].

Җәмгыятьтә эмоциональ интеллект проблемаларына игътибарның көчәюе, мәктәптә уку-укытуның, аерым алганда тел һәм әдәбият укытуның эмоциональлеге мәсьәләләре белән дә кызыксынуны арттыра. Уку-укытуның эмоциональлеге – уку-укыту һәм тәрбия бирүнең максат-бурычлары белән билгеләнеп, аның нәтиҗәлелеген тәэмин итә торган педагогик күренеш. Аңа бердәм эшчәнлектә укытучының укучыларның эмоцияләренә тәэсир итүе нәтиҗәсендә ирешелә.

Укытучы туган телдәге әдәбият дәресләрендә һәрвакыт укучының әсәр эчтәлегенә, образлар системасына, идея-мәгънәви өлешенә эмоциональ мөнәсәбәтен белдергән җавап алуга ирешергә тырышырга тиеш, чөнки текстка салынган эстетик һәм эмоциональ мәсьәләләр турында фикер алышу барышында укучылар үзләрен, үзләренең эмоциональ дөньясын һәм тирә-юньдәге дөньяны тирәнрәк танып белә алалар. Шуңа күрә конкрет әдәби әсәрне өйрәнүгә бәйле рәвештә укучының хис-кичерешләрен, эмоцияләрен тәрбияләү аларның хис-ихтыяр өлкәсен формалаштыруда әһәмиятле санала.

Уку-укыту, аерым алганда тел-әдәбиятны укыту барышында укучыларда теге яки бу эмоцияләрне һәм хис-кичерешләрне ничек уятырга соң? Моңа нинди юллар белән ирешеп була? дигән сораулар туа.

Әдәби әсәрне эмоциональ кабул итүне көчәйтү чараларын ачыклау, сәнгатьчә фикерләүне активлаштыру, әдәбият дәресләрендә эмоциональ атмосфера тудыру максаты белән аның берничә юлын күрсәтергә мөмкин.

Беренчедән, әдәби әсәрләрнең эмоциональ якларын карау һәм әдәби геройларның хисләрен кичерү сәләтен ачыклау өчен, укучылар үзләрен әсәрдә сурәтләнгән теге яки бу ситуациядә күз алдына китерергә омтыла. Укытучы укучыларны әсәрдә тасвирланган вакыйгаларның шартлы катнашучысы итеп танытып, алардагы хис-кичерешләрне уяту ысуллары турында уйларга тиеш була. «Әсәрнең эмоциональ өлешенең шәрехләнүенә, текстта эмоциональлек «маркерларын» аерып чыгаруга ирешергә кирәк, шул вакытта әсәр героеның (геройларның) эчке дөньясына үтеп була» [6: 67].

Һәр әдәби әсәр укучының тойгысына, хыялына, фикерләвенә тәэсир итә, ягъни ул, фикерне куәтләп, тойгыны ачыклый. Чыннан да, әгәр әдәби әсәр укучының хисси даирәсенә кагылмаса, аны кызыксындырмаса, ул аны бернәрсәгә ышандыра дә алмый. Шул ук вакытта хис-кичерешләрне мәҗбүр итеп уяту мөмкин түгел, укучыга сөенергә, сагынырга, куркырга яки ачуланырга боерып та булмый, ягъни кеше үзендә билгеле бер хисне юктан гына барлыкка китерә алмый. Билгеле бер хисне укучыда уяту өчен, аны әдәби әсәрнең эмоциональ халәтен тулырак ачып бирә алырлык, укучыларны билгеле бер эмоциональ халәткә кертә алырлык ситуациягә куярга кирәк. Әдәбиятны укытуның эмоциональлеге, беренче чиратта, әдәби әсәрнең характерына бәйле. Әдәби әсәр үзе укучыга көчле эмоциональ тәэсир ясарга мөмкин, чөнки беренче чиратта ул хис-кичерешкә, хыялга юнәлгән була. Әдәби әсәр белән эшләгәндә укучының вакыйгаларга һәм геройларга эмоциональ мөнәсәбәтен булдыру, саклау мөһим. Моның өчен укучыдан эмоциональ җавап алырга һәм хис-кичерешләрен чагылдырырга ярдәм итә торган биремнәр сайлап алу зарур. Бу биремнәр укучыларның эчке дөньясын баеталар һәм кичерешләрен төрләндерү мөмкинлеген тәэмин итәләр.

Әсәрне анализлау барышында укучылар төрле хисләр, тойгылар кичерүче төрле геройларның характерлары белән танышалар. Геройның хисләренә кушылып, аларны үз рухи халәте аша кичергән вакытта

укучы үзен шул вакыйгаларда катнашучы итеп тоя, геройның язмышы аңа ят булып күренми, һәм шул вакытта ул үзен, үзенең яшәү рәвешен, хис-кичерешләрен, хыялларын, фикерләрен әдәби геройныкы белән чагыштырып карарга тырыша. Бу очракта, Е.М. Марков әйтүенчә, психологик «күчерү» барлыкка килә, ягъни «укучы үзенең шәхесен әсәр герое шәхесенә күчереп карый, үзен шул герой урынында хис итә, аның образында хәрәкәт итә башлый» [3: 168]. Мондый «күчерү» эмоцияләрне кузгата, реаль ситуацияне кичергән кебек билгеле бер эмоциональ халәт барлыкка китерә. Бу очракта укучы әсәрне ике позициядән чыгып кабул итә башлый: әсәр герое – вакыйгаларда катнашучы һәм әсәрне укучы позициясеннән. Вакыйгада катнашучы буларак, ул геройның алдагы тормышы белән кызыксына. Укучы буларак исә, әсәрдә сурәтләнгәннәргә субъектив бәя бирергә тырыша, ләкин шул ук вакытта, әсәргә үз йөзен, үзе булган чынбарлык сыйфатларын кертә.

Туган (татар) телдәге әдәбияттан яңа федераль эш программаларында [8] 5 нче сыйныф курсына Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыре кертелгән. Әсәр күптөрле хисләр белән сугарылган. Шигырьне укып чыкканнан соң, иң элек, беренчел тәэсирне уртаклашу максаты белән, укучыларга: «Бу шигырь нәрсә турында?» дигән сорауны тәкъдим итеп була. Укучылар шигырь лирик геройның Казанга баруы турында, дип җавап бирәчәкләр. Шагыйрь-лирик герой бу хисләрне Казанга кайтуы белән бәйле рәвештә кичерә. Г. Тукайның «Пар ат» шигырен өйрәнгәндә, укучылар лирик геройның әлегәчә гомер иткән, үзе өчен кадерле булган җирдән аерылган вакытта туган хисләрен билгеләргә тиешләр. Шигырьнең язылу тарихы турында дәреслектә [4: 134–137] бирелгән мәгълүмат белән таныштыру файдалы булачак.

Лирик геройның күңелен төрле уйлар һәм хисләр биләп ала: ул я кайгыра, борчыла, я шатлана, я аны билгесезлектән туган курку хисе били, я хыялларга бирелә, үз максатына омтылып, аның күңелендә өмет уяна. Алга таба да шигырь өйрәнү барышында әлеге хисләрне билгеләтергә тырышабыз. Аларны әсәрне сәнгатьле итеп уку барышында ачыклап була.

Шулай итеп, эмоциональлекне арттыруның икенче юлы әдәби әсәрдәге хис-кичерешләрне сәнгатьле уку аша аңлау сәләтен билгеләүне күздә тота. Шушы максатны күздә тотып, лирик геройның хис-тойгыларын ачыграк чагылдырган әсәрләр сайлана.

Г. Тукайның «Пар ат» шигырен сәнгатьле уку белән үреп анализлаганда, ул, хисләр алмашыну нигезендә, өлешләргә бүлеп укыла. Укучыларга әсәрнең темасы, геройның хисләре турында түбәндәге сорауларны тәкъдим итәргә мөмкин:

1) Шигырьнең беренче өлешендә нәрсәләр сурәтләнә? Лирик герой үзен ничек хис итә? Ул борчыламы, әллә, киресенчә, тынычмы?

2) Шигырьнең кайсы юлларыннан лирик геройның туган җиренә кайтканлыгын белеп була? Туган як табигате ничек тасвирлана?

3) Лирик геройның күңел халәте дүртенче дүртьюллыкта нинди үзгәреш кичерә? Анда нинди уй-хисләр туа? Бу юллар нинди хис белән әйтелергә тиеш?

4) Бишенче-алтынчы дүртьюллыкта лирик герой кемгә мөрәҗәгать итә? Бу юллар нинди хис белән сугарылган?

5) Лирик герой ни өчен моңсулана? Аның сәбәбе нәрсәдә?

6) Лирик герой нәрсәдән курка? Бу юлларны ничек укырга кирәк?

7) Кайсы юлларда хис-кичерешләр кинәт үзгәрә? Бу нәрсәгә бәйле? Кучер һәм лирик герой сүзләрен нинди интонация белән укырга кирәк?

8) Шигырь ахырында лирик геройның күңелен нинди уй-кичерешләр биләп ала?

Укучылар бу сорауларга җавап бирү барышында шигырьнең «лирик геройның кичерешләре, рухи дулкынланулары турында» булуын билгелиләр, «аның борчылулары берничә ел яшәгән җиреннән аерылуы белән бәйле» булуын, «аның тиздән туган якларын күрүенә шатлануын», «лирик герой бередә киләчәге якты булачагына өметләнүен» ачыклыйлар. Шулай итеп, әлеге барлык сораулар лирик геройның кичерешләрен күзәтергә булышачак һәм шигырьне уку барышында шул ук хисләрнең укучыларда да тууына китерәчәк.

Сорауларга җавап биргәндә, укучылар сәнгатьле уку аша шигырьдә булган хис-кичерешләрне дөрес билгеләргә өйрәнәләр, тиешле интонацияне табалар. Шуның аша лирик геройның, туган җиргә кайту рәхәтен тоеп, канәгатьлек, күңел тынычлыгы; торган җир белән бәхилләшү, күнегелгән тормыштан аерылу белән бәйле борчылу-хәсрәтләнү, эч пошу; туган җиргә ышаныч, язмышын мәңгегә аның белән бәйләү, бәхетле булу теләге туу сәбәпле шатлык, өмет, ышаныч хисләре кичерүен ачыклыйлар.

Әлеге хис-кичерешләрне ачыклаганда, чиктәш сәнгать әсәрләреннән файдалана алабыз. Әдәбиятны чиктәш сәнгать төрләре белән берлектә өйрәнү укучыларга билгеле бер мәдәни катламга үтеп кереп, аның күптөрлелеген һәм бөтенлеген күрү мөмкинлеге генә биреп калмый, ә бәлки әдәби әсәрне кабул итүнең эмоциональлеген көчәйтеп, хисләр культурасы булдырырга ярдәм итә.

Әдәбият дәресләрендә эмоциональлекне үстерүнең өченче юлы нәкъ менә әдәби әсәрне өйрәнүдә кулланыла торган тасвирый сәнгать әсәрләренең эмоциональ тәэсирен билгеләүне максат итә, чөнки сәнгать төрләреннән иң элек тасвирый сәнгатьнең әдәбиятка тәэсире зур. Аның вазифасы – укучыларга тасвирланган тормышны, күренешләрне конкрет, тулы, ачык аңларга ярдәм итү, эмоциональ тәэсирне көчәйтү, эстетик күзаллауны киңәйтү. Бүгенге көндә Татарстан рәссамнары иҗат иткән күпсанлы уңышлы картиналар, иллюстрацияләр бар. Алар арасында төрле әдәби әсәрләргә нигезләнеп язылганнары да шактый.

Г. Тукайның «Пар ат» шигырен өйрәнгәндә, укучыларга Ф. Якупов яки Б. Урманче ясаган иллюстрацияләрне күрсәтеп була. Ф. Якупов иллюстрациясе белән эшләгән вакытта түбәндәге сораулар-биремнәрдән файдаланырга мөмкин: «Пар ат» шигыренә хас нинди үзенчәлекләр аны рәсем рәвешендә чагылдырырга мөмкинлек бирә? Рәсемдә сез кемнәрне күрәсез? Лирик герой белән рәсемдә сурәтләнгән кеше

арасында нинди бәйләнеш бар? Аның турында сез нәрсә әйтә аласыз? Рәссам лирик геройның эчке дөньясын чагылдыра алганмы? Рәсемдә бирелгән пейзаж нинди? Ни өчен ул төссез итеп бирелә? Рәссам аның аша нинди эмоцияләрне күрсәтергә теләгән? Табигать күренеше шигырьнең эмоциональ халәтенә үтеп керү мөмкинлеге бирәме? Рәсемдә нинди төсләр өстенлек итә? «Пар ат» шигырендәге төсләр белән алар ничек яраша? Атларга игътибар итегез. Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен бер ат – ак, икенчесе кара төстә? Моның аша рәссам ни әйтергә теләгән икән? Иллюстрациядән чыгып, шагыйрь күңелендә нинди хисләр туганын билгеләп буламы? Бу сәфәр аңа ошыймы, аерылышу аңа шатлык һәм канәгатьлек хисе бирәме? Ничек уйлыйсыз, алда аны нәрсә көтә? Рәсемдә кайсы ел фасылы сурәтләнгән? Ни өчен?

Укучылар эш барышында рәссам тарафыннан шигырь героеның торган җиреннән аерылу сагышы белән янган вакытлары сурәтләнүен билгелиләр. Агачларның шәрәлеге, төсләрдәге караңгылык, кучерның бик җитди утыруы «бер матурның балдагын я калфагын» җырламавы, геройның йөзендәге җитдилек тә шуны күрсәтеп тора. Атларның ашкынып чабуы, геройның еракка төбәлгән карашы туган җиргә омтылу, аңа өмет баглауны гәүдәләндерә. Шулай ук укучылар Г. Тукайга үзе яшәгән шәһәрдән аерылу авыр булуын, аның Казан белән очрашудан куркуын, шикләнүен әйтәләр, «ләкин шул вакытта аның сөенүен», «гомеренең озакламый рәтләнәчәгенә өмет баглавын» күреп алалар, «ак ат, бәлки, өмет кенә булыр, ул, киртәләрдән курыкмыйча, алга таба чаба, ә кара ат – ул куркулар, алар инде онытылырга тиеш»леген билгелиләр.

Әдәбият укыту барышында эмоциональлекне тәэмин итүнең дүртенче юлы әдәби әсәрне өйрәнүдә кулланыла торган музыка сәнгате әсәрләренең эмоциональ тәэсирен ачыклауга юнәлдерелгән. Бу максатны күздә тотып, билгеле бер дәрәҗәдә әдәби әсәр белән бәйле булган төрле характердагы музыкаль әсәрләрне файдалана алабыз. Төп максат – укучыларның эмоцияләрен активлаштыру, чөнки музыка «конкрет вакыйгаларны чагылдырмый, ә аларның эмоциональ мәгънәсен тапшыра» [2: 54].

Күпчелек очракта укытучы дәрестә өйрәнелә торган теге яки бу лирик әсәргә язылган көйләрдән файдалана. Аларны әсәрне өйрәнгәннән соң да, өйрәнү барышында да яңгыратып була. Хисләрнең җыр аша бирелүе укучыда көчле тойгылар уята. Мәсәлән, Г. Тукайның «Туган тел», «Әллүки» шигырьләре көйгә салынган, «Пар ат» шигыренә көйне халык үзе иҗат иткән. Дәрестә бу җырларны тыңлау укучыга лирик геройның кәефен, аның фикерләрен аңларга, хис-кичерешләрен тирәнрәк төшенергә булыша.

Бишенчедән, әдәби әсәрне эмоциональ кабул итүне көчәйтү максатында, алда күрсәтелгән барлык чараларны комплекслы рәвештә дә кулланып була. Моңа без әдәби әсәрнең эмоциональлеген, сәнгатьле уку, музыка һәм тасвирый сәнгать әсәрләреннән файдалануны кертәбез.

Шулай итеп, туган (татар) телдәге әдәбият дәресләрендә эмоциональлекне үстерүдә күрсәтелгән юллардан файдалану әдәби әсәрне

тирәнрәк, эмоциональрәк кабул итәргә һәм аңларга булыша, укучыларның эмоциональ-образлы фикерләүләрен киңәйтә һәм, нәтиҗә буларак, эмоциональ интеллектны үстерергә ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. *Гоулман Д.* Эмоциональный интеллект / пер. с англ. А.П. Шаевой. М.: АСТ, 2009. 480 с.

2. *Исламов Ф.И.* Татар әдәбиятын укытканда сәнгатьнең башка төрләреннән комплексы файдалану методикасы (V–XI сыйныфлар). Казан: Мастерлайн, 1997.108 б.

3. *Марков Е.М.* Искусство как процесс. М.: Искусство, 1970. 239 с.

4. *Мухарлямова Г.Н., Абдуллина Д.М.* Родная (татарская) литература: Туган телдәге әдәбият. 5 класс: учебник для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, владеющих родным (татарским) языком). Казань: Изд-во АН РТ, 2024. 175 с.

5. *Мухарлямова Г.Н., Абдуллина Д.М.* Формирование эмоционального интеллекта у обучающихся средствами художественной литературы (на примере обучения родной (татарской) литературе) // Казанская наука. № 9, 2023. Казань: Рашин Сайнс. С. 58–60.

6. Научно-методические рекомендации по формированию эмоционального интеллекта обучающихся в образовательной среде (основная школа): методические рекомендации / под общ. и науч. ред. С.В. Ивановой. М.: ФГБНУ «Институт стратегии развития образования РАО», 2022. 23 с.

7. *Сергиенко Е.А., Ветрова И.И.* Эмоциональный интеллект: русскоязычная адаптация теста Мэйера – Сэловея – Карузо [Электронный ресурс] // Психологические исследования: электрон. науч. журн. 2009. № 6 (8). URL: http://psystudy.ru (мөрәҗәгать итү көне: 31.10.2025).

8. Федеральная рабочая программа по учебному предмету «Родная (татарская) литература». М., 2023. Режим доступа: https://static.edsoo.ru/projects/fop/index.html#/sections/20020432 (мөрәҗәгать итү көне: 02.11.2025).

9. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования. М.: Просвещение, 2021. 124 с.

10. Эмоциональный интеллект школьника: становление и развитие: монографический сборник / под общ. и науч. ред. С.В. Ивановой. М.: ФГБНУ «Институт стратегии образования РАО», 2022. 203 с.


*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Мөхәрләмова Гөлназ Нурфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге мөдире*

***Мухарлямова Гульназ Нурфатовна,***
*кандидат филологических наук, заведующий отделом национального образования Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*mukharlamgul@gmail.com*

УДК 821.512.145

*Г.В. Һадиева*

# «ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ҺӘМ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ САННАРДА» ИНФОГРАФИКАСЫ

На сегодняшний день актуальна разработка наглядных дидактических материалов для популяризации татарской литературы среди школьников путем представления литературных фактов и цифр, таких как количество написанных произведений, объем опубликованных страниц, популярность произведений, а также биографические данные самих писателей. В статье представлен проект «Инфографика “Татарские писатели и поэты в цифрах”».

Проект представляет собой серию инфографик, объединенных общей темой – количественный анализ жизни и творчества выдающихся татарских классиков. Данная работа направлена на представление значимых цифровых показателей деятельности татарских писателей и привлечение внимания к их творчеству через визуально привлекательные и понятные формы подачи материала. Тем самым идет повышение интереса учащихся к изучению родной литературы и формированию навыков функциональной грамотности. Современная инфографика по татарской литературе сделает уроки наглядными и интересными, а обучение увлекательным. Статья рекомендована для педагогов образовательных учреждений.

**Ключевые слова:** татарские писатели, инфографика, цифры, информация, Федеральный государственный образовательный стандарт, биография, творчество.

Today, the development of visual didactic materials for the popularization of Tatar literature among schoolchildren is relevant by presenting literary facts and figures, such as the number of written works, the volume of published pages, the popularity of works, as well as the biographical data of the writers themselves. The article presents the Infographic project “Tatar writers and Poets in numbers”.

The project is a series of infographics united by a common theme – a quantitative analysis of the life and work of outstanding Tatar classics. This work is aimed at presenting significant digital indicators of the activities of Tatar writers and drawing attention to their work through visually attractive and understandable forms of presentation of the material. This increases students’ interest in studying native literature and developing functional literacy skills. Modern infographics on Tatar literature will make lessons clear and interesting, and learning exciting. The article is recommended for teachers of educational institutions.

**Keywords:** Tatar writers, infographics, figures, information, Federal State Educational Standard, biography, creativity.

Бүгенге заманның үзенчәлеге – чикләнгән вакыт эчендә чикләнмәгән күләмдә мәгълүмат табу һәм үзләштерү. Бу процесста традицион формалар гына кулланылса, кеше әлеге күләмне физик яктан эшкәртә алмый һәм килеп туган проблеманы чишү вариантларын эзләргә тиеш була.

Мәгариф системасында барган үзгәрешләр дә (Федераль дәүләт белем бирү стандартлары [5]) укучыларның зур күләмдәге мәгълүматны эзләү, эшкәртү һәм үзгәртү белән бәйле күнекмәләрен үстерүне таләп итә.

Инфографика (*лат. informatio – аңлату, хәбәр итү*) – катлаулы мәгълүматны тиз һәм уңайлы, аңлаешлы итеп тәкъдим итүнең график алымы. Аны информацион дизайнның бер төре дип тә атыйлар [1: 153]. Мәсәлән, 5 биттән артык текст бер график рәсемгә кереп бетәргә мөмкин. Бүгенге көндә бу алым белем бирү өлкәсендә дә актив кулланыла башлады. Заманча инфографика куллану белем бирүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итә, визуаль грамоталылыкны арттыра, образлы күзаллауны үстерә.

Белем бирү процессында инфографика мәгълүматны кабул итүнең берничә каналын берьюлы эшләтеп җибәрә. Ачык күренеп торган бәйләнешләр булу бер элементтан икенчесенә күчәргә, өйрәнелә торган объектның, предметның, процессның яки күренешнең төп үзенчәлекләрен әйтеп бирергә мөмкинлек бирә.

Визуальләштерү барышында һәрбер объект турында күбрәк мәгълүмат туплана, тема ачыла һәм төгәлләштерелә, укучыларга белем бирү өчен яңа чаралар (дәресне алып бару методикасы, күрсәтмә материал, интеллектуаль карталарны файдалану) куллануны тәэмин итә [1: 153].

Бүген әдәбият дәресләре саны кимегәндә, укытучыга материалны тиз һәм аңлаешлы итеп аңлатырга кирәк. Шушы кыска вакыт эчендә язучылар һәм шагыйрьләр турында күзаллау булдыру, алар турында күбрәк мәгълүмат җиткерү – татар теле һәм әдәбияты укытучысының бурычы. Бу проект әдәби фактларны цифрларда күрсәтеп, замана укучысына мәгълүматны үзләштерүне кызыклы һәм уңайлы итә. Татар әдәбияты буенча дидактик материаллар укытучының эшен җиңеләйтүгә юнәлтелгән.

«Туган телдә әдәбият» предметы буенча Федераль эш программасына кергән язучылар исемлеге «Татар язучылары һәм шагыйрьләре саннарда» инфографикасын төзү өчен кулланылды. 5 нче сыйныф өчен әдәбият дәреслегенә кертелгән 5 язучының тормыш юлы һәм иҗаты эшләнелде [2]. Инфографикада Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Туфан Миңнуллин, Фәнис Яруллин һәм Роберт Миңнуллинның тормыш юлы, иҗаты белән бәйле фактлар яктыртылды.

«Татар язучылары һәм шагыйрьләре саннарда» инфографикасы күренекле татар әдипләренең тормышы һәм иҗаты турында биографик һәм статистик мәгълүматларны визуальләштерүгә юнәлтелгән. Шул рәвешле, Татарстан Республикасы оешмаларында укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыруга да нигез була.

Дәресләргә кирәкле булган мәгълүматны визуальләштерү өчен Publisher, Power Point кебек программалар һәм https://leonardo.ai/ һәм https://freepik.com нейрочелтәрләре кулланылды. Инфографика ярдәмендә басылган китаплар саны һәм алар тәрҗемә ителгән телләр

саны, әдәби эшчәнлекнең башлангычы, иҗат эшчәнлегенең дәвамлылыгы һәм язучылар тормышындагы башка кызыклы фактлар алынды. Шул рәвешле мәгълүматны күрсәтмәлелек аша кабул итү гуманитар һәм цифрлы фикерләүне берләштерергә ярдәм итә.

Әлеге хезмәт татар телендә белем бирүче оешмаларның татар теле һәм әдәбияты укытучыларына адреслана. Шулай ук төрле күргәзмәләрдә, китапханә һәм музей экспозицияләрендә белем бирү максатыннан кулланыла ала. Әдәбият темасына багышланган тематик чараларда һәм социаль челтәрләр өчен дә визуаль контент буларак куллану мөмкинлеге бар.

Әлеге проектның максаты – рәсем, тамгачыклар һәм шартлы элементлар ярдәмендә танылган язучы һәм шагыйрьләрнең тормыш юлын һәм иҗатын саннарда аңлаешлы итеп күрсәтү.

Проектның бурычлары:

– татар язучылары һәм шагыйрьләренең тормышы һәм иҗаты турында дөрес булган мәгълүматны җыю, өйрәнү;

– төгәл структурасы булган һәм үзара бәйләнгән тематик инфографика сериясен төзү;

– мәгълүматны кабул итәргә уңайлы форматны сайлау.

Проектны эшләгәндә язучы һәм шагыйрьләр турында түбәндәге параметрлар кертелде:

– һәр автор буенча тормыш юлы белән бәйле вакыйганы чагылдырган даталарны эченә алган кыскача белешмә;

– тормыш дәверендә язылган әсәрләр саны;

– яшәү урыны;

– биография белән бәйле кызыклы фактлар;

– китаплар тәрҗемә ителгән телләр саны һәм исемлеге;

– беренче әсәрнең басылып чыгу вакыты;

– әдәби премияләр исемлеге;

– әсәрләрнең популярлык дәрәҗәсе һәм тиражлары;

– һәр автор исеме белән бәйле хәтер (һәйкәлләр һ. б.)

Мәгълүмат чыганаклары булып әдәби энциклопедияләр [4], интернет чыганаклар һәм язучыларның рәсми сайтлары хезмәт итте. Шулай ук шәхси музейларда сакланган материаллар да инфографикада урын алды. Мәсәлән, Туфан Миңнуллинның шәхси музеендагы (Кама Тамагы шәһәр тибындагы посёлогы) әдипнең ручкалары саны инфографикада чагылыш тапты.

Әлбәттә, инфографиканы эшләү барышында билгеле бер авырлыклар да килеп туды. Мәсәлән, Габдулла Тукай [6], Муса Җәлил [3] кебек шагыйрьләрнең иҗаты һәм тормыш юлы җентекләп өйрәнелгән, фундаменталь хезмәтләр күп, материал табу, аларны саннарга әйләндереп, инфографика эшләү уңышлы булды. Ләкин Габдулла Тукай, Муса Җәлилнең портретларын ясау максатыннан, ясалма интеллект өчен сыйфатлы фотоматериал табу проблема тудырды.

Туфан Миңнуллин, Фәнис Яруллин һәм Роберт Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты исә тирәнтен өйрәнелгән дип булмый. Бу

язучылар турында фәнни хезмәтләр аз. Санап кителгән язучылар XXI гасырда яшәгән, ләкин аларның тормышы һәм иҗаты турында мәгълүмат базасы көчле түгел.

Инфографика, кабул итү җиңелрәк булсын өчен, минималистик дизайн, төс кодировкасы һәм пиктограммалар кулланып, заманча стильдә эшләнелде. Һәр авторга аерым төс кулланылды һәм ул яшәгән чор, аның иҗаты белән бәйле символик образ тәкъдим ителде. Мәсәлән, Габдулла Тукай – каләм, Муса Җәлил – карандаш, Фәнис Яруллин – язу машинасы, Туфан Миңнуллин – авторучка, Роберт Миңнуллин – ноутбук.

«Татар язучылары һәм шагыйрьләре саннарда» инфографикасы татар язучыларының тормыш юлы һәм иҗатына кызыксыну булдыру, аларның дәрәҗәсен күтәрү һәм татар әдәбиятын өйрәнүгә омтылыш булдыру максатыннан эшләнде. Димәк, уку материалын инфографика ярдәмендә визуальләштерү берничә педагогик бурычны хәл итәргә мөмкинлек бирә: әдәбият буенча белемнәр формалаштырыла, тәнкыйди һәм визуаль фикерләү үстерелә, уку һәм танып белү эшчәнлеге активлаштырыла. Бу проектны дәресләрдә куллану катлаулы һәм күләмле материалны үзләштерергә ярдәм итәр дип ышанабыз.















**Әдәбият**

1. *Григорьева Н.В.* Инфографика как способ визуализации учебной информации // Алгоритмы высшей школы. 2019. № 3. С. 151–156.

2. *Мухарлямова Г.Н., Абдуллина Д.М.* Родная (татарская) литература: Туган телдәге әдәбият. 5 класс: учебник для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, владеющих родным (татарским) языком). Казань: Изд-во АН РТ, 2024. 175 с.

3. Муса Җәлил – документларда / [төз. Р. Исламов]. Казан: Җыен, 2021. 823 б.

4. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Фолиант, 2017. 5 т. 826 б.

5. Федеральные государственные образовательные стандарты. URL: https://fgos.ru (мөрәҗәгать итү көне: ).

6. *Фридерих М.* Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 343 с.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024.*

***Һадиева Гөлнара Васил кызы,***
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы*

***Хадиева Гульнара Василовна,***
*старший преподаватель кафедры татарского языка и литературы Института развития образования РТ*

*gulnarahgv@mail.ru*

УДК 811.512.145

*А.М. Сәлахов*

# XIX – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР МӘДРӘСӘЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ГАРӘП ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ БУЕНЧА УКУ ӘСБАПЛАРЫ

Данная статья посвящена краткому описанию издававшихся в типографиях Казани в конце XIX – начала XX вв. учебных пособий по арабскому языку средневековых восточных авторов с попыткой выявления их особенностей и различий.

В указанный период в Казани издавались следующие учебные пособия по грамматике арабского языка: «аль-Анмузадж» аз-Замахшари с комментарием аль-Ардабили, «аль-Кафия» Ибн Хаджиба с комментарием аль-Джами, «аль-‘Авамиль аль-ми’а» аль-Джурджани, «Мукаддима-и Бедон», «Шарх-и ‘Абдуллах», «Сарф Му‘иззи».

В трудах аз-Замахшари и Ибн Хаджиба изложена арабская грамматика в целом: морфология и синтаксис. Работа аль-Джурджани посвящена синтаксису; в ней описаны грамматические факторы, требующие постановки имен и глаголов в том или ином падеже или наклонении соответственно. «Мукаддима-и Бедон» представляет собой краткий курс морфологии арабского языка; в «Шарх-и ‘Абдуллах» подробно изучаются породы глагола; в «Сарф Му‘иззи» изложены изменения, происходящие в парадигме глагола.

**Ключевые слова:** сочинения по грамматике арабского языка, татарские медресе, аз-Замахшари, «аль-Анмузадж», Ибн Хаджиб «аль-Кафия», аль-Джурджани «аль-‘Авамиль», «Мукаддима-и Бедон», «Шарх-и ‘Абдуллах» «Сарф Му‘иззи», морфология, синтаксис.

This article is devoted to a brief description of the textbooks on the Arabic language by medieval Eastern authors published in Kazan printing houses in the late 19th – early 20th centuries, with an attempt to identify their features and differences.

During the specified period, the following textbooks on Arabic grammar were published in Kazan: “al-Anmuzaj” by az-Zamakhshari with the commentary of al Ardabili, “al-Kafiya” by Ibn Hajib with the commentary of al-Jami, “al-‘Awamil al mi’a” by al-Jurjani, “Muqaddima-i Bedon”, “Sharh-i ‘Abdullah”, “Sarf Mu‘izzi”.

The works of al-Zamakhshari and Ibn Hajib deal with Arabic grammar in general: morphology and syntax. Al-Jurjani’s work is devoted to syntax; it describes the grammatical factors that require the placement of names and verbs in a particular case or mood, respectively. The “Muqaddimah-i Bedon” is a short course in Arabic morphology; the “Sharh-i Abdullah” studies verb forms in detail; and the “Sarf Mu‘izzi” describes the changes that occur in the verb paradigm.

**Keywords:** works on Arabic grammar, Tatar madrasahs, az-Zamakhshari, al Anmuzaj, Ibn Hajib, al-Kafia, al-Jurjani, al-Awamil, Muqaddima-i Bedon, Sharh-i ‘Abdullah, Sarf Mu‘izzi, morphology, syntax.

Гарәп телен өйрәнү өчен уку әсбаплары буларак озак вакыт дәвамында татар мәдрәсәләрендә бөтен мөселман дөньясында популяр булган әз-Зәмәхшәринең «әл-Әнмүзәҗ» (Үрнәк), Ибне Хаҗибның

«әл-Кафия» (Тулы [трактат]), әл-Җөрҗанинең «әл-Гавамил» (Грамматик [факторлар]) һ. б. кулланылган.

Мәхмүд бине Гомәр әз-Зәмәхшәри (1074–1144) – мәшһүр дин галиме, филолог һәм әдәбиятчы, күпсанлы хезмәтләр авторы, мәшһүр «әл-Кәшшаф» ([Мәгънәләрне] ачучы) тәфсиренең төзүчесе [4]. Аның «әл-Әнмүзәҗ» китабы Идел-Урал җирлегендә яшәгән татарлар арасында гына түгел, бәлки бөтен төрки дөньяда да киң таралыш тапкан булган. Әз-Зәмәхшәри тарафыннан элегрәк язылган «әл-Мөфассал» (Аңлатма) китабының кыскартмасыннан гыйбарәт [11: 180] бу трактатта гарәп теле грамматикасының төп мәсьәләләре кыскача өйрәнелә.

Грамматик материал, традицион рәвештә, сүз төркемнәрен аерып чыгарудан башлана: исем, фигыль, кисәкчә; аларның һәркайсына аерым бүлек (баб) багышлана.

Исем бабында аның билгеләре: алдында предлоглар, билгелелек артикле *(-әл)* килә алуы, изафә конструкциясе ясаулары, ахырына *-н* суффиксы ялгана алуы), уртаклык (исмел-җенес) һәм ялгызлык (галәм) исемнәренә бүленүе карала; баш (әр-рәфгъ), иялек (әл-җәрр), төшем (ән-нәсб) килешләре һәм аларның күрсәткечләре, ике килешле исемнәр һәм бу күренешнең лексик-грамматик сәбәпләре аңлатыла [2: 8–30].

Җөмләдәге функцияләренә карата, баш килештә (әл-мәрфугат) куела торган исемнәр фигыль җөмләдә – ия (әл-фагыйль), исем җөмләдә ия (әл-мөбтәда) белән хәбәр булып килә ала дип билгеләнә. Берлек сандагы исемнән тыш, хәбәрнең түбәндәге төрләре күрсәтелә: исем җөмлә, фигыль җөмлә, шарт җөмлә, хәл җөмлә белән бирелгән хәбәр. Хәбәрнең ия алдыннан килү мөмкинлеге, ия белән хәбәрнең берсенең төшеп кала алуы билгеләнә. *Кәнә* (булды) фигыленең субъекты, *-иннә* көчәйтү кисәкчәсенә ияргән хәбәр, *-лә* җенеснең юклыгын күрсәтә торган кисәкчәгә ияргән хәбәр; *-мә*, *-лә* юклык кисәкчәләренә ияргән исем турында мәгълүмат бирелә [2: 31–39].

Хезмәттә төшем килешендәге (әл-мәнсубат) исемнәрнең җөмләдәге функцияләре дә санап кителә: тәмамлык (фигыль мәгънәсен көчәйтү өчен кулланылган абсолют тәмамлык – мәфгулен мотлак), фигыльнең объектын белдергән тәмамлык (мәфгулен биһ), чакыру кисәкчәсеннән соң килгән исем (әл-мөнәда), урын-вакыт хәле (мәфгулен фиһ – зарыф), эшне субъект белән бергә башкаруны белдерә торган тәмамлык (мәфгулен мәга), сәбәп-максат хәле (мәфгулен ләһ), рәвеш хәле (хәл), махсус аныклагыч (тәмйиз), *-иллә* (кала, тыш) кисәкчәсе ярдәмендә ясалган чыгарма, *-кәнә* фигыленең хәбәре, *-иннә* кисәкчәнең исеме, җенеснең юклыгын күрсәтә торган *-лә* кисәкчәсенә ияргән исем, *-мә*, *-лә* кисәкчәләренә ияргән хәбәр [2: 40–59].

Түбәндәге очракларда исемнәр иялек килешендә (әл-мәҗрурат) килә дип аңлатыла: 1) изафәнең икенче кисәге, ягъни ярашмаган аергыч булу, 2) предлогка иярү. Изафәнең әл-мәгънәвийя (мәгънәви, ягъни эчендә предлог мәгънәсе булган) һәм әл-ләфзыйә (сөйләмдә чагыла торган) дигән төрләре аерып күрсәтелә [2: 59–60].

Алмашлык (зат, күрсәтү һәм нисби алмашлыклар), исем фигыль, рәвеш сүз төркеменә караган сүзләргә, кайбер сүзтезмәләр (әл-мөрәккәбат) һәм кинаяләргә китап авторы килеш кушымчаларының ялганмавын күрсәтә [2: 64–67].

Хезмәтнең исем бабында шулай ук икелек, күплек сан формалары һәм аларның төрләре: ир җенесендә төзек күплекләр (җәмгъ мөзәккәр сәлим), хатын-кыз җенесендә төзек күплекләр (җәмгъ мөәннәс сәлим), сынык күплекләр (әл-җәмгъ әл-мөкәссәр) өйрәнелә; билгелелек-билгесезлек категориясе турында мәгълүмат бирелә; ир-ат (әл-мөзәккәр) һәм хатын-кыз җенесенә (әл-мөәннәс) караган исемнәр һәм аларның кушымчалары; сүзләрнең уртак формалары; кечерәйтү исеме (әл-мөсаггар) һәм аның ясалышы; нисби сыйфат (әл-мәнсүб) һәм аның ясалышы; саннар (әсма әл-гадәд) һәм аларның ясалышы, саналмышларның килеш формалары кебек мәсьәләләр төгәл аңлатыла [2: 67–76]. Әз-Зәмәхшәри фигыль мәгънәсенә ия булган исемнәр (әсма әл-әфгаль): инфинитив (масдар), сыйфат фигыль (исмел-фагыйль), төшем юнәлешендәге сыйфат фигыль (исмел-мәфгуль), фигыльгә охшатылган сыйфат (әс-сыйфә әл-мөшәббәһ), артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат (әфгаль әт-тәфзыйл) һәм аларның синтаксик үзенчәлекләренә дә махсус туктала [2:76–78].

Фигыль бабында әлеге сүз төркеменең төп грамматик үзенчәлекләре күрсәтелә: үткән (әл-фигыль әл-мадый), хәзерге-киләчәк (әл-фигыль әл-мөдаригъ) заман формалары булуы, киләчәк заман формасының *-сә*, *-сәүфә* алкушымчалары ярдәмендә ясалуы, киселгән наклонение алкушымчалары (әл-җәвазим) ялгана алуы һ.б. [2: 79–80]. Фигыль наклонениеләренә килгәндә, гарәп телендә аның өч формасы күрсәтелә: хикәяләү (рәфгъ әл-мөдаригъ), теләк (насб әл-мөдаригъ) һәм боеру наклонениясе (җәзм әл-мөдаригъ), шуларның һәрберсенең нинди чаралар ярдәмендә барлыкка килүе мисаллар белән аңлатыла [2: 79–81]. Хезмәттә шулай ук боерык фигыльнең ясалу ысуллары, көчемле һәм көчемсез фигыльләр, аларның грамматик мәгънәләре, фигыльне көчемле ясый торган грамматик факторлар, фигыльнең бер, ике, өч тәмамлык ияртә алуы (аңа буйсынган исемнәрнең төшем килешендә торуларын таләп итүе), төшем юнәлеше (әл-фигыль әл-мәбни лил-мәфгуль) һәм аның ясалуы турында аңлаешлы, төгәл мәгълүмат бирелә [2: 81–82].

Кисәкчәләр (әл-хоруф) бабында[1] аларның лексик-семантик төрләре һәм грамматик функцияләре аңлатыла. Кисәкчәләрнең түбәндәге төрләре күрсәтелә: исемне иялек килешенә куя торган хәрефләр (хоруф әл-идафә), фигыльгә охшаган хәрефләр (әл-хоруф әл-мөшәббәһ бил-фигыль), теркәгечләр (хоруф әл-гатф), юклык кисәкчәләре (хоруфән-нәфи), игътибар кисәкчәләре (хоруф әт-тәнбиһ), чакыру кисәкчәләре (хоруф ән-нида), раслау кисәкчәләре (хоруф әт-тасдыйк), чыгару кисәкчәләре (хоруф әл-истисна), эндәшү кушымчалары (хоруф

[1] Татар телендә бу бабка, кисәкчәләрдән тыш, кайбер кушымчалар, бәйлекләр һәм теркәгечләр керә.

әл-хитаб), нисби алмашлыклар (хоруф әс-сыйлә), аңлату кисәкчәләре (хәреф әт-тәфсир), масдар кисәкчәләре (әл-хәрфән әл-масдарийан), өндәү кисәкчәләре (хоруф әт-тәхдыйд), якынлаштыру кисәкчәсе (хоруф әт-тәкъриб), киләчәк заман кисәкчәләре (хоруф әл-истикъбаль), сорау кисәкчәләре (хәреф әл-истифһам), шарт кисәкчәләре (хәреф әш-шарт), сәбәп кисәкчәсе (хәреф әт-тәгълил), тыю кисәкчәсе (хәреф әр-рәдгъ), *-ләм* кисәкчәсенең мәгънәләре, хатын-кыз (женский род категориясе) (тае-тәэнис) кушымчасы, *-нун* көчәйтү кисәкчәсе (ән-нун әл-мөәккәд), *-һә* тукталыш кушымчасы [2: 87–97].

Татар мәдрәсәләрендә киң кулланылган гарәп теле дәреслекләренең тагын бер авторы – Ибне Хаҗиб (Госман бине Гомәр әл-Әснани) (1174–1249). Ул – ислам тарихында танылган гарәп теле галимнәренең берсе, төрле фәннәрдән күпсанлы хезмәтләр авторы [3].

«Әл-Кафия» Ибне Хаҗибнең гарәп теле грамматикасына багышланган иң беренче хезмәте булып исәпләнә. Бу трактатка Ибне Хаҗиб үзе үк «Шәрхел-Кафия» («Кафиягә аңлатма») дип исемләнгән аңлатма язган. Шулай ук ул, «әл-Кафия»не шигъри формада да язып («әл-Вафия фи назмел-Кафия» («әл-Кафия»нең шигъри формасы [булган] «әл-Вафия» [китабы]), аңа «Шәрхел-Вафия назмел-Кафия» дигән аңлатма төзегән [5: 25]. Гомумән, «әл-Кафия»гә 124 аңлатма язылганлыгы мәгълүм [5: 51].

Структура һәм эчтәлекләре ягыннан, кайбер нюансларны игътибарга алмасак, әз-Зәмәхшәри белән Ибне Хаҗибнең хезмәтләре тәңгәл. «Әл-Кафия»дә дә, «әл-Әнмүзәҗ»тәге кебек үк, өч килешнең берсендә килә торган җөмлә кисәкләре, ахыры үзгәрми торган сүзләр, исемнең билгелелек/билгесезлек категориясе, саннар, җенес категориясе, икелек һәм күплек саннары, күплекнең төрләре, фигыль мәгънәсенә ия булган исемнәр, фигыль һәм аның наклонениеләре, төшем юнәлеше, күчемле һәм күчемсез фигыльләр, «кальб фигыльләре», «төзек түгел фигыльләр, «якынлату фигыльләре», «мактау һәм хурлау фигыльләре», «гаҗәпләнү фигыльләре», кисәкчәләр өйрәнелә.

Ләкин ике әсәрнең аңлатмаларының күләмнәренә карасак, Габдрахман әл-Җаминың (1414–1492) «әл-Кафия»гә төзелгән шәрхе Мөхәммәт әл-Әрдәбилинең (1572–1627) «әл-Әнмүзәҗ»гә язган шәрехенә караганда күләм ягыннан күпкә зуррак (Казанда 1902 елда «Бертуган Кәримовлар» матбагасында басылган «әл-Әнмүзәҗ»нең аңлатмасы белән күләме 97 бит булса, Казанда 1884 елда «Император» матбагасында басылган «әл-Кафия»нең аңлатмасы белән күләме 403 бит). Димәк, әл-Җами хезмәтен әл-Әрдәбили хезмәтеннән соң өйрәнү максатка ярашлырак була, һәм ул китап гарәп грамматикасы буенча белемнәрне тагын да тирәнәйтергә һәм камилләштерергә мөмкинлек бирә торган әсбаб дип әйтергә мөмкин.

Габделкаһир әл-Җөрҗани (1078 дә вафат) гарәп теленең стилистикасына аерым фән буларак нигез салучы дип санала. Киң танылган «Әсрарел-бәляга» (Матур сөйләм серләре) әсәреннән тыш, бу күре-

некле галим гарәп теле грамматикасына кагылышлы башка хезмәтләр дә язган [9: 13–16].

Әл-Җөрҗанинең «әл-Гавамил әл-миәт» трактаты исемнең теге яки бу килештә, фигыльнең нинди дә булса наклонениедә торуын таләп итә торган грамматик факторларны (җөмләдәге функцияләре, предлогларга, кисәкчәләргә иярүләре һ.б.) өйрәнүгә багышланган [1: 28–47].

Татар мәдрәсәләрендә гарәп теленең морфологиясен өйрәнү өчен уку әсбабы буларак фарсы телендә язылган «Мөкаддимә-и Бедон» («Бел» рисаләсенә кереш), «Шәрхе Габдулла» (Габдулла аңлатмасы) һәм гарәп телендәге «Сарф Мөгыйззи» (Мөгыйззи морфологиясе) китаплары да киң кулланылган.

«Мөкаддимә-и Бедон» гарәп теле морфологиясенең кыска курсыннан гыйбарәт һәм гарәп теленең грамматикасын башлап өйрәнүчеләргә юнәлтелгән [8: 2–18]. Р. Фәхреддин әлеге әсбапның авторы Казан өязе Оры авылының имамы Юныс бине Иванай (1636 да туган) булу ихтималын әйтеп китә [10: 41]. Хезмәтнең исеме фарсы телендәге «бел» (бедон) сүзеннән алынган.

Габдулла бине Ак-Мөхәммәт тарафыннан төзелгән «Шәрхе Габдулла» хезмәте «Сарф Мөгыйззи» китабының бер бүлекчәсенә аңлатмадан гыйбарәт. Шәрехнең беренче һәм иң зур өлешендә составларында өстәмә хәрефләр булмаган өч хәрефле фигыльләрнең төрләре өйрәнелә. Икенче бүлектә составларында өстәмә хәрефләр булган өч хәрефле фигыльләрнең төрләре карала; аларның семантик үзенчәлекләре аңлатыла; исем фигыльдән (масдар) деривативлар ясалу кагыйдәләре китерелә. Өченче бүлек составында өстәмә хәрефләр булмаган дүрт хәрефле фигыльне, соңгы бүлек составларында өстәмә хәрефләр булган дүрт хәрефле фигыльләрне өйрәнүгә багышланган [8: 19–100].

Морфология фәненә кереш буларак язылган «Сарф Мөгыйззи»дә (авторы мәгълүм түгел) фигыль парадигмасында булган үзгәрешләр аңлатыла: фигыль баблары, төшем юнәлеше, боеру наклонениесе формалары ясалуы, зат-сан белән төрләнеш [8: 101–112].

Югарыда язылганнарга нәтиҗә ясап әйтсәк, татар мәдрәсәләрендә морфология һәм синстаксис буенча материалны үз эченә алган гомуми характердагы һәм аларның берсенә генә багышланган уку әсбаплары кулланылган. Беренчеләрен әз-Зәмәхшәри һәм Ибне Хаҗиб хезмәтләре тәшкил итә. Уку әсбапларының икенче төркеме исә гарәп теле синтаксисына багышланган әл-Җөрҗани трактаты һәм гарәп теле морфологиясенә караган «Мөкаддимә-и Бедон», «Шәрхе Габдулла», «Сарф Мөгыйззи» китапларыннан гыйбарәт.

Әлеге трактатлар һәм аларның аңлатмаларының башлыча гарәп телендә язылган булуы аларны татар укучыларына укып аңлау өчен артык кыен иткән. Материал аңлашылсын өчен, мөгаллимнәр, гарәп теленнән сабак биргәндә, укучыларга туган телдә дә өстәмә аңлатма бирергә мәҗбүр булып, гарәп телен мөстәкыйль фән буларак өйрәнүгә мөмкинлек калмаган. Моннан тыш, бу хезмәтләрне дәреслек дип атавы да шактый кыен, чөнки, күп еллар элек төзелгән булып,

инде яңадан татар теленә тәрҗемә итеп эшләнүне таләп иткәннәр. Шул ук вакытта әйтеп үтелгән зур галимнәр төзегән хезмәтләр, тирән эчтәлекле грамматик материал чыганагы буларак, гарәп теле буенча белешмә һәм өстәмә белем бирү әсбабы буларак бик нәтиҗәле кулланыла алу, әлбәттә, шик тудырмый.

Билгеле, гарәп теле буенча дәреслекләр белән бәйле әлеге вазгыять алдынгы карашлы мөгаллимнәрне һәм гомумән татар зыялыларын канәгатьләндерә алмаган. XIX гасырның ахыры – XX гасыр башында, Европада кузгалган уку-укыту системасын реформацияләү дулкынында, мәдрәсәләрнең башлангыч сыйныфлары өчен татар телендә заманча гарәп теле грамматикаларын әзерләү һәм бастыру өлкәсендә зур активлык күзәтелә. Моңа шулай ук татарларның башка төрки халыклар арасында аерым этнос буларак формалашуы да уңай йогынты ясый. Шушы чорда дөнья күргән җәдиди уку әсбаблары арасында Галимҗан һәм Салихҗан Баруди, Әхмәдһади Максуди, Габдрахман Гомәри, Сөнгатулла Бикбулат һ. б. төзегән хезмәтләрне санап китәргә кирәк.

**Әдәбият**

1. *Әл-Җурҗәни Г.* Әл-Гәвамил // Кавагыйдел-игъраб вәл-гәвамил мәга шурухихима. Казань: Тип. Имп. Ун-та, 1890. Б. 28–47.

2. *Әз-Зәмәхшари М.* Әл-Әнмүзәҗ. Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1902. 97 б.

3. *Әз-Зирикли Х.* Әл-Әгълям. Бейрут: Дарел-гыйлем лил-мәләйин, 1986. Т. 4. 211 б.

4. *Әз-Зирикли Х.* Әл-Әгълям. Бейрут: Дарел-гыйлем лил-мәләйин, 1986. Т. 7. 178 б.

5. *Галили М.* Кереш // Ибне Хаҗиб Г. Шәрхел-вафия назмел-кафия.Ән-Нәҗәф: Матбәгател-әдәб, 1980. 480 б.

6. *Ибне Хаҗиб Г.* Хәза китабел-кафия. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1889. 27 б.

7. *Кахәля Г.Р.* Мөгъҗәмел-мөъәллифин. Бейрут: Дар Ихьяъә әт-турас әл-гәраби. Т. 6. 265 б.

8. Мөкаддимә-и бедон мәга шәрхе Габдуллаһ вә Мөгыйззи. Казань: Типолитогр. Имп. ун-та, 1894. 112 б.

9. *Рида М.* Кереш // Әл-Җөрҗани Г. Әсрарел-бәляга. Җиддә: Дарел-мәдәни. Б. 13–16.

10. *Фәхреддин Р.* Асар. Казан: Рухият, 2006. Т. 1. Б. 41.

11. *Хаҗи Халифә.* Кәшфез-зөнүн. Дамаск: Дарел-фикр. Т. 1. 180 б.

***Сәлахов Габдулла Мөнир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инситутының Язма мирас өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

***Салахов Абдулла Мунирович,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*abdullasalakhov@yandex.ru*

УДК 821.512.145

***Г.Р. Гайнуллина,***
***Р.Р. Мәннанова***

# ГОБӘЙДУЛЛА НИГЪМӘТУЛЛИН ФӘЙЗИ-БУБИНЫҢ МӘКТӘП-МӘДРӘСӘЛӘР ӨЧЕН ТӨЗЕГӘН ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНӘ КҮЗӘТҮ

Как известно, медресе Иж-Буби к концу XIX – началу XX века, т. е. в период руководства просветителей Губайдуллы, Габдуллы, Мухлисы Буби, стал очагом национального просвещения, обладающим не только авторитетом в масштабах страны, но и во всём тюркско-мусульманском мире. Просветительские идеи братьев Буби – основателей первой национальной дореволюционной школы, готовивших не только религиозных деятелей, но и светских учителей, преподавателей различных дисциплин, – были известны во всей России, где существовали татарские школы, в них преподавали ученики братьев Габдуллы и Губайдуллы Буби. В музее медресе Иж-Буби хранятся и экспонируются книги просветителей Нигматуллиных-Буби, изданных на рубеже XIX–XX веков. Всего их 21. Габдулла Буби – автор богословских сочинений, внесших значительный вклад в формирование татарской религиозно-реформаторской мысли начала XX века, автор переводов; Губайдулла Буби – автор учебников по географии, физике, естествознанию, этике, грамматике татарского языка, которые в 1898–1917 гг. неоднократно переиздавались, даже после Октябрьской революции по ним обучали детей. Крайне важным сегодня является не просто сохранение богатого национального наследия, но также изучение его, популяризация и передача подрастающему поколению, чтобы возобновить преемственность знаний. Осуществлена текстологическая работа, перевод с арабской графики на кириллицу двух учебников и хрестоматии Губайдуллы Нигматуллина-Буби «Кавагыйде төркия» (1898), «Кыйраәте төрки» (1899), «Кыйраәте фәнния (беренче җөзьә)» (1909), рукописи подготовлены для издания. В данной статье основное внимание уделяется содержанию учебников и хрестоматии.

**Ключевые слова:** медресе Иж-Буби, просветитель, педагог, Губайдулла Нигматуллин Файзи-Буби, учебник, хрестоматия, физика, грамматика, чтение.

As you know, by the end of the XIX – beginning of the XX centuries, the Izh Bubi madrasah, that is, during the leadership of the enlighteners Gubaidullah, Gabdulla, Mukhlisa Bubi, became a hotbed of national enlightenment, which has authority not only nationwide, but throughout the Turkic-Muslim world. The enlightenment ideas of the Bubi brothers, the founders of the first national pre–revolutionary school, who trained not only religious figures, but also secular teachers, teachers of various disciplines, were known throughout Russia, where Tatar schools existed, where students of the brothers Gabdulla and Gubaidulla Bubi taught. The museum of the Izh-Bubi madrasah preserves and exhibits books by the enlightenment thinkers Nigmatullin Bubi, published at the turn of the XIX–XX century. There are 21 of them in total. Gabdulla Bubi is the author of theological works that made a significant contribution to the formation of Tatar religious reform thought at the beginning of the twentieth century, the author of translations; Gubaidulla Bubi is the author of textbooks on

geography, physics, natural sciences, ethics, grammar of the Tatar language, which were repeatedly republished in 1898–1917, even after the October Revolution, they were taught to children. It is extremely important today not only to preserve the rich national heritage, but also to study it, popularize it and pass it on to the younger generation in order to resume the continuity of knowledge. Textual work has been carried out – the translation from Arabic graphics into Cyrillic of 2 textbooks and Gubaidulla Nigmatullin's anthology Bubi «Kavagyide turkia» (1898), «Kiyraete turki» (1899), «Kiyraete fanniya (berenche jozə)» (1909) from Arabic graphics to Cyrillic and the manuscripts are prepared for publication. This article focuses on the content of textbooks and anthologies.

**Keywords:** Izh-Bubi madrasah, educator, teacher, Gubaidulla Nigmatullin Faizi-Bubi, textbook, textbook, physics, grammar, reading.

XX гасыр башында «Иж-Буби» мәдрәсәсе Русиядәге мөселман уку йортлары арасында иң абруйлы, иң алдынгы белем учакларының берсе саналган һәм татар мәгърифәте тарихында якты эз калдырган, аны тәмамлаучылар арасында халкыбызның мәгарифен, фәнен, рухи мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән шәхесләр шактый.

Күренекле мәгърифәтче, мөгаллим Гобәйдулла Нигъмәтуллин Фәйзи-Буби (Гобәйдулла Мөхәммәд Фәйзи Нигъмәтуллин) (1866–1938) 1866 елның 20 гыйнварында Вятка губернасы Сарапул өязе Иж-Буби авылында (хәзерге Әгерҗе районы) мулла һәм мөдәррис Габделгалләм Нигъмәтуллин (1834–1903) һәм Бәдрелбанат Нигъмәтуллина (1838–1922) гаиләсендә туа. Ул – Габдулла һәм Мөхлисә Бубиның абыйсы. Гобәйдулла башлангыч урта белемне әтисенең мәдрәсәсендә ала. Шәкертлек елларында ук мөдәррис булып торган атасының ярдәмчесе – хәлфә итеп билгеләнә, шул ук вакытта аңа сәүдә эшләрендә дә булыша. Кечкенәдән үк күп укый. Бигрәк тә Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри әсәрләренең һәм Исмәгыйль Гаспралы чыгарган «Тәрҗеман» газетасының аңа йогынтысы зур була. 1890 елны 24 яшендә, әтисенең ризалыгын алып, Истанбулга укырга китә һәм 1890–1895 елларда Төркиядә иң абруйлы дөньяви уку йортларының берсе саналган «Мәктәбе мулкияи шахане» мәктәбендә укый, табигать фәннәрен үзләштерә. Истанбулда укыганда, Гобәйдулла Бубиның иң якын дуслары Харис Фәйзуллин (Шакирҗан Файзуллинның энесе) һәм язучы Фатих Кәрими була. Гыйлемгә сәләтен күреп, аңа белем алуын Париж университетында дәвам итәргә тәкъдим ясыйлар. Ләкин әтисе Төркиядә биш ел белем алу белән канәгатьләнергә кирәк дип исәпли, һәм Гобәйдулла Буби, туган авылына кайтып, энесе Габдулла белән бергә мәдрәсәне үзгәртеп кору эшенә тотына. Табигать фәннәрен (физика, география), татар телен укыта, программалар һәм дәреслекләр төзи. Алар арасында «Мохтасар җәгърафия», «Җәгърафия-и гомуми», «Кечек география» кебек география дәреслекләре, «Кавагыйде төркия» дип аталган төрки телләр грамматикасы дәреслеге, «Кыйраәте төрки» уку китабы һәм ике өлештән торган «Кыйраәте фәнния» дип исемләнгән табигать белеме яки физика дәреслеге бар.

Габдулла һәм Гобәйдулла Нигъмәтуллин Фәйзи-Бубиларның 1898–1918 еллар аралыгында нәшер ителгән һәм Иж-Буби авылы тарихы, мәктәп музейларында саклананган 13 китабын һәм хезмәтен, мәдрәсәдә кулланышта булган 9 дәреслек һәм уку китабын иске имладан кирилл язуына күчерү эшен башлап җибәреп, бүгенге көндә без Г. Бубиның «Кавагыйде төркия» (1897), «Кыйраәте фәнния» (1909) дәреслекләре һәм «Кыйраәте төрки» (1899) хрестоматиясе өстендә зур текстологик эш башкардык. Әлеге дәреслекләр һәм хрестоматия К. Насыйри хезмәтләреннән башлангыч алган гамәлләрнең дәвамы булып тора. Бу хезмәтләрне иске имладан гамәлдәге графикага күчерү һәм өйрәнү инкыйлабка кадәр эшләп килгән татар мәктәп-мәдрәсәләрендәге уку программаларының эчтәлеген, укыту алымнарын күзәтергә дә ярдәм итә.

«Кавагыйде төркия» дип аталган төрки телләр грамматикасын Г. Буби 1897 елда тәмамлап, шул ук елда дәреслекне бастыруга рөхсәт ала. Хезмәт 1898 елда Казанда Чирков хатыны варислары матбагасында нәшер ителә. Китапның иске имладагы нөсхәсе 24 биттән гыйбарәт.

Г. Буби төзегән «Кавагыйде төркия»нең [2] төп эчтәлеге сүз төркемнәренә, аларга хас грамматик категорияләргә багышланган. Татар теленең бу чорда язылган грамматикаларында сүз төркемнәренә билгеләмә биргәндә, семантик принципка нигезләнәләр, аларның морфологик билгеләренә игътибар җитәрлек түгел, телгә алынганнары да сүз төркемнәреннән аерым карала [5: 25]. К. Насыйри исә 1895 елда гарәп теле грамматикалары үрнәгендә сүз төркемнәрен исем, фигыль, хәреф дип атап аерып чыгара: «Сыйфат, сан, алмашлык кебек хәзерге татар әдәби телендәге мөстәкыйль сүз төркемнәре исемнең төркемчәләре (исме сыйфат, исме гадәд, исме замир), дөресрәге, барысы да исем сүз төркемнәре (именные части речи) итеп карала» [5: 26].

Г. Буби, кәлимә төшенчәсенә аңлатма биреп, сүз төркемнәренең тугыз төргә бүленүен хәбәр итә: *«Кәлимә – ялгыз бер мәгънәгә мәүдуг*[1] *булган ләфзадыр*[2]*. Вә бу кәлимәнең лисан төркидә тугыз кыйсеме*[3] *тәкъсим*[4] *булуы муафикътыр*[5] *ки, алар шулардыр: исем, сыйфат, замир, фигыль, фәргъ фигыль, карыйн фигыль, әдат бәян, әдат гатыйф, хәрф нәдә»* [2: 3].

Бу чорда дәреслекләрдә гарәп теле грамматикасының йогынтысы нык сизелүен дә билгеләп үтәргә кирәк: «1) терминнарның күбесе гарәпчә (кәлимә, сарыф, игъраб, замир һ. б.); 2) сүз төркемнәренең саны бик чикле (3–5); 3) сүз төркемнәре эчендәге бүленеш тә гарәп телендәгечә (исме сыйфат, исме гадәд, исме замир)» [5: 27].

[1] Мәүдуг – сакланылган.

[2] Ләфза – сүз.

[3] Кыйсем – төркем.

[4] Тәкъсим – бүлү, кисәкләргә аеру.

[5] Муафикъ – туры килгән.

Грамматик категорияләрне аңлату өчен Г. Буби күпсанлы гарәп терминнарына мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта автор төрки телләрдә гарәп грамматикасына хас булган кайбер үзенчәлекле категорияләрне, калыпларны аерып күрсәтә. Мәсәлән, гарәп телендә фигыльләр тамырдагы хәреф саны буенча аерып карала (өч хәрефтән торган фигыльләр, дүрт хәрефтән торган фигыльләр). Г. Буби бу күренешкә төрки телләрдән дә мисаллар китерә: *«Бер кәлимәнең җәүһәре*[1] *бер хәреф булса – фуради*[2]*, ике хәреф булса – сүнәи*[3]*, өч хәреф булса – сүләси*[4]*, дүрт хәреф булса – робагый*[5]*, биш хәреф булса – хумәси*[6] *диелер».*

Әмсилә:

*Ю – юмак, ди – димәк кеби (фуради).*

*Үп – үпмәк, ат – атмак (сүнәи).*

*Утыр – утырмак, ачык – ачыкмак (сүләси).*

*Актар – актармак, күндер – күндермәк (робагый).*

*Асмарла – асмарламак (хумәси)»* [2: 11–12].

Г. Буби төзегән әлеге дәреслектә һәр сүз төркеменә хас грамматик категорияләр аңлатыла, аларга мисаллар китерелә, язылышларындагы кайбер үзенчәлекләргә, искәрмәләргә дә игътибар бирелә. Мәсәлән, алмашлыклар турында мондый мәгълүмат бирелә: «*Замир – исемнең җирен тоткан кәлимәдер. Бән (мин), сән (син), у (ул) кеби. Замир ике кыйсем булып, замаир шәхсия вә замаир истәф һәмиядер. Замаир шәхсия бән, сән, у замирлары булып, җәмгъләре – без, сез, анлардыр. Замаир истәфһәмия кем вә нә кәлимәләре булып, кем – зөлгакульдән*[7] *вә нә гайре зөлгакульдән сөаль өчендер: кем килде? нә вар? кеби»* [2: 11].

Дәреслек иске имляда кулланылган тыныш билгеләренә багышланган «Ишарәтләр» дип аталган бүлек белән тәмамлана.

Г. Буби төзегән дәреслекләр арасында табигать фәннәре буенча дәреслекләр аеруча әһәмияткә ия. Мөгаллимнең К. Насыйри хезмәтләрен файдаланып төзегән «Кыйраәте фәнния» яки «Фәнни уку» [4] дәреслеге 1909 елда Казанда «Үрнәк» басмаханәсендә нәшер ителә. Мәгълүм булганча, 1895 елда К. Насыйри, балаларны дөньяви фәннәрнең нигезләре белән таныштыру максатыннан, татар телендә кызыклы, бай материал туплаган, тормыш белән бәйләп бирелгән география, табигать белеме, математика, геометрия, ботаника, физика дәреслекләре төзи [6: 67]

Г. Бубиның башка дәреслекләреннән аермалы буларак, «Кыйраәте фәнния» дәреслеге рәсемнәр белән бизәлгән. Фәнни тәҗрибәләрне

[1] Җәүһәр – нигез.
[2] Фуради – берәм-берәм.
[3] Сүнәи – гарәп грамматикасында ике хәрефтән яисә ике иҗектән торган фигыль.
[4] Сүләси – гарәп грамматикасында өч хәрефтән яисә өч иҗектән торган фигыль.
[5] Робагый – дүрт өлештән торган.
[6] Хумәси – гарәп грамматикасында биш тартыктан торган фигыль.
[7] Зөлгакуль – акылга ия булган.

тасвирлаганда, термометр һәм паровоз кебек предметларны аңлатканда рәсемнәрдән файдалану үзен аклый. Дәреслектә укучыларга гади тел белән атом, газ кебек төшенчәләр, җил, тавыш һ. б. күренешләрнең табигате аңлатыла, кайбер галимнәр һәм аларның ачышлары тасвирлана. Укучыларны кызыксындыру максатыннан, Г. Буби еш кына бүлек башында тема буенча сораулар бирә. Бу шулай ук укучыны әйләнә-тирәне, табигать күренешләрен өйрәнергә, эзләнергә этәрә: *«...Йә әле, тимерчыбыкны, юан бауны яисә каешны тартып өзеп карагыз. Өзә алмассыз. Нигә өзә алмыйсыз? Нигә алардагы җөзьә вә парчаларны бер-береннән аерырга көчегез җитми? Ул җөзьәләр бер-берләренә ни белән ябышканнар? Ул җөзьәләрне бер-беренә кем бәйләгән, кем берләштергән, бер-беренә ни белән тарттырылган? Бу җөзьәләрне бер-береннән аермыйча кем тота?»* [4: 5–6].

Автор, балаларның тормыш тәҗрибәсенә таянып, катлаулы темаларны да бик җиңел аңлата белә. Мәсәлән, аларны атом төшенчәсе белән таныштыру өчен, ул суда буяуның эрүе, чәчәк, хушбуй яки керосин исенең таралуы, хайваннарның исне тоемлавы кебек күренешләргә мөрәҗәгать итә.

Шулай ук Г. Буби үзенең мөгаллимлек тәҗрибәсеннән кызыклы мисаллар китерә. Мәсәлән, ул шәкертләреннән Җирнең тарту көченең нәрсәгә охшавы турында сорап, аларның кайбер җавапларын терки: *«Сабак биргәндә шәкертләрдән: “Бу куәт нинди нәрсәгә охшый?” – дип сораган идем <...> Миңа икенче бер шәкертнең җавабы бик ошады. Ул әйтәдер: “Бу көч күзгә күренми торган ата вә ананың баласына мәхәббәтенә охшый, вә туганнарның бер-берсенә шәфкать вә бер-берен сөюләренә охшый”. Менә бу сөю, мәхәббәт, шәфкать берсе дә күзгә күренми, шулай булса да, ата вә ананы – балаларына, вә балаларны ата вә аналарына тарта»* [4: 6].

Дәреслек укучылар өчен аңлаешлы телдә язылган, мөгаллим фәнни терминнарны башта татарча аңлата, соңыннан гарәпчә яки башка телдә китерә: тарта торган куәт – куввәтә җәзибә, микроскоп – зур күрсәтә торган корал һ. б.

Г. Буби «Кыйраәте фәнния» китабында укучыларын физика, табигать белеме белән генә таныштырып калмый, аларны белем алырга, тәрәккыйлашырга өнди. Мәсәлән, парның үзенчәлеге, паровозлар турында мәгълүмат биргәч, ул бу ачышның мәдәни һәм фәнни үсеш өчен никадәр әһәмиятле булуын әйтә: *«Петербургта, Парижда вә гайре зур шәһәрләрдә чыккан яхшы китап вә газеталарны Русиядә булган зур шәһәрләрдә, хәтта авылларда да, бер һәфтә, ун көн соң алып укырга мөмкин. Петербургта бүген булган бер эш, өч-дүрт көн соң, газеталардан безгә мәгълүм була»* [4: 24].

Г. Бубиның «Кыйраәте фәнния» дәреслеге укытучылар, мәктәп балалары, милли мәгарифкә битараф булмаган киң катлау укучылар өчен кызыклы хезмәт булып тора.

Мөгаллимнең гарәп имласында язылган 85 биттән торган «Кыйраәте төрки» [3] дип исемләнгән уку китабы да 1899 елда Казанда

Чирков хатыны варисларының матбагасында нәшер ителә. Билгеле булганча, XIX йөз урталарында татар әдәбияты буенча беренче уку китаплары төзелә: «Оренбургның Неплюев кадет корпусы укытучысы М. Иванов 1842 елда «Татарская грамматика» исемле уку китабы чыгара. Шул ук уку йорты укытучысы С. Кукляшев 41 татар халык иҗаты үрнәкләре (мәкальләр, әйтемнәр, бәетләр, җырлар, тапкыр сүзләр) һәм Урта гасырлар кулъязма китапларыннан, тарихи хезмәтләрдән өзекләр туплаган татар әдәбияты хрестоматиясе һәм аңа сүзлек төзи» [6: 67]. Р.Н. Вәлиуллин фикеренчә, ул чорда үгет-нәсыйхәт рухындагы китапларның зур күпчелеге Ризаэддин Фәхреддин тарафыннан төзелә [1: 21].

Г. Бубиның уку китабы гади һәм бүгенге көн укучысына да аңлаешлы татар телендә язылган. Эчтәлеге балалар бакчасы яшендәге һәм башлангыч сыйныф укучылары өчен файдалы нәсыйхәтләр, тормыш-көнкүреш һәм хайваннар дөньясы турында кызыклы мәгълүматлар, тәрбияви хикәяләр һәм мәсәлләрдән гыйбарәт.

Китаптагы беренче хикәясе «Аллаһ» дип исемләнгән. Мәгърифәтченең теләге – Аллаһ турында мәгълүматны балаларга аңлаешлы итеп җиткерү: *«Балалар! Сезнең анагыздан тагын да шәфкатьлерәк вә тагын да яхшырак бер Зат бардыр. Бу яхшы ананы сезгә ул Зат биргәндер. Дөньяны, кояшны, айны ул Зат яраткандыр. Ул Зат та – Аллаһы Тәгаләдер. Аллаһы Тәгалә бердер. Бар нәрсәне дә күрер, ишетер, сизәр, яхшы эшләребезне дә, явыз эшләребезне дә белер. Яхшы эш эшләгән кешеләрне сөяр, яман эш кылган кешеләрне сөймәс. Тырышыйк! Яхшылык кылып, Аллаһы Тәгаләнең сөйгән колы булыйк»* [3: 2]. Дини эчтәлекле хикәяләр берничә: «Аллаһ», «Дога», «Пәйгамбәр», «Мәчет». Китаптагы калган әсәрләрне тормыш-көнкүрешкә багышланган кыска хикәяләргә, хайваннар турындагы белешмә һәм мәсәлләргә, тәрбияви эчтәлекле сюжетлы хикәяләргә бүлеп карарга мөмкин. Мәсәлән, Г. Буби он, зәйтүн мае, ефәк тукыма һ. б. җитештерү, кәгазь ясау серләрен төшендерә, кайбер һөнәрләр турында яза. «Игенче» хикәясендә мондый өзек бар: *«Сукачы басуларда сука сукалап ашлык чәчәр. Ашлыкларны үсеп җитеп эч кергәч, урып алыр. Шушы эшкә "игенчелек" дип әйтәләр. Игенчеләр үзләренең бала-чагалары өчен тырышалар. Тырышкан кешеләр никадәр яхшы адәмнәрдер! Игенчеләр булмаса, ашый торган икмәк вә күмәчләрне кайдан табар идек?»* [3: 6].

«Кәгазь» хикәясен дә мисалга китерергә мөмкин: *«Китапларыгыздагы вә яза торган кәгазьләрне ни нәрсәдән ясыйлар, беләсезме? Иске чүпрәкләрдән, саламнан, төрле-төрле кипкән үләннәрдән, пычкы чүпләреннән ясаладыр. Әмма бездәге кәгазьләрнең күбрәге иске киндер чүпрәктән ясалгандыр. Кәгазь ясаучылар иң элек бу чүпрәкләрне, бик зур казанга салып, камыр булганчы кайнатырлар. Аннан соң бик нык тазартып вә дарулап агартырлар. Соңыннан уклау кебек нәрсә белән бик юка итеп җәярләр. Соңыннан киптереп, базарга чыгарып сатырлар. Иске заман кешеләре кәгазь ясый белмәгәннәр. Алар*

*агач кабыкларына, зур яфраклы печәннәрнең яфракларына, тактага, ташка, тирегә вә моның кебек нәрсәләргә язып укыганнар»* [3: 40].

Укучыларга әхлакый тәрбия бирү максатыннан Г. Буби чәчмә мәсәл жанрына мөрәҗәгать итә. Башта балаларга төрле хайваннар һәм үсемлекләр турында кыска гына хикәяләр, мәгълүмат бирелә. Геройларны тасвирлаганнан соң, тәрбияви эчтәлекле мәсәл китерелә. Һәр мәсәлнең ахырында автор «хисса» дип атаган кыска нәтиҗә (мораль, нәсыйхәт) ясый.

Төлке, арыслан кебек хайваннар мәсәлләрдә еш искә алына. Шундый әсәрләрнең берсе «Арыслан вә төлке» дип атала: *«Бер арыслан, кояш эсселегеннән сакланып, бер тау тишегенә кереп ятты. Моның артыннан бер зур кигәвен кереп, башы янында безләп йөрде. Арыслан бу хайванның тешләп безләвенә эче пошып, әле бер ягына, әле бер ягына әйләнеп ятадыр иде. Бик ачуы килгәнгә күрә, бөтен тәне белән калтырый иде. Бер төлке арысланның бу хәлен күреп көлгәнгә күрә, арыслан төлкегә шул сүзләрне сөйләде:*

*– Минем бу кадәр калтырап эчем пошуы кигәвеннән курыкканга күрә түгелдер, бәлки кечкенә генә башы белән мине хур иткәне өчендер.*

*Хисса*

*Гакыллы кешегә хур булу үлүдән дә яманрактыр. Шушының өчен хур була торган эшләрне кылудан бик сакланырга кирәк»* [3: 73–74].

Китаптагы сюжетлы хикәяләрнең төп герое булып, нигездә, кечкенә малай тора. Ул төрле тормыш ситуацияләренә эләгеп (бик фәкыйрь яки карт кешене очрата, бер кешенең акчасы төшеп калганын күрә һ. б.), әнисеннән нәсыйхәт ала яки, үзе дөрес гамәл кылган очракта, автор укучының игътибарын аның күркәм әхлагына юнәлтә. Шунысын әйтергә кирәк: текстларның кем тарафыннан язылганлыгы күрәтелми.

Гобәйдулла Бубиның «Кыйраәте төрки»се бүгенге көндә дә тәрбияви әһәмиятен, әдәби кыйммәтен югалтмаган һәм кечкенә балалар өчен кызыклы китап була ала.

Иҗтимагый барышның, милли-әхлакый яңарышның хәзерге дәверендә күренекле мәгърифәтчеләрнең карашларын милли мохиттә таныту, тарату өчен шартлар тудырырга кирәк. Татар мәгарифе, мәдәнияте тарихында җуелмас эз калдырган зыялылар буынын тәрбияләгән «Иж-Буби» мәдрәсәсе һәм аның мәшһүр җитәкчеләренең эшчәнлеген тирәнтен өйрәнү эше дә дәвамлы булсын иде.

## Әдәбият

1. *Валиуллин Р.Н.* Татарские учебники по гуманитарным дисциплинам (конец XIX – начало XX века): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2001. 28 с.

2. *Нигъмәтуллин Фәйзи-Буби Г.* Кавагыйде төркия. Казан: Чирков хатыны варисларының матбагасы, 1898. 24 б.

3. *Нигъмәтуллин Фәйзи-Буби Г.* Кыйраәте төрки. Казан: Чирков хатыны варисларының матбагасы, 1899 ел. 85 б.

4. *Нигъмәтуллин Фәйзи-Буби Г.* Кыйраәте фәнния. Казан: Үрнәк, 1909 ел. 43 б.

5. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

6. Татар педагогик фикере тарихы. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. 308 б.

*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья написана при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024*

***Гайнуллина Гөлфия Расил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты*

***Мәннанова Рәмзилә Рәмзит кызы,***
*«Хозур» нәшрият йорты редакторы*

***Гайнуллина Гульфия Расиловна,***
*кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета*
*gulfiarasilevna@mail.ru*

***Маннанова Рамзиля Рамзитовна,***
*редактор издательского дома «Хузур»*

УДК 75.04

*О.Л. Улемнова*

# РӘССАМ Р.Г. ЗАҺИДУЛЛИН ИҖАТЫНДА ТАТАР ХАЛКЫ ТАРИХЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ

Статья посвящена заслуженному деятелю искусств Республики Татарстан, художнику-живописцу Р.Г. Загидуллину. Автор раскрывает биографию художника, особенности его творческой индивидуальности, жанровые и стилевые предпочтения, истоки его художественного языка. Художник органично соединяет академические методы изображения с приемами импрессионистической и постимпрессионистической живописи. Это позволяет ему создавать условное пространство картины, в котором историческая и бытовая достоверность соединяется с идеалистическим взглядом на события и людей. Автор подчеркивает приверженность художника основной теме – многовековой истории и культуре татарского народа, которую он раскрывает в картинах исторического и бытового жанров, посвященных разным историческим этапам. В живописных сериях «В стране болгар», «Казанское ханство» нашли отражение древние формы государственного устройства татарского народа и его предков, традиционные занятия мирного времени (пахота, охота, торговля и пр.), разные социальные и возрастные слои татарского общества прошлых веков. В серии «Наша деревня» художник представляет традиции и обычаи татарского народа, которые прошли сквозь века и сохраняются в сельском укладе татар на современном этапе. Р.Г. Загидуллин передает прошлое не столько через исторические события и исторические лица, сколько через типические персонажи, воссоздавая дух исторического времени. При создании исторических полотен художник опирается на исследования татарских ученых – историков и археологов. Его картины настолько полно, достоверно и разносторонне раскрывают жизнь татарского народа, что их широко используют для иллюстрирования трудов по истории и учебников по татарскому языку и литературе.

**Ключевые слова:** живопись, исторический и бытовой жанры, история и культура татар.

The article is dedicated to the Honored Artist of the Republic of Tatarstan, the painter R.G. Zagidullin. The author reveals the biography of the artist, the features of his creative personality, genre and style preferences, the origins of his artistic language. The artist organically combines academic methods of image with impressionistic and post-impressionistic art. This allows him to create a conditional space of the picture in which historical and everyday authenticity are combined with an idealistic view of events and people. The main theme of the artist is the centuries – old history and culture of the Tatar people. He reveals this theme in paintings of historical and everyday genres dedicated to different historical stages. The painting series "In the Land of the Bulgarians" and "Kazan Khanate" reflect the ancient forms of government of the Tatar people and their ancestors, traditional peacetime occupations (plowing, hunting, trading, etc.), and various social and age strata of Tatar society in the past centuries. In the series "Our Village", the artist presents the traditions and customs of the Tatar people, which have passed through the centuries and are preserved in the rural life of the Tatars at the present stage. R.G. Zagidullin reconstructs historical

events and everyday life in his paintings, embodies typical characters, and recreates the spirit of historical time. In the process of creating historical paintings, the artist relies on the research of Tatar historians and archaeologists. His paintings reveal the life of the Tatar people so fully, reliably and comprehensively that they are widely used to illustrate works on history and textbooks on the Tatar language and literature.

**Keywords:** painting, historical and everyday genres, history and culture of the Tatars.

Равил Заһидуллин – бүгенге көндә Татарстанда эйдәп баручы рәссамнарның берсе. Ул 35 елдан артык актив иҗат итеп, югары һөнәри үрләр яулаган һәм зур темага – татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә тугрылык саклаган рәссам-график. Останың туган халкына багышланган күпьеллык иҗаты югары бәяләнеп, агымдагы елда Р. Заһидуллин «Болгар илендә», «Казан дәүләте», «Безнең авыл» дип исемләнеп, өч сериягә кергән картиналары өчен (бу әсәрләрне 2000–2010 елларда иҗат ителгән полотнолар берләштерә) Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе номинанты булды.

Равил Габделбәшир улы Заһидуллин 1960 елның 28 октябрендә Казанда туа. Кечкенәдән үк ул рәсем ясарга ярата, әлеге мавыгуы 1978 елда аны Казан сәнгать училищесына алып килә. 1984 елда ул училищеның педагогика (тасвирый сәнгать) бүлеген тәмамлый һәм үзенең педагоглары Б.И. Майоров, Т.М. Юдина традицияләрен дәвам итеп, берничә ел дәвамында республиканың төрле уку йортларында – Мамадыш балалар музыка мәктәбендә (1984–1985), Казан шәһәренең Идел буе районы пионерлар һәм мәктәп укучылары йортында (1985–1987), Казан шәһәренең 4 нче балалар сәнгать мәктәбендә (1987–1990) рәсем дәресләрен алып бара.

Параллель рәвештә Р.Г. Заһидуллин иҗат эше белән дә шөгыльләнә һәм 1982 елдан башлап төрле дәрәҗәдәге республика, зона, бөтенроссия, бөтенсоюз, ә 1990 еллар башыннан халыкара һәм чит илләрдә узган күргәзмәләрдә катнаша башлый. 1990 елда Р.Г. Заһидуллинны, Б.И. Урманче һәм Б.И. Майоров тәкъдиме буенча, Россия Рәссамнар берлегенә (хәзер Татарстан Рәссамнар берлеге – «Россия рәссамнары берлеге» Бөтенроссия иҗат иҗтимагый оешмасының төбәк бүлеге) кабул итәләр. 1990 елдан башлап ябылганчы (1998) Р.Г. Заһидуллин РСФСР Сәнгать фондының Татар иҗат-җитештерү комбинатында рәссам буларак хезмәт куя. 2012 елда Р.Г. Заһидуллин тагын бер сәнгать берләшмәсенә – Россия рәссамнары иҗат берлегенә («Россия рәссамнарының иҗат берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлегенә) керә. Рәссамның күпьеллык иҗаты югары бүләкләргә лаек була: 2014 елда аңа Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге, 2016 елда Россия Сәнгать академиясе һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Н.И. Фешин исемендәге премияләре тапшырыла. 2014 елда Р.Г. Заһидуллинга Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелә.

Мөстәкыйль иҗат юлына чыгуга ук Р.Г. Заһидуллин үз сәнгать методын һәм темасын сайлый. Аның бөтен иҗаты аша, кызыл җеп булып, тарихи һәм көнкүреш жанрларындагы картиналары сузылып бара. Киң катлау тамашачыларның һәм профессионалларның (рәссамнар, сәнгать белгечләре, журналистлар) аның иҗаты белән даими кызыксынуы, аның талантын тануы, республика һәм федераль дәрәҗәдәге бүләкләр тапшырылу рәссам сайлаган юлның дөрес булуы турында сөйли.

1986 елда Казанда Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган республика сәнгать күргәзмәсендә катнашу Р.Г. Заһидуллинга аеруча зур уңыш китерә. Күргәзмәдә «Кырлай турында истәлекләр» сериясе куела. Миниатюра форматына тартым кечкенә картиналарда традицион яшәешне саклаган татар авылының табигате һәм тормышы сурәтләнә. Серия теманың үзенчәлекле чишелеше, эчкерсезлеге, үзгә сәнгатьчә манерасы белән тамашачыларның да, сәнгать белгечләренең дә игътибарын шунда ук җәлеп итә. Д.К. Вәлиева соңрак бу серия турында болай дип искә ала: «... это не были миниатюры в их традиционно-восточном понимании. Картины были очень невелики, но написаны с такой любовной тщательностью, душевным теплом, увлечением, подробностью письма, что хотелось их долго рассматривать, изучать. В них были та свежесть и то очарование, что возникает от встречи с чем-то истинным и самобытным. В них я услышала национальную мелодию, древнюю мелодию моего народа» [1: 29]. Р.Г. Заһидуллин иҗатының башлангыч чорында булган сәнгатьчә манера озак еллар дәвамында үзгәрешсез кала, бу рәссам натурасының ныклыгы, аның үзе сайлаган юлның дөреслегенә ихлас ышануын дәлилли. Р.Г. Заһидуллин картиналары реалистик һәм бер үк вакытта шартлы да – ул академик сурәтләү алымнарын (туры һәм һава перспективалары, фигураларны һәм йөзләрне күләмле итеп модельләштерү, классик композицион төзелеш) импрессионистик һәм постимпрессионистик рәсем сәнгате алымнары (аерым буяу төшерү, чиста төсләр) белән органик рәвештә бергә куша, бу аңа картинада шартлы киңлек булдырырга мөмкинлек бирә. Ә анда инде тарихи һәм тормыш дөреслеге вакыйгаларга һәм кешеләргә идеалистик караш белән тоташа. Р.Г. Шаһиева үзенә генә хас образлы тел белән Р.Г. Заһидуллин турында болай дип яза: «прародитель стиля подлинного национального импрессионизма, адекватного татарскому мелизму – «монг» (моң) – близким по звучанию звукам флейты, гобоя и древнего фольклорного певца» [2: 11].

Рәссам чынбарлыкны бизәп тасвирламый, ә туган халкының иң яхшы эчке һәм рухи сыйфатларын, татар авыллары һәм шәһәр тормышында озын-озак тарихи үсеш юлында барлыкка килгән милли эстетик кыйммәтләрне, гасырлар дәвамында тупланган тәҗрибәне чагылдырган традицион яшәү рәвешен гәүдәләндерә. Рәссам иҗатына хас әлеге сыйфатны Р.Г. Шаһиева да билгеләп үтә. Аның сүзләренә караганда, Р.Г. Заһидуллин полотноларында идеаль гүзәллек, игелек,

тынлык һәм гармония дөньясы – бөтен кешелек фәлсәфәсендә гениаль утопияләрнең берсе сурәтләнә [2: 10].

1980 елларда яшь рәссамнар арасында Р.Г. Заһидуллин милли темага һәм аны традиционлык рухында аңлатуга тугрылыгы, гасырлар дәвамында төзелеш сәнгате, агач архитектурасы, декоратив-гамәли сәнгать формаларында (ә аларга бизәклелек һәм полихромия хас) үсеш алган татар сәнгатьле мәдәниятенә күмелеп иҗат итүе белән аерылып тора. Татар сәнгатенә хас бу сыйфатлар академик белемгә, Европа сынлы сәнгате традицияләренә таяна һәм Р.Г. Заһидуллинның шәхси сәнгать телен барлыкка китерә. Д.К. Вәлиева билгеләп үткәнчә, рәссам эшләренең миниатюра форматында булуы, аның детальләргә игътибары нәкъ менә татар халкының традицион сәнгатенә хас үзенчәлекләр, күләме белән «кечкенә» әйберләр (чигүле яулыклар, сөлгеләр, шәмаилләр һ. б.) белән бәйле. Алар тамашачы күзен кечкенә формаларны, композицияләрне күзәтергә, бизәкләрне җентекләп карарга өйрәтә. Д.К. Вәлиева сүзләренә караганда, бу Р.Г. Заһидуллинның татар халкының психологиясен, сәнгатькә мөнәсәбәтен дә тирән тоемлавын чагылдыра [1: 29].

2000 елларда Р.Г. Заһидуллин, үзенең үзенчәлекле шәхси стилен саклап, полотноларының форматын зурайта. Бу аның татар халкының эпик тарихына, масштаблы тарихи вакыйгаларга мөрәҗәгать итүе белән дә бәйле.

Татарстан сәнгатендә Р.Г. Заһидуллин тарихи һәм көнкүреш жанрларын берләштергән жанрны тудырды, дип әйтә алабыз. Рәссам халыкның тормыш-көнкүрешен, яшәү рәвешен һәм милли архитектураны реконструкцияләүне, халыкның традицион шөгыльләрен һәм гадәтләрен синтезлый, үткәндәге дәреслекне тарихи вакыйгалар һәм тарихи шәхесләр аша гына түгел, ә заман рухын яңартып, типик персонажлар аша да җиткерә.

Үз картиналарында рәссам төрле чор татар тарихы һәм көндәлек тормыш белән бәйле вакыйгаларның аерым эпизодларын сурәтли. Көнкүреш жанрына караган картиналарында ул йолаларны һәм гореф-гадәтләрне игътибар үзәгенә ала. Рәссамның күпсанлы картиналары татар халкының тормышын шулкадәр тулы һәм киң итеп ачалар ки, аларны хәтта татар тормышы энциклопедиясе дип атарга мөмкин. Тарих белән бәйле хезмәтләрне, татар теле һәм әдәбияты буенча дәреслекләрне бизәгәндә, Р.Г. Заһидуллин картиналарын еш кулланалар. Мәсәлән, С. Шәмси һәм И. Измайлов авторлыгында язылган «Волжская Болгария в рассказах для детей» («Мәгариф», 1995) [3], 2000 елларда Татарстан китап нәшриятында «Татар тарихы» сериясендә чыккан китаплар өчен акварель композицияләрен генә алыйк.

Рәссам үткәндәге вакыйгаларны сәнгатьчә аңлатып кына калмый, ә үз картиналарының эчтәлегенә фәнни нигезләнгән позицияләрдән якын килә, татар галимнәре – тарихчы һәм археологлар А.Х. Халиков, Р.Г. Фәхретдинов, И.Л. Измайлов, Ф.Ш. Хуҗин һ. б. ның хезмәтләрен

китап читенә карандаш белән билгеләр куя-куя җентекләп өйрәнә, аерым өзекләрне күчереп ала һәм картиналарын язганда шуларга таянып эш итә. Аның эшләренә ихтыяҗ зур булу шуның белән дә аңлатыла.

Р.Г. Заһидуллинның озак еллар дәвамында язылган картиналарын өч сериягә берләштерергә мөмкин. Аларда тыныч тормыш һәм сугыш хәрәкәтләре, төрле ел фасылларында шәһәр һәм авыллар, гади крестьяннардан алып бәкләргә һәм ханнарга кадәр төрле социаль катлаулар, төрле буын вәкилләре – балалар, яшүсмерләр, өлкәннәр һәм картларның үзара мөнәсәбәтләре гәүдәләндерелеп, халкыбыз тормышының өч чоры ачыла.

«Болгар илендә» сериясе иң борынгы тарих сәхифәләренең берсенә багышланган. Рәссам картиналарында борынгы Биләр һәм Болгар шәһәрләрен яңадан торгызганда, урам һәм мәйданнарны милли костюмнар кигән һәм көндәлек эш-мәшәкатькә чумган ир-ат, хатын-кыз һәм балалар фигуралары белән җанландыра. «Иртә белән Болгарда» (2022) картинасында ул борынгы сугышчыларны һәм галимнәрне чагыштыра, Җамигъ мәчет күренеп торган шәһәр урамында хәрби киемдәге ир-атның мәдрәсәгә ашыккан шәкерт белән очрашуын сурәтли. «Иртә белән Биләрдә» (2016) картинасында ул тамашачыга шәһәрнең базар мәйданындагы кышкы иртәне тасвирлый, анда сәүдәгәрләр үз кибетләренә товар ташый, халык базарга агыла. «Болгар бикәсе» (2019) картинасында XII гасыр Болгар шәһәрләренең берсендә бәк йорты ишегалды сурәтләнә, анда мех тун һәм баш киеме кигән зифа буйлы ханым балаларның кышкы уеннарын күзәтә.

Болгарларның традицион шөгыльләрен – җир сөрү, ауга чыгуны сурәтләү рәссамга туган як табигатенең матурлыгын күрсәтергә мөмкинлек бирә. «Сабан» картинасы (2015) X гасырда болгарларның дәүләтнең көньяк районнарына язгы кыр эшләренә чыгуын тасвирлый. «Ау» (2022) картинасында болгарлар Иделнең күпсанлы култыкларында үрдәк аулыйлар, шул ук вакытта бу X гасырда яшь сугышчыларны сугыш һөнәренә өйрәтү кебек тә аңлашыла. Халыкның терлекчелек белән шөгыльләнү ысулларында сакланган күчмә тормыш мирасы «Күченү» (2014) картинасында чагылдырылган. «Кар диңгезенә таба» (2019) картинасы XII гасыр вакыйгаларын чагылдыра: монда Идел буе болгарлары мех белән сату иткән Төньяк халыкларына сәүдә экспедициясенә хәзерлек бара.

Тарихның фаҗигалы сәхифәләре сугыш темасына багышланган картиналарда ачыла, рәссам каһарман болгарларның, шәһәрне саклаучыларның сынмас рухын гәүдәләндерә. «Болгар алыплары»нда (2019) XII гасырда дошман гаскәрләре якынлашканда Болгар сугышчыларының ныгытмалар периметры буенча ничек оборона тотуы күрсәтелә. «Биләрне саклау» (2014) картинасы 1236 елның көзендәге вакыйгаларга – Идел Болгарының башкаласы Биләрне Субәдәй җитәкчелегендәге монгол яуларыннан саклауга багышлана.

«Казан дәүләте» сериясендә Р.Г. Заһидуллин Казан ханнарының тантаналы церемонияларын, җәен һәм кышын шәһәрдәге сәүдә тормышына хас үзенчәлекләрне ачып, аның мәһабәт архитектурасын, хакимнәр һәм сугышчылар, һөнәрчеләр һәм гади халык костюмнарын реконструкцияләп, ханлык башкаласының тыныч тормышы сәхифәләрен яңарта. «Хан күтәрү» (2007) картинасында борынгы төрки йола чагылыш таба: Казан ханлыгындагы дүрт аксөяк ыруы вәкилләре хан титулына дәгъва кылучыны алтын киездә югары күтәрәләр. Бу – хан итеп сайлауны символлаштыра. Вакыйга мәчеттә бара: хөтбә укыла, анда катнашучылар вак тәңкәләр ыргыталар һәм яңа сайланган хакимне сәламлиләр.

«Казан. Капка янында» (2021) картинасында ханның ат өстендә, үзенең яраннары белән бергә, ныгытмадан бистәгә чыгуы сурәтләнә. Аны сәламләргә халык төркеме – аксөякләр һәм һөнәрчеләр җыелган. «Казаклар сатулаша» картинасында (2022) казаклар (Казан ханлыгында хәрби-йомышлылар сословиесе) XVI гасыр Казанында сәүдә барган урамнарның берсендә иптәшләре өчен итек сайлыйлар. Болак буендагы бистәнең сәүдә тормышы «Казанда кышкы базар» картинасында урын ала (2015).

«Кол Шәриф шәкертләре белән» (2012) картинасында рәссам Иван Грозный гаскәрләренә каршы Казан өчен соңгы сугышта шәһәрне саклаучыларның фидакярлеген ача: сәет Кол Шәриф җитәкчелегендәге мөгаллимнәр, шәкертләр белән бергә, мәчет түбәсеннән торып, Мәскәү гаскәре белән сугыша. «Сары батыр чирүе» (2010) картинасында, Иван Грозный гаскәрләре Казанны яулап алганнан соң, татар халкының азатлык көрәше башлануы күрсәтелә. Баш күтәрүчеләрнең берсе – Сары батыр – Иделнең уң ярына (тау ягына) күчә һәм 1553 елда басып алучыларга каршы көрәшә.

«Безнең авыл» сериясендә Р.Г. Заһидуллин традицион татар авылын яратып һәм барлык нечкәлекләрен белеп тасвирлый, XIX гасырга формалашып беткән традиция һәм гореф-гадәтләрне чагылдыра: табигый ландшафт, уеп-кисеп декоратив бизәк төшерелгән һәм төрле төсләргә буялган агач корылмалар, дини йолалар, халык бәйрәмнәре, милли костюм, гаилә тормышы, төрле буыннар арасындагы мөнәсәбәтләр. Бу сериягә кергән картиналарда рәссам татар традицияләренең, татар милли характерының асылын тәшкил иткән барлык яхшы якларны бергә туплый, идеаль татар дөньясы образларын күрсәтергә тели, аларны чынбарлыкта торгызырга омтыла.

«Сабантуй. Көрәш» (2014) картинасында XIX гасыр татар авылындагы милли бәйрәм сурәтләнә: мәйдан уртасында көрәшчеләр бил алыша, староста бәйрәмне күзәтә, тәртип саклый. «Тиздән Сабантуй бәйрәме» (2021) картинасында бәйрәмгә әзерлек вакыты тасвирлана: Сабан туе алдыннан авыл старостасы балалар белән бергә авылдагы бөтен йортларны әйләнеп чыга һәм катнашучылар өчен бүләк җыя.

XIX гасыр ахыры татар авылындагы печән вакыты «Зәңгәр күлмәк» (2021) картинасында чагылыш таба. «Авыл мулласы» (2022) картинасы XIX гасыр татар авылы тормышын сурәтли: урам буйлап алтын чапан, ак чалма кигән, култык астына китап кыстырган мулла бара, ә икенче планда балта осталары яңа йорт өчен агач бура җыялар. «Авыл урамы» (2022) картинасы XX гасыр башында авыл мулласының өлкән яшьтәге балта остасы белән сөйләшүен күрсәтә.

Р.Г. Заһидуллин балачак дөньясын аерым бер җылылык һәм ярату белән тасвирлый, буыннарның тыгыз бәйләнешен ассызыклый, өлкәннәрнең балаларны кайгыртып һәм аларга үз тәҗрибәләрен тапшырып, яшь буынны ни рәвешле тәрбияләвен күрсәтә. Бер картинада бабай, оныкларына җылы киемнәр кидереп, төреп, аларны агач чаналарга утыртып, мунчага алып бара («Мунчага», 2022), икенчесендә койма буендагы эскәмиядә утырган бабай йөгереп барган җиреннән туктап калган кечкенә малай белән сөйләшә («Бабай белән малай», 2019). «Кошлар көтүчесе» (2019) картинасы аерым лиризм белән сугарылган, анда тал күләгәсендә курайда уйнаучы малай һәм аның көен ишетеп килгән кошлар сурәтләнә.

Р.Г. Заһидуллин – Татарстанның иң үзенчәлекле тасвирый сәнгать осталарының берсе. Аның югары профессиональ дәрәҗәдә индивидуаль манерада язылган картиналары бай татар тарихының төрле сәхифәләрен гәүдәләндерә, халыкның традицион яшәү рәвешен, аның көнкүрешен һәм дини гореф-гадәтләрен чагылдыра. Р.Г. Заһидуллин үзенең иҗаты белән татар халкының матди һәм рухи мәдәниятен үстерүгә, күпмилләтле республикабыз сәнгатенә үзеннән зур өлеш кертә.

**Әдәбият**

1. *Валеева Д.К.* В миниатюрах – душа народа // Идель. 1991. № 4. С. 29.

2. *Шагеева Р.Г.* Оазисы Атлантиды прошлого // Юный художник. 2020. № 12. С. 9–11 (ил.).

3. *Шамси С., Измайлов И.* Волжская Булгария в рассказах для детей: Учебное пособие для начальных классов по истории и культуре Татарстана. Казань: Магариф; Слово, 1995. 80 с.: ил.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Улемнова Ольга Львовна,***
*кандидат искусствоведения, ведущий научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*oulemnova@mail.ru*

УДК 75

*Р.А. Гулиев*

# БОРЫНГЫ АЗӘРБАЙҖАН СКУЛЬПТУРАСЫНДА ХАТЫН-КЫЗ СИМВОЛИЗМЫ

Данная статья исследует культурное и историческое значение древних женских статуэток, обнаруженных в ходе археологических раскопок на территории Азербайджана. В статье подчёркивается, что форма и символика этих статуэток олицетворяют плодородие, изобилие и женскую энергию. Отмечается роль и значение женщины в древние времена, а также подчеркивается, что находки отражают высокую ценность, придаваемую женщине в культурах того времени. Исследование также освещает место этих статуэток, выражающих женскую энергию, в социальной и религиозной структуре эпохи.

**Ключевые слова:** Азербайджан, женщина, статуэтка, символ.

This article examines the cultural and historical significance of ancient female figurines found during archaeological excavations in Azerbaijan and Tatarstan. The article emphasizes that the shape and symbolism of the figurines represent fertility, abundance, and feminine energy. The role and importance of women in these regions was noted in ancient times, and the findings reflect the value attached to women in these cultures. The study also describes the place of these figurines, which reflect feminine energy, in the social and religious structure of that period.

**Keywords:** Azerbaijan, woman, statuette, symbol.

Бик борынгы чорлардан алып безнең көннәргә кадәр символ – кешелек дөньясының универсаль чагылышы формасы. Мәгънәдә, эчтәлектә һәм төшенчәдә урын алган символ, кешелек җәмгыятенең үсеш процессын белдерү формасы буларак аның роле турында философлар, рәссамнар һәм сәнгать белгечләре төрле фикерләр әйтәләр.

Символ хакыйкатькә ишарә ясый, ләкин беркайчан да аның белән тулысынча тәңгәл килә алмый. Шуңа күрә аңа үзе ишарәләгән мәгънә һәм хакыйкатьнең йогынтысы зур. Кабул ителгән символны үзгәртү яки юкка чыгару бик кыен. Еш кабатлану аны юкка чыгармый, киресенчә, аның тотрыклылыгын гына арттыра. Чөнки символ үзенең барлыкка килүенә җирлек булган мәдәният сыйфатларын да үзләштерә.

Һәр символ үзе барлыкка килгән географик урынга туры килгән тел, мәдәният һәм тарихи тәҗрибә кебек факторлар тәэсирендә формалаша. Бер мәдәниятнең символлары икенчесенеке белән кушылганда, алар үзара охшаш булалар, формаларын үзгәртәләр яки кайбер мәдәни символлар башкаларын ассимиляциялиләр. Моннан тыш, кайбер символлар универсаль характер ала. Мәдәни кыйммәтләрне киләчәк буыннарга үзгәрешсез тапшыруда мәдәни символлар мөһим роль уйныйлар һәм бу очракта саклагыч элементлар булып саналалар.

Азәрбайҗанда яшәгән борынгы төркиләрнең ышануларында җәмгать эшләре белән идарә иткән, низагларны хәл иткән хатын-

кызлар дәвалаучы һәм каһинә буларак танылалар. Алар шулай ук символларга керәләр. Хатын-кызлар уңдырышлылык, дөньяга килү, арадашчылык һәм киеренкелекне бетерү символы сыйфатында аерым мәгънәгә ия була. Төрки мифологиядә хатын-кыз символлары төрле образларда гәүдәләнеш таба: күктән яктылык белән бергә төшкән ана бүре, агач кәүсәсеннән чыккан, ботактан төшкән Дөнья агачы һ. б. [5: 250]. Баланың әнисе фамилиясен алуы кебек элементлар хатын-кызларның матриархаль башлангычын яки характерын һәм борынгы төрки җәмгыятьтәге көчен күрсәтә.

Төркиләрдә аеруча хөрмәт ителгән һәм төрле мәгънәләргә ия ана бүре (Бөрү, Ашина) эпосларда хатын-кыз символы буларак күрсәтелә. Моны болай аңлатып була: төркиләрне яклау, ашату һәм җитәкчелек итү кебек авыр бурычлар үтәгән хатын-кызлар тора-бара символларга әверелгән. Мәсәлән, бүредән килеп чыгу башка эпосларда да чагылыш таба.

Күп кенә башка мәдәниятләрдәге кебек угызларда «ай» символы шулай ук хатын-кызлар белән ассоциацияләнә. «Угыз хан» эпосына игътибар итик: Угызның әнисе – Айхакан, ә аның ике улы Гүнхан һәм Айхан [4: 142].

Азәрбайҗанда борын-борыннан хатын-кызга яшенә карап мөрәҗәгать итү формалары яшәгән: 15 яшькә кадәрге кызларга – «бану», 15–35 яшьлекләргә – «бейим», 35–55 яшьлекләргә – «ханым», 55–75 яшьлек хатын-кызларга – «хатун», ә 75 яшьтән өлкәнрәкләргә «ханым хатун» дип эндәшкәннәр [8]. Әмма хәзерге вакытта күбрәк «ханым» дип мөрәҗәгать итәләр. Бу сүзнең тарихи мәгънәсе «хан», «шаһ» сүзләренә барып тоташа. Ир кеше, хатынының дәрәҗәсен күтәреп, аңа «ХАНым» дип эндәшә.

Кешеләрнең тормышы кайбер шартларга турыдан-туры бәйле булып, алар да символларга йогынты ясаган. Мәсәлән, климат яки туфракның әһәмиятен ассызыкларга теләгәндә, яңгырны – корылыкның, муллыкны ачлыкның капма-каршысы буларак күрсәтүче мотивлар яки игеннең уңмавына юл куймаска тиешле символлар туган. Борынгы җәмгыять кешеләренең уй-хыялларын аңлау өчен, аларга йогынтысы аеруча зур булган нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк. Бу яктан караганда, кыяга төшерелгән рәсемнәр һәм хатын-кызларны символлаштырган скульптуралар беренче сәнгать әсәрләре булып тора. Шуңа күрә хатын-кызлар сәнгатьнең башлангыч чор нигезен тәшкил итәләр дә. Кешелек дөньясының иң борынгы чорларына караган скульптуралар хатын-кыз символлары буларак кабул ителә.

Борынгы пластик сәнгатьнең төрле үрнәкләрен өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1) рельефлы;

2) түгәрәк (күләмле);

3) кабер ташлары.

Игенчелек үсү белән, неолит һәм энеолит чорларында яндырылган балчыктан савыт-саба ясый башлау скульптураның үсешенә

көчле этәргеч бирә һәм аның киң таралуына ярдәм итә. Төрле формалы булулары һәм үлчәмнәре белән аерылып торган балчык эшләнмәләр бу чорның иң мөһим казанышларыннан берсе санала. Әлеге процесслар нәтиҗәсендә скульптур эшләнмәләрнең эчтәлеге дә үзгәрә: алар арасында шәрә хатын-кыз потларның балчыктан ясалган кечкенә сыннары өстенлек итә башлый, алар элек кешеләр яшәгән авылларда табыла. Бу потларның зурлыгы – 15 см га кадәр. Төгәлрәк әйткәндә, мондый эшләнмәләр гадәттә өй эченә куела яки идән астына күмелә.

Шундый скульптураларның төрле урыннарда табылуы кешеләрнең аларның саклау функцияләренә ышануы турында сөйли: алар явыз рухлардан саклый һәм уңдырышлылык, муллык һәм иминлекне тәэмин итә. Азәрбайҗанның борынгы авылларында – Мингячевир, Исмаилла, Габалада – һәм башка төбәкләрдә табылган балчык скульптура эшләнмәләрен мондый ышануларга мисал итеп китерергә мөмкин. Кайвакыт аларны бодай оны яки бөртекләр дә кушып ясаганнар. Болар барысы да әлеге фигураларның биредә яшәүчеләрнең мул тормышын тәэмин итү белән бәйле тылсымлы-йола характерында булуын раслый.

Городец культурасы – Идел буе төбәге һәм Россиянең Дон буе далалары белән бәйле тимер гасыры археологик мәдәнияте ул (б. э. к. VIII–VII гасырлардан б. э. IV–V гасырларына кадәр яшәгән).

Городец авылларында керамика, сөяктән эшләнгән кораллар, таш эшләнмәләр һәм металл әйберләр табылган. Корал кебек металл әйберләр күбесенчә тимердән, ә ювелир әйберләр башлыча бронзадан эшләнгән. Бу культурага караган хатын-кыз сыннары балчыктан ясала һәм уңдырышлылык культын чагылдыра [9].

Моннан тыш, хәзерге Татарстан территориясен үз эченә алган Идел-Урал төбәгенең археологик культурасында таштан, сөяктән, балчыктан һәм бронзадан ясалган ритуаль формалар, сыннар һәм потлар табылган. Алар ир-атларны да, хатын-кызларны да гәүдәләндерәләр һәм борынгы төрки тамгалар булып торалар.

Алар арасында геометрик фигура да бар – тигезьяклы өчпочмак, гади булуына карамастан, сакраль мәгънәгә ия символ, ул дөньядагы күп кенә борынгы халыкларның символлар системасына керә. Кагыйдә буларак, өчпочмак изге тауның, хатын-кыз башлангычының, камилләшкән идеянең, шулай ук Мәхәббәт – Хакыйкать – Зирәклек, Җир – Күк – Кеше, Ата – Ана – Бала, Җан – Рух – Тән, Ата – Угыл – Изге Рух һ. б. кебек өчлекләр гәүдәләнеше буларак кабул ителә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: гомумтөрки мифологик күзаллауларда югарыга юнәлгән өчпочмак, Галәмне саклаучы алиһә Һомай ана символы кебек, графема-тамгалар арасында шулай ук күп очрый [4: 161]. Хәзерге заманда яңа Гвинеядә Койта кабиләсе хатын-кызлары күкрәкләренә V-рәвешле татуировкалар ясыйлар, алар кызның кияүгә чыгу яшенә җитүен символлаштыра [6: 31]. Гомумтөрки фольклорда һәм мифологиядә Иятәр образлары мөһим

урын тота. Мәсәлән, Су анасы яки Урман иясе. Бу образлар хатын-кыз башлангычының табигать көчләре, уңдырышлылык һәм саклау көче белән бәйләнешен күрсәтә, болар борынгы хатын-кыз статуэткаларына нисбәтләнгән саклау һәм уңдырышлылык функцияләре белән бәйләнештә карала.

Ни өчен бу сыннарны кабергә салганнар? Мәгълүм булганча, борынгы төрки халыкларда (бронза дәверендә) абруйлы кеше үлгәч, аны барлык кирәк-яраклары: әйберләре, коллары һәм хәтта үтерелгән атлары белән бергә җирләгәннәр. Әмма соңрак, бу традициянең мәгънәсезлеген аңлап, аны символик рәвештә сурәтләнгән фигуралар белән алыштырганнар. Баштагы ышанулар һәм карашлар тәэсирендә алар дини төс ала, һәм археологик казулар вакытында табылган сыннарны шартлы рәвештә дүрт төп төркемгә бүлеп була:

Беренче төркемгә теге дөньяда бөтен авырлыкларны үлгән кеше белән бергә күтәреп, аңа хезмәт итсен дип, мәрхүмнең каберенә куелган фигуралар керә.

Икенче төркем фигуралары шулай ук анимистик дини карашлар тәэсирендә барлыкка килгән. Кабердә үлгән кешенең рухы әлеге сыннар белән бергә мәңге яшәячәк дип саналган.

Өченче төркемне теге дөньяда үлгәннәрнең күңелен ачу максаты белән ясалган фигуралар тәшкил итә.

Дүртенче төркемгә төрле аллаларны гәүдәләндергән фигуралар, шулай ук авыруларны «үзләренә алган» һәм башка ритуаль вазифалар башкарган сыннар керә.

Бронза һәм тимер гасырларына караган сыннарның үрнәкләрен, нигездә, курганнарда һәм башка күмү корылмаларында очратып була. Бу чорда шулай ук зооморф скульптура киң тарала, бу кабилә һәм ыруларның килеп чыгышы турында тотемик күзаллаулар үсү белән бәйле. Ата-баба гына түгел, кабилә яки ыру сакчылары да булганнар тотемнар. Бронза чорында Идел-Урал төбәгендә тотемик һәм аграр культлар белән бәйле зооморф һәм антропоморф сурәтләр очрап тора. Балчыктан әвәләп ясалган хатын-кыз образлары җирләү һәм авыл тормышы белән бәйле инвентарьларда табыла. Күбрәк схематик характердагы әлеге фигуралар җирнең уңдырышлылыгы һәм нәселне дәвам итү белән бәйле ритуаль максатларга хезмәт иткән, бу Мингячевир һәм Исмаилладагы Азәрбайҗан статуэткалары символизмына тәңгәл килә.

Таш гасырында Алиһә-Ана культы бөтен җирдә таралган була. Археология моны шаккаттыргыч дәлилләр белән раслады. Бүгенге көндә дә Пиренейдан алып Себергә кадәр киңлекләрдә таштан яки сөяктән уеп-кисеп ясалган хатын-кыз фигуралары табыла. Аларның иң борынгысына Австриядә юлыкканнар, һәм ул шартлы рәвештә «Венера» дип исемләнгән. Бу фигураларны бер мөһим сыйфат берләштерә: аларның кул, аяк һәм йөзләре үтә схематик сурәтләнгән. Борынгы заманнар рәссамын барыннан да элек тудыру һәм ашату-имезү белән бәйле органнар кызыксындырган. Хәзерге замандагы кайбер

примитив кабиләләрнең хатын-кызлары кебек, борынгы хатын-кызларның да күкрәкләре чыннан да бик зур һәм корсаклары салынкы булган дигән гипотеза яши. Әмма әгәр дә без «веналар»да реализмга омтылыш кына чагылуын танысак, борынгы хатын-кызларның да йөзләре булмаган, ә куллары бик кечкенә булган дип санарга тиеш... Ахыр килеп, без гадиләштерүнең соңгы дәрәҗәсен күрәбез: күкрәктән генә торган статуэтка – тудыру һәм имезү функцияләренең чиста сурәте, акылга бернинди ишарә юк. Бу – «мәңгелек хатын-кыз гүзәллеге»нең иң борынгы гәүдәләнеше [3: 6]. Чынлыкта исә дөньяга яңа җан иңдерүне, муллыкны, уңдырышлылыкны, тууны гәүдәләндергән бу статуэткалар төгәл йөз чалымнарына, кул һәм аякларга мохтаҗ да түгел.

2015 елда Татар Суыксуы авылы җирлегендә (Татарстан Республикасының Актаныш районы) эзләнү эшләре алып барганда табылган балчык антропоморф фигура фәнни әйләнешкә кертелә [2: 161]. Бу – хатын-кыз фигурасы, һәм ул уңдырышлылык культы белән бәйле булырга мөмкин. Аның орнаментларын анализлау һәм интерпретацияләү Идел-Кама буенда яшәгән борынгы халыкның костюмын реконструкцияләү өчен яңа мәгълүматлар бирергә мөмкин. Табылдык б. э. к. III–IV гасырларга һәм Ананьино мәдәни-тарихи өлкәсе үсешенең соңгы чорына карый. Аны Тауасты Байлар авылы җирлегендә 1958 елда табылган шундый ук фигура белән, шулай ук күрше төбәкләрдәге башка аналогияләре белән чагыштыру мондый балчык эшләнмәләр соңгырак дәверләрдә дә булган дип фаразларга мөмкинлек бирә [2: 161].

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: төрки халыкларның дөньяга карашында хатын-кыз мәрхәмәтле, изге зат буларак кабул ителгән, аңа аерым хөрмәт белән караганнар һәм якларга омтылганнар. Хатын-кыз шулай ук тыйнаклык символы да булып тора. Нәкъ менә шуңа күрә гаилә һәм аны төзү, саклау белән бәйле бөтен нәрсә аның төп миссиясе булып саналган. Хатын-кыз – хезмәт сөючән, ябык холыклы зат, үз-үзен саклап, ул бер үк вакытта гаиләсен һәм киләчәкне дә саклый. Аңа нәкъ менә шундый итеп караганнар да.

Азәрбайҗанның борынгы скульптурасында хатын-кыз символизмы төрки халыкларга хас булган универсаль уңдырышлылык, муллык, саклау культының һәм иҗади хатын-кыз энергиясенең төбәк үзенчәлекләрен чагылдырган тирән мәдәни-тарихи күренеш булып тора. Авыл җирлекләрендә һәм каберлекләрдә неолит һәм энеолит чорларына караган балчыктан эшләнгән кечкенә хатын-кыз фигуралары табылу аларның борынгы җәмгыятьләрнең социаль-дини структурасында мөһим роль уйнавын фәнни яктан раслый, алар анда гаиләнең иминлеген һәм явыз рухлардан саклаучы, җирнең уңдырышлылыгын тәэмин итүче, шулай ук теге дөньяда ярдәм итүче ияләр (обереги) булып торганнар.

Тикшеренү шуны күрсәтә: бу скульптураларда (шул исәптән «веналар»да да) анатомик үзенчәлекләрнең (күкрәк, корсак) схематик

яки гипертрофик сурәтләнеше символның функциональ әһәмиятен – тудыру һәм имезүне – ассызыклау өчен хезмәт иткән һәм «мәңгелек хатын-кыз гүзәллеге» архетибының иң борынгы гәүдәләнеше булып тора.

Шулай итеп, төбәкнең борынгы скульптурасы төбәк мәдәни практикалары һәм гомумтөрки мифологик күзаллаулар синтезын чагылдыра, бербөтен символик система барлыкка китерә, соңгысы исә хатын-кызны иртә сәнгатьнең нигезе итеп кенә түгел, ә җәмгыятьнең рухи таянычы, дөньяга килү, муллык символы һәм киләчәкнең дә башлангычы итеп күрсәтә.

**Әдәбият**

1. Археология Волго-Уралья: в 7 т. Т. 3. Ранний железный век / Институт археологии им. А.Х. Халикова АН РТ; под общ. ред. А.Г. Ситдикова; отв. ред. А.А. Чижевский. Казань: Изд-во АН РТ, 2021. 676 с.: ил.

2. *Беляев А.В., Хуснутдинов Э.А.* Глиняная фигурка из Татарско-Суксинского поселения // Поволжская археология. 2016. № 3 (17). С. 161–167.

3. *İbrahimov Telman.* Azərbaycan qədim heykəltəraşlığı. Bakı: Şərq-Qərb, 2013. 112 s.

4. *Qurbanov Araz.* Damğalar, rəmzlər... mənimsəmələr. Bakı, 2013. 326 s.

5. *Ramazan Qafarlı.* Azərbaycan-türk mifologiyası (qaynaqları, təsnifatı, obrazları, genezisi, evolyusiyası və poetikası). Bakı: ADPU-nun nəşri, 2011. 438 s.

6. *Guliyev Ramil.* Images on the body in ancient Karabakh culture // İncəsənət və mədəniyyət problemləri Beynəlxalq Elmi Jurnal. Bakı, 2024. Vol. 18. № 1. S. 29–37.

7. https://eksisozluk.com/apakay--667275

8. https://sabaha-inamla.az/diger/30797-xanm-sozu-nec-yaranb.html

9. https://en.wikipedia.org/wiki/Gorodets_culture

***Гулиев Рамил Афиг оглы,***
*сәнгать белеме буенча фәлсәфә докторы,*
*Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе Архитектура һәм сәнгать институтының гыйльми сәркатибе*

***Гулиев Рамиль Афиг оглы,***
*доктор философии по искусствоведению,*
*ученый секретарь Института архитектуры и искусства Национальной Академии наук Азербайджана*

*ramil_amea@mail.ru*

УДК 811.512.145

*И.С. Насипов*

# АЛМАС ГАЛИМҖАН УЛЫ ШӘЙХУЛОВ – ЧАГЫШТЫРМА-ТАРИХИ ТЕЛ БЕЛЕМЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ВӘКИЛЕ
## (галимнең тууына 80 ел тулу уңаеннан)

В статье рассказывается о научно-педагогической деятельности профессора А.Г. Шайхулова – видного представителя сравнительно-исторического языкознания. В материалах он представлен как ученый, работавший в разных направлениях лингвистики: его публикации охватывают такие области как ономастика, семасиология, диалектология, лексикография, алтаистика, лингвистическая контактология и др. Он развил и практически обосновал на новом материале гипотезу Волго-Камского языкового союза Б.А. Серебренникова, был сторонником теории алтайского языкового родства Дж.Г. Киекбаева, развил теорию тюркских односложных корневых основ А.Т. Кайдарова и применил ее для анализа материалов кыпчакских языков Урало-Поволжья в алтайском языковом контексте, применил в синопсисе и таксономии лексических единиц кыпчакских языков Урало-Поволжья идеографические принципы Р. Халлинга и В. Вартбурга и др. Ученый внес большой вклад в составление общетюркских, региональных научных и учебных словарей, в изучение татарских народных говоров, в разработку проблем языковых контактов тюркских и финно-угорских народов, в подготовку молодых научно-педагогических и учительских кадров.

**Ключевые слова:** А.Г. Шайхулов, сравнительно-историческое языкознание, тюркология, ономастика, диалектология, лексикография, алтаистика, урало-алтаистика.

This article is devoted to the scientific and educational practices of Almas Shaikhulov, a prominent figure in comparative linguistics. The author describes him as a person working in different linguistic fields: onomastics, semantics, dialectology, lexicography, Altaistics, linguistic contactology, etc. A. Shaikhulov developed B. Serebrennikov's hypothesis for Volga-Kama regional association of languages and proved it, using new data. He also supported D. Kiekbaev's theory of Altai linguistic affinity, developed the theory of Turkic monosyllabic root stems introduced by A. Kaidarov and used it to analyze Kypchak languages of the Ural-Volga region in the Altai linguistic context. A. Shaikhulov applied the ideographic principles of R. Halling and W. Wartburg to the synopsis and taxonomy of lexical units of the Kypchak languages of the Ural-Volga region. He made a great contribution to the compilation of common Turkic, regional scientific and educational dictionaries, to the study of Tatar folk dialects, to the development of problems of linguistic contacts between Turkic and Finno-Ugric peoples, and to the training of young scientific, academic and teaching staff.

**Keywords:** A.G. Shaikhulov, comparative linguistics, Turkology, onomastics, dialectology, lexicography, Altaistics, Ural-Altaic studies.

Алмас Галимҗан улы Шәйхулов – филология фәннәре докторы, танылган тюрколог, хәзерге тел белемендә алтаистика һәм тел багланышлары өлкәсендәге проблемаларны аеруча актив тикшерүче, татар төбәк диалектологиясе һәм лексикографиясенең күренекле вәкиле. Галимнең фәнни эшчәнлеге Урал-Идел буе халыклары телләренең чагыштырма-тарихи лексикасына, ономастикага, этимологиягә багышланган. Тел белеме өлкәсендәге тикшеренү юнәлешләрен билгеләүгә һәм хезмәтләренең тематикасын ачыклауга шактый вакыт кирәк булыр иде. Әмма, безнең карашка, галимнең фәнни эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе – чагыштырма-тарихи тел белеме, чөнки чагыштырма-тарихи метод аның барлык фәнни хезмәтләренең нигезендә ята [3: 1345]. Боларның барысына да ул Башкорт дәүләт университетында укыту чорында ирешә.

А.Г. Шәйхулов 1945 елның 21 октябрендә БАССРның Туймазы районы Туймазы эшчеләр поселогында туа. 1963 елда Туймазының 1 нче урта мәктәбен тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген Туймазы геофизприборлар һәм аппаратура заводында эшче-электрослесарь булып башлый. Булачак галимнең педагогик эшчәнлеге Туймазы районының Түбән Бишенде сигезьеллык мәктәбендә башлана: биредә ул 1964–1965 елларда рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1970 елда Башкорт дәүләт университетының филология факультеты татар-рус бүлеген «Филолог. Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы» белгечлеге буенча уңышлы тәмамлый. Югары уку йортының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы тарафыннан, яхшы укуын һәм фәнни-педагогик эшчәнлеккә зур сәләтләрен исәпкә алып, аспирантурага тәкъдим ителә. Әмма педагогик эшчәнлеген гомуми белем бирү мәктәбендә дәвам итә: ике ел Туймазы шәһәренең 7 нче мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

1972–1975 елларда Мәскәү шәһәрендә махсус юллама буенча СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институтына аспирантурага укырга кергәч, төрки һәм монгол телләре секторында «Төрки телләр» белгечлеге буенча фәнни-тикшеренү эшчәнлеге нигезләрен өйрәнә. Уку вакытында ул илебезнең әйдәп баручы галимнәре белән тыгыз аралаша. Аның тормышында СССР ФА академигы, гомуми һәм чагыштырма-тарихи тел белеме, урал-алтаистика һәм һинд-европеистика проблемалары буенча белгеч Б.А. Серебренников; Казахстан ССР ФА академигы, алтаист, тюрколог, этнолингвист А.Т. Кайдаров; Россия Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, тюрколог, монгол телләре белгече Э.Р. Тенишев; Казахстан Республикасы Милли академиясе академигы, тюрколог, СССР халыклары телләре буенча белгеч К.М. Мусаев; профессор, лингвист, этимолог И.Г. Добродомов һ. б. пәйда була, һәм соңрак бу гыйльми даирә киңәйгәннән киңәя бара.

1975 елда А.Г. Шәйхулов, аспирантураны уңышлы тәмамлап һәм яклауга диссертациясен тапшырып, Уфага кайта һәм Башкорт дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасында эшли

башлый. Биредә ул югары уку йорты укытучысы буларак карьера үсешенең барлык баскычларын үтә: ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор. 2009 елдан – татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире, ә 2022 елдан – университетның баш фәнни хезмәткәре. Бу уку йортында ул гомеренең ахырына кадәр актив фәнни-педагогик эшчәнлеген дәвам итә.

Беренче фәнни эзләнүләрен А.Г. Шәйхулов ономастика өлкәсендә башлый. 1978 елда ул СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институты каршында «Төрки чыгышлы татар һәм башкорт шәхси исемнәре» («Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения») темасына филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә диссертацияне уңышлы яклый. Бу хезмәттә яшь галим тарафыннан семантикада гомуми һәм аермалы сыйфатларны реконструкцияләү һәм ачыклау, мотивацияләү, Урал буе төрки халыклары антропонимиконында борынгы төрки чыгышлы шәхси исемнәрне номинацияләү методологик аспектлары эшләнгән. Әлеге хезмәттә Урал-Идел буендагы төрки телле этносларның генетик яктан бердәм ономастик системасы чыганаклары булуы турындагы фикер әйтелә.

Соңыннан аның ономастика өлкәсендәге тикшеренүләре нәтиҗәләре «Төрки чыгышлы татар һәм башкорт шәхси исемнәре» («Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения» (Уфа, БашДУ нәшрияты, 1983) һәм «РСФСР халыкларының шәхси исемнәре белешмәлеге» («Справочник личных имен народов РСФСР» (Мәскәү, «Русский язык» нәшрияты, 1970), «Урал-Идел буеның кыскача топонимик сүзлеге» («Краткий топонимический словарь Урало-Поволжья») (Уфа, БашДУ нәшрияты, 2005) һ. б. урын ала [6, 143]. Соңрак ул башкорт лингвисты З.М. Раемгуҗина белән берлектә төзелгән «Башкорт һәм татар исемнәре» сүзлеген бастыра [8]. Ул Башкортстан Республикасының төбәк ономастиконы материалларын җыюга, системалаштыруга һәм өйрәнүгә зур өлеш кертә, аларның нәтиҗәләре галимнең күпсанлы гыйльми хезмәтләрендә файдаланыла.

Галимнең Урал-Идел буе кыпчак телләрендә бер иҗекле тамыр нигезләрен этимологизацияләү өлкәсендәге күпьеллык тикшеренүләре 2001 елда Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты каршында «Урал-Идел буе кыпчак телләрендә бер иҗекле тамыр нигезләрнең структурасы һәм идеографик парадигматикасы ареаль, төркиара һәм гомумтөрки лексика континуумында («Табигать (тере һәм тере булмаган)» когнитив сферасының синопсисы һәм таксономиясе)» («Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики (синопсис и таксономия когнитивной сферы «Природа (неживая и живая)» темасына филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә диссертациясен уңышлы яклау өчен нигез булды. Диссертациянең фәнни консультанты РФА мөхбир әгъзасы Э.Р. Тенишев була. Диссертациясендә ул

Урал-Идел буеның кыпчак (башкорт һәм татар) телләре материалы нигезендә Казах ССР ФА академигы А.Т. Кайдаровның казах телендә бер иҗекле тамырлар һәм нигезләр структурасының үзенчәлекләре турындагы тәгълиматын гомумтөрки яссылыкта үстерә [1].

Алга таба үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре аның «Урал-Идел буе кыпчак телләренең лексик системасында бер иҗекле тамырларның һәм нигезләрнең идеографик парадигматикасы (синхрон һәм диахрон характеристика тәҗрибәсе)» («Идеографическая парадигматика односложных корней и основ в лексической системе кыпчакских языков Урало-Поволжья (опыт синхронической и диахронической характеристики)») (Уфа, БашДУ нәшрияты, 1999), «Урал-Идел буе кыпчак телләренең тамыр нигезләре ареаль лексика континуумында һәм аларның гомумтөрки фондтагы структур-идеографик парадигматикасы (тезаурус тибындагы лексик-семантик сүзлекнең синопсисы һәм таксономиясе тәҗрибәсе)» («Корневые основы кыпчакских языков Урало-Поволжья в континууме ареальной лексики и их структурно-идеографическая парадигматика на общетюркском фоне (опыт синопсиса и таксономии лексико-семантического словаря тезаурусного типа)») (Уфа, БашДУ нәшрияты, 1999), «Урал-Идел буе кыпчак телләрендә бер иҗекле тамыр нигезләр (синхрон һәм диахрон характеристика) («Односложные корневые основы в кыпчакских языках Урало-Поволжья (опыт синхронической и диахронической характеристики)») (Уфа, «Көнчыгыш университеты» нәшрияты, 2000), «Ареаль, төркиара һәм гомумтөрки лексика континуумында Урал-Идел буе кыпчак телләренең бер тамырлы нигезләре» («Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики») (Уфа, БашДУ нәшрияты, 2000), «Алтай телләре гомумилеге контекстында Урал-Идел буе төрки телләре (лексик-семантик и идеографик сүзлек тәҗрибәсе» («Тюркские языки Урало-Поволжья в контексте алтайского языкового сообщества (опыт лексико-семантического и идеографического словаря)») (Уфа, «Көнчыгыш университеты» нәшрияты, 2004) һ. б. хезмәтләре нигезенә салына.

«Санап үтелгән хезмәтләрдә мәгънә кыры кысаларында иң борынгы сүзьясалыш парадигмаларының берсенең идеографик (төшенчә) өлкәләрен ачыклау юлы белән (СТ һәм ТС, СТС һәм ТСТ, ТСТТ тибындагы бер иҗекле структуралар һәм аларның вариатив дериватлары нинди булуы) Урал-Идел буе кыпчак телләренең үзара лексик бәйләнешләре барлыкка килүе характерлана» [5, 144]. Әлеге хезмәтләр танылган тюркологлар тарафыннан югары бәяләнде. РФА мөхбир әгъзасы, РТФА академигы Э.Р. Тенишев билгеләп үткәнчә, «А.Г. Шәйхулов Урал-Идел буе кыпчак телләрендә бер иҗекле тамыр нигезләрнең шактый тулы хәзерге заман семантик-идеографик парадигматикасын төзегән. Билгеле бер мәгънәдә, А.Г. Шәйхуловның гаять зур фактологик материалда төзегән “Табигать (тере һәм тере бул-

маган)” когнитив сферасының синопсисы һәм таксономиясе гомуми һәм төркиара лексика континуумында теоретик постулатларны аңлауга якын килгән барлык тюркологлар (шулай ук, алтаистлар) өчен нигез булып тора...» [9].

А.Г. Шәйхулов – Башкортстан Республикасында төрки-татар гомумтөрки, төбәк фәнни һәм укыту лексикографиясен үстерүгә зур өлеш керткән күренекле галим. Лексикография өлкәсендәге эшчәнлеген ул уникаль югары уку йорты фәнни-тикшеренү лабораториясе булдырудан башлады. Мондый фикер аның башына студент елларында ук килгән – ул татар һәм башкорт телләренең апеллятив һәм ономастик берәмлекләре картотекасын төзи башлый. Мәскәүдә аспирантурада укыган вакытта ук аны төзү принципларын эшли, ә соңыннан камилләштерә. Соңрак, университетта эшләгәндә, немец галимнәре Р. Халлинг һәм В. Вартбург тәкъдим иткән идеографик принципларга нигезләнеп, картотекадагы лексик берәмлекләрне тәртипкә китерә, бу синопсик төркемнәрне аларны системалаштыруда камилләштерә, дүрт зур лексик-семантик төркемгә – Галәм, Кеше, Җәмгыять һәм Танып белү – анализ ясауны тәкъдим итә. 1987 елда ул Башкорт дәүләт университетында лаборатория өчен кабинет ала, һәм соңгы вакытка кадәр ул «Идел-Кама-Урал этнолингвистик төбәгендә төрки, монгол, фин-угор һәм һинд-Европа (славян) халыкларының рухи мәдәнияте» вузара фәнни-тикшеренү (укыту) лабораториясе исемен йөртә [3: 1345]. Лаборатория картотекаларында 1,5 млн лексик берәмлек тупланган була. Ул үзенең барлык басмаларында да шушы бай коллекциягә таянып эш итә. Бу материалларның бер өлеше аның шәкертләренең диссертацияләре һәм күпсанлы фәнни хезмәтләре нигезенә салынган [4: 75].

1991 елда А.Г. Шәйхулов Төрек Республикасы Мәгариф министрлыгы чакыруы буенча бер елга якын Төркиядә фәнни командировкада була. Биредә ул төрки телләрнең күптелле сүзлеген төзүдә катнаша, татар һәм башкорт телләренең лексикасына һәм кыскача грамматикасына багышланган бүлекләр авторы була. Сүзлек 2007 елда Әнкарада төрек телендә ике томда «Төрки телләр чагыштырма сүзлеге: этимологик белешмәлек» исеме белән басылып чыга [10]. Сүзлек төзү эше Әнкарадагы Милли китапханә базасында СССР һәм чит илләрнең бер төркем танылган тюркологлары тарафыннан башкарылган. Сүзлек төзүче галимнәр коллективы белән Төркиянең әйдәп баручы тел белгечләреннән берсе – профессор Әхмәт Бижан Эрджиласун җитәкчелек итә [4: 75].

2005 елда Уфада А.Г. Шәйхулов җитәкчелегендәге авторлар коллективы «Татар теле диалектларыныың идеографик сүзлегенә материаллар» («Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка») хезмәтен бастырып чыгара. Бу басма күп томлы, һәр том берничә өлештән торачак, дип уйланыла. Ләкин хезмәтнең беренче томының ике өлеше генә дөнья күрә [2]. Бу китапларда татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларының идеографик принципка

нигезләнгән материаллары тупланган. Авторлар «Татар теленең диалектологик сүзлекләре»н (Казан, 1969; Казан, 1993; автор-төзүчеләр: Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, З.Р. Садыйкова, Г.К. Якупова һәм Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова) иҗади кулланганнар. Әмма басмага шулай ук фәнни-тикшеренү (укыту) лабораториясенең бай картотекасыннан җирле татар халык сөйләшләре буенча бик күп яңа лексик материаллар да кергән. Бу сүзлекләрне төзүгә аспирант Л.Ү. Бикмаева зур өлеш кертә [4: 75–76].

2012–2013 елларда А.Г. Шәйхулов Казахстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казахстан Республикасы төрки академиясе проектында катнаша. Аның кысаларында ике монографик тикшеренү үткәрелә: «Бер иҗекле тамыр нигезләренең сүзлек-тезаурус тәҗрибәсе» (Астана, Төрки академия, 2012) һәм «Урал-Идел буе һәм Казахстан төрки телләрендә бер иҗекле тамыр нигезләренең структурасы һәм идеографик парадигматикасы» (Астана, Төрки академия, 2013). Фәлсәфә фәннәре докторы, профессор А.Р. Абдуллин әлеге хезмәткә рецензиясендә «...бу хезмәттә барлык кирәкле анализлар һәм төрки телләрнең идеографик сүзлеген төзү омтылышы ясалган», дип билгеләп үтә [4: 76–77].

Бу мөһим фәнни проектны гамәлгә ашыру Казахстан университетлары белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне үстерергә ярдәм итә. А.Г. Шәйхулов «Алтаистика и тюркология» (Казахстан) фәнни журналының редколлегия әгъзасы була. Россия белән Казахстанның фәнни-педагогик хезмәттәшлеген үстерүгә керткән өлеше өчен ул Казахстан Республикасы Мәдәният һәм мәгълүмат министрлыгының «Казах телен үстергән өчен» күкрәк билгесенә лаек була, «Казахстан Республикасы фәнен үстерүдәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә һәм Евразия милли университеты каршындагы тюркология һәм Л.Н. Гумилёв исемендәге Алтаистика халыкара фәнни-тикшеренү үзәге Президиумының мактаулы әгъзасы итеп сайлана [6: 145]. Шуны да әйтергә кирәк: галим совет һәм советтан соңгы чорда СССРның союздаш һәм автономияле республикаларының, киләчәктә – бәйсез дәүләтләрнең һәм Россия Федерациясе милли республикаларының күп кенә әйдәп баручы тюркология үзәкләре белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Ул төрле дәрәҗәдәге фәнни конференцияләрдә даими катнаша. Аны илебез һәм чит ил лингвистик үзәкләре оештырган күп кенә әһәмиятле фәнни симпозиумнар һәм форумнарның оештыру комитетларына кертәләр. Галимнең пленар докладлары һәрвакыт фәнни җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, киң фикер алышу һәм бәхәсләр предметына әверелә.

Галим татар теле диалектларының җирле территориаль халык сөйләшләре материалларын җыюга һәм фәнни эшкәртүгә зур игътибар бирә. Ул ел саен диярлек университетның татар-рус бүлеге студентлары белән Башкортстан Республикасы районнарына, чиктәш төбәкләргә һәм өлкәләргә диалектологик экспедицияләргә чыга. Соңыннан бу материаллар лаборатория әгъзалары булган студентлар катнашында

картотека базасына кертелә, студентлар һәм аспирантланың фәнни тикшеренүләрендә кулланыла. Галимнең һәр хезмәтендә лабораториядәге диалекталь лексик материалның өлеше шактый.

А.Г. Шәйхулов тел белемендә яңа юнәлешкә – лингвистик контактологиягә нигез салучыларның берсе. Ул академик Б.А. Серебренниковның Идел-Камада төрки (башкорт, татар, чуваш) һәм фин-угор (мари, удмурт) халыкларының тел берлеге булуы турындагы гипотезасын тулысынча хуплый. Ул гына да түгел, бу гипотезаны теоретик яктан үстерә һәм гаять зур практик материалда нигезли, «Идел-Кама-Урал тел берлеге», «Идел-Кама-Урал этнолингвистик регионы» һ. б. терминнарны фәнни әйләнешкә кертә. Телләр берлеге территориясен Иделдән Уралга кадәр киңәйтә, телләр берлегенә мордва телләрен дә кертә. Галим танылган башкорт лингвисты Дж.Г. Киекбаевның алтай телләренең туганлыгы турындагы теориясен төбәк тел бәйләнешләре, төрки һәм фин-угор халыкларының этномәдәни бәйләнешләре һәм үзара йогынтысы материалында алтай һәм урал телләренең туганлыгына кадәр тирәнәйтә. Аның бер иҗекле тамыр нигезләренә таянган этимологик тикшеренү нәтиҗәләре башкорт, татар, чуваш, мари, удмурт һәм мордва этимологияләре казанышларына җирлек әзерли. Тел бәйләнешләре һәм телләр туганлыгы турындагы төп идеяләрендә ул М.З. Зәкиев, Л.Ш. Арсланов, Р.Г. Әхмәтҗанов, М.А. Зәйнуллин, Т.М. Гарипов, Н.И. Егоров, И.Г. Добродомов, Н.И. Исәнбаев, И.В. Тараканов, В.К. Кельмаков Р.Ш. Насыйбуллин, В.И. Рассадин һ. б. күренекле телчеләрнең хуплавын таба.

Профессор А.Г. Шәйхуловның фәнни кызыксынуларының һәм казанышлары киңлегенә күзәтү ясау өчен «Урало-Поволжье: языковой союз» хезмәтенә игътибар бирү дә җитә. Бу монография аның бөтен гыйльми эшчәнлеген чагылдыра һәм бу чор фәнни тикшеренүләренең үзенә күрә йомгагы итеп тә карала ала [6].

А.Г. Шәйхулов төрек телен һәм аның диалектларын камил белә. «Ислам нигезләре» («Основы Ислама») (Истанбул, 1993) һәм «Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы (С.А.С.)» («Жизненный путь Пророка Мухаммеда (С.А.С.)») (Казан, 2000) басмаларын төрекчәдән татарчага тәрҗемә итүче, «Төрек теле белән дусларча очрашулар» («Дружеские встречи с турецким языком») (Уфа, «Көнчыгыш университеты» нәшрияты, 1997) һәм «Төрек-татар-башкорт-рус сүзлекчәсе» («Турецко-татарско-башкирско-русский разговорник» (Уфа, «Гилем» нәшрияты, 2014) кебек китапларның төзүче-авторы да ул. Галим Көнчыгыш икътисад-юридик гуманитар академиясендә (ВЭГУ) төрек телен укыта, Уфада Төрек теле курсларын алып бара. Еш кына Башкортстан делегацияләренең Төркия Республикасына сәфәрләрендә һәм Уфада уздырыла торган рәсми халыкара чараларда, шул исәптән ШОС-БРИКС саммитларында (2015 елның 8–10 июле) тәрҗемәче сыйфатында катнаша.

Һәрбер талантлы галим һәм педагог кебек үк, ул үзенең фәнни мәктәбен булдырган. Аралашуда гадилеге һәм эчкерсезлеге белән

студентларны һәм яшь галимнәрне үзенә гел тартып тора. Югары уку йортындагы фәнни-тикшеренү (укыту) лабораториясе курс һәм диплом, чыгарылыш квалификация эшләре, конкурс проектлары язганда – йөзләрчә студентлар өчен, фәнни публикацияләр һәм диссертацияләр язганда аспирантлар һәм докторантлар өчен фәнни-тикшеренү үзәге булды. Лабораториядә танылган галимнәр һәм укытучылар фәнни әзерлек үтте. Мәсәлән, филология фәннәре докторлары, профессорлар Р.Ф. Исламов һәм И.С. Насипов фәнни тикшеренүләрен профессор А.Г. Шәйхулов җитәкчелегендә башлап җибәрәләр, Орхон-Енисей рун язмаларын хәзерге төрки телләр белән чагыштырып тикшерү буенча диплом эшләре язалар. Биредә доцент Л.Ү. Бикмаева татар теленең көнбатыш диалекты эстәрлетамак сөйләше буенча диссертациясен яза. Лабораториядә башкорт галиме В.Н. Асмондьяров «Идеографический и когнитологический аспекты составления диалектологического атласа башкирского языка в сравнительном плане с данными языков Урало-Поволжья: на материале корневых основ» темасына кандидатлык диссертациясен яклауга әзерли һ. б.

А.Г. Шәйхуловның тел белемендә ономасиологик, семасиологик һәм идеографик юнәлешләрдә Урал-Идел буе төрки телләренең бер иҗекле тамыр нигезләрен өйрәнү идеяләрен дәвам иттерүчесе – филология фәннәре кандидаты, доцент Н.У. Хәлиуллина. Ул 2003 елда «Семантическая и идеографическая характеристика односложных корневых основ тюркских языков Урало-Поволжья в контексте алтайского языкового общества» темасына кандидатлык диссертациясе яклый [5: 138–141]. Соңыннан диссертация материаллары җитәкчесе белән авторлыкта язылган «Урал-Идел буе төрки телләре алтай телләре гомумилеге контекстында (лексик-семантик һәм идеографик сүзлек тәҗрибәсе)» («Тюркские языки Урало-Поволжья в контексте алтайского языкового сообщества (опыт лексико-семантического и идеографического словаря)») хезмәтендә чагылыш таба [5: 140–141]. Шулай ук А Г. Шәйхулов җитәкчелегендә Л.А. Гаитованың «Урал төрки телләрендә бер иҗекле тамырларның структур һәм идеографик характеристикасы» («Структурная и идеографическая характеристика односложных корней в тюркских языках Урало-Поволжья: на материале лексики татарского, башкирского и чувашского языков, относящейся к когнитивной сфере “Природа (неживая и живая)”») дигән кандидатлык диссертациясе якланды.

А.Г. Шәйхулов – 600 гә якын фәнни хезмәт, шул исәптән монографияләр, уку әсбаплары һәм сүзлекләр авторы. Ул татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучылары һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләүгә зур өлеш кертә, төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы, тарихи фонетикасы һәм лексикасы буенча күпсанлы лекция, практик һәм махсус курслар эшли. Югары уку йортларында аның «Алтай телләрен өйрәнүгә кереш» («Введение в изучение алтайских языков») (Уфа, БашДУ нәшрияты,

1984), «Идел-Кама-Урал төбәге төрки телле халыкларының тарихи һәм диалекталь лекикасы (системалы характеристика аспектлары)» («Историческая и диалектная лексика тюркоязычных народов Волго-Камско-Уральского региона (аспекты системной характеристики)») (Уфа, БашДУ нәшрияты, 1988), «Урал-Идел буендагы кыпчак телләренең үзара лексик бәйләнешләре» («Лексические взаимосвязи кыпчакских языков Урало-Поволжья в свете их историко-культурной общности (аспекты системно-идеографической характеристики на общетюркском фоне)») (Уфа, БашДУ нәшрияты, 1999) һ. б. уку әсбаплары танылу алды [6: 146].

Югары белем һәм фән үсешенә керткән өлеше өчен А.Г. Шәйхулов Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә, «Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була. Табигать һәм җәмгыять Халыкара Фәннәр академиясе (Евразия проблемалары өлкәсендәге тикшеренүләр өчен) аны академиянең Евразия бүлеге буенча хакыйкый әгъзасы итеп сайлый. А.Г. Шәйхулов тел белеме үсешенә зур өлеш кертә, аның биографиясе «Persona Grata» халыкара рейтинг энциклопедиясендә урнаштырыла, исеме «Дөньяның әйдәп баручы тел белгечләре» (М., 2000), «Урал-Алтай теле (төрки-монгол) тел белеме» («Урало-Алтайское (тюрко-монгольское) языкознание») (М., 2001) һәм «Казан лингвистика мәктәбе» («Казанская лингвистическая школа») белешмәлегенә (Казан, 2008) кертелгән.

Алмас Галимҗан улы искиткеч педагог, таләпчән фәнни җитәкче, игътибарлы остаз, уңай карашлы, актив, игелекле, ачык күңелле һәм ярдәмчел кеше иде. Аны һәрвакыт анык акыл, кайнап торган энергия, тапкырлык һәм гаҗәеп җанлы, образлы сөйләм аерып торды. Күпсанлы укучылары, татар җәмәгатьчелеге аны даими искә алып торалар.

**Әдәбият**


1. *Кайдаров А.Т.* Структура односложных корней и основ в казахском языке. Алма-Ата: Наука, 1986. 322 с.

2. Материалы к идеографическому словарю диалектов татарского языка / авт.-сост.: А.Г. Шайхулов, Л.У. Бикмаева, З.Р. Садыкова. Уфа: РИО БашГУ, 2005. Т. I. Ч. 1. XXI, 512 с.

3. *Насипов И.С.* Алмас Галимзянович Шайхулов (К 65-летию со дня рождения) // Вестник Башкирского университета. 2010. Т. 15, № 4. С. 1345.

4. *Насипов И.С.* Татарская лексикография в Башкортостане // Гуманистическое наследие в культуре и образовании. Традиции и инновации в национальных системах образования: материалы Национальной науч.-практ. конф. 21–22 ноября 2019 г. Уфа: Изд-во БГПУ, 2018. С. 72–78. URL: https://bspu.ru/files/76815

5. *Насипов И.С., Тимашева А.А.* Деятельность Н.У. Халиуллиной по изучению односложных корневых основ тюркских языков Урало-Поволжья Ступени созидания / сост.: И.С. Насипов, А.Г. Халиуллина. Уфа: БГПУ, 2022. С. 137–141.

6. *Насипов И.С., Мансуров И.С., Зарипова И.Ф.* Памяти Алмаса Галимзяновича Шайхулова (21.10.1945–06.01.2022) // Российская тюркология. 2022. № 3–4 (36–37). С. 143–146.

7. *Шайхулов А.Г.* Урало-Поволжье: языковой союз. Уфа: Китап, 2018. 463 с.

8. *Шайхулов А.Г., Раемгужина З.М.* Башкирские и татарские имена собственные. Уфа, 2006. 92 с.

9. Шайхулов Алмас Галимзянович // URL: https://tuimazimcb.ru/index.php?option=com_k2&view=item&id=17924 (мөрәҗәгать итү көне: 12.10.2025).

10. Türkiye türkçesindeki türkçe sözlüklerin köken sözlügü: Etimolojik Sözlük Denemesi / Prof. Dr. Tuncer Gülensoy. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2007. T. I (A–N). 608 s.; T. II (O–Z). 502 s.

***Насипов Илшат Сәхиятулла улы,***
*филология фәннәре докторы, М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры*

***Насипов Илшат Сахиятуллович,***
*доктор филологических наук, профессор кафедры татарского языка и литературы Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы*

*nasipov2021@yandex.ru*

УДК 398

*Л.Р. Мортазина*

# ПЕДАГОГ ҺӘМ ШӘРКЫЯТЧЫ ГАЛИМ ӘБҮБӘКЕР ДИВАЕВ

В представленной статье рассматривается жизнь и научно-педагогическая деятельность ученого-востоковеда и педагога, выходца из татарского дворянского рода Оренбурга Абубакира Ахметзяновича Диваева, посвятившего свою жизнь изучению этнографии и фольклора тюркских народов.

А.А. Диваев сыграл важную роль в сборе и сохранении уникальных, ранее неизвестных в научной среде образцов фольклорного и этнографического наследия тюркских народов, также в организации народного университета и Туркестанского восточного института, в становлении этнографической науки тюркских народов. Помимо всего, он известен как один из участников любительского театра и преподаватель татарской школы в Ташкенте.

На основе анализа трудов А. Диваева, также публикаций татарской периодической печати начала XX века и работ казахских ученых, посвященных жизни и творчеству ученого, автор предпринимает попытку определения его места в становлении российской востоковедческой науки на рубеже XIX–XX веков и роли в развитии педагогической мысли в Туркестане.

Статья посвящена 170-летию со дня рождения А. Диваева.

**Ключевые слова:** Абубакир Диваев, Оренбург, казахи, этнография, фольклор, педагогическая деятельность, татарская школа.

This article explores the life and work of Abubakir Akhmetzyanovich Divaev, a scholar, orientalist, and educator from Orenburg who dedicated his life to the study of the ethnography and folklore of the Turkic peoples.

A.A. Divaev played a key role in collecting and preserving previously known examples of the folklore and ethnographic heritage of the Turkic peoples, as well as in organizing the People’s University and the Turkestan Oriental Institute, and in developing the ethnographic science of the Turkic peoples. He is also known as a member of an amateur theater group and a teacher at the Tatar school in Tashkent.

Based on an analysis of A. Divaev’s works, as well as publications in the Tatar periodical press of the early 20th century and works by Kazakh scholars dedicated to his life and work, the author attempts to determine his place in the development of Russian Oriental studies at the turn of the 20th century and his role in the development of pedagogical thought in Turkestan. This article is dedicated to the 170th anniversary of A. Divaev’s birth.

**Keywords:** Abubakir Divaev, Orenburg, Kazakhs, ethnography, folklore, pedagogical activity, Tatar school.

Казах, үзбәк, каракалпак һ. б. төрки халыкларның этнографиясен, фольклорын, тарихын өйрәнүгә нигез салучыларның берсе, Оренбург төбәгеннән чыккан атаклы галим һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог Әбүбәкер Әхмәтҗан улы Диваевның тууына быел 170 ел тула. Казахлар тарафыннан үз галимнәре итеп танылган һәм эшчәнлеге бик

җентекле өйрәнелгән күренекле мәгърифәтченең исеме һәм хезмәтләре туган төбәгендә, кызганыч, әлегәчә аз билгеле.

Әбүбәкер Диваев 1855 елның 6 (18) декабрендә Оренбург шәһәрендә татар дворяннары нәселе [9: 148] дәвамчысы Әхмәтҗан Шаһиморат улы Диваев гаиләсендә дөньяга килә. XIX гасырда нәселнең Тукай авылында (хәзерге Башкортстан Республикасы Бишбүләк районына карый) яшәгән тармагына нәселдән күчүче дворянлык бирелгән. Татар галиме һәм мәгърифәтчесе булып танылу алачак Ә. Диваевның ата-бабалары да шушы авылдан чыкканнар [19: 261].

Әбүбәкер башта гаиләдә, аннан соң беркадәр Төркестанда өяз башлыгы вазифаларын башкаручы агасында тәрбияләнә. Оренбург кадет корпусының Азия бүлекчәсендә белем алган егет, 1876 елда әлеге уку йортын тәмамлаганнан соң, Төркестан төбәгенә хәрби хезмәткә билгеләнә, аңа тәрҗемәче вазифаларын үтәү йөкләнә. Ә. Диваевның шушы вакыттан соңгы барлык гомере Урта Азия, Казахстан белән бәйле була. Хәрби эш белән беррәттән, ул шул төбәктә яшәүче халыкларның яшәешенә, көнкүрешенә игътибар итә, телләре, тарихы, этнографиясе, халык иҗаты, каберташ язмалары белән кызыксына башлый. Шактый эзләнүләр алып бара, казахларның тормыш-көнкүреше, рухи дөньясы белән бәйле материалларны туплый башлый. Махсус белеме булмаса да, тырышлыгы һәм киң эрудициясе бәрабәренә мәгълүматлы белгеч булып җитешә.

Ә. Диваев Көнчыгыш халыкларының телләрен, әдәбиятын һәм мәдәниятен бик яхшы белгән [16: 15]. Әлеге гыйлемнәрен күпсанлы фәнни хезмәтләр язуда файдаланган. Шулай итеп, аның 1886 елдан соңгы тормышы, нигездә, фән, әдәбият, гыйльми тикшеренүләр белән бәйле.

Моннан тыш Ә. Диваев төрки халыклар арасында аң-белем, фәнни белемнәр тарату белән шөгыльләнгән, сәнгатьнең төрле төрләрен үстерүгә үзеннән өлеш керткән. Бу елларда татарлар яшәгән башка төбәкләрдәге кебек, Ташкентта да театр түгәрәкләре эшли башлый, театраль тамашалар күрсәтелә. Бу эшләрдә, билгеле булганча, татарлар үзләре башлап йөри. 1904 елда Ташкент каласында һәвәскәр татар театры барлыкка килә. Аны оештыруда татар полковнигы Ә. Диваев катнаша. Беренче спектакльләр нәкъ менә аның фатирында күрсәтелә [20: 158].

Ә. Диваев – педагог та. 1906 елда хәрби хезмәттән киткәннән соң, ул Ташкенттагы татар җамигъ мәчете каршында ачылган татар мәктәбендә укыта, мөдирлек итә (1915 елда әлеге вазифаны башкара) [17]. И. Гаспринский исемен йөрткән бу мәктәпне оештыруда һәм анда укытуда, Әбүбәкер Диваевтан тыш, Габдулла Биги (Мостакаев), Булат Салиев, Габдрахман Чанышев, Һади һәм Хәбибрахман Фәйзиләр катнашкан [2: 400]. Билгеле булганча, әлеге татарлар Төркестанда халыкка аң-белем тарату буенча зур эш башкарганнар[1].

[1] Ә. Диваев һәм Б. Салиев – профессорлар, Г. Биги – доцент, Ташкент татар мәгариф институты директоры, Һ. Фәйзи – Сәмәркандта дәүләт нәшриятының беренче директоры.

Педагогик эшчәнлек алып бару белән беррәттән, Ә. Диваев фән өлкәсендә эзләнүләрен дә дәвам итә. Бу елларда аның төрле фәнни журналларда, вакытлы матбугатта казахларның, үзбәкләрнең, каракалпакларның фольклоры, мифлары, риваятьләре, әкиятләре, ышанулары, гореф-гадәтләренә багышланган күпсанлы мәкаләләре, хезмәтләре дөнья күрә. Мисал өчен, Ә. Диваевның казах халык әкиятләрен өйрәнүгә керткән өлешен ассызыклап, аның 1903–1912 елларда «Этнологическое обозрение» һәм «Сборник материалов для статистики Сыръ-Дарьинской области» журналларында басылган язмаларын искә алу урынлы булыр. Автор аларда Сырдәрья өлкәсендә яшәгән казахларның иң билгеле әкиятләрен туплап, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә [11; 12; 13; 14; 15].

1915 елда Төркестанның рус фәнни даирәләрендә Әбүбәкер әфәндене 60 яшьлек юбилее һәм мәдәни хезмәткә керешүенең 25 еллыгы зурлап билгеләп үтелә. «Туркестанский курьер», «Туркестанские ведомости» газеталарында юбилярга багышланган зур-зур мәкаләләр басылып чыга. Бу вакыйга татар вакытлы матбугатында да яңгыраш ала.

«Вакыт» газетасының 1915 елдагы 30 сентябрь санында Ташкент шәһәреннән Әхмәт Сәрдар дигән авторның «Әбүбәкер әфәнде Диваев» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Анда автор Ә. Диваевның Сырдәрья өлкәсендәге статистик җыентыкларда дөнья күргән күпсанлы хезмәтләрен искә ала. «Әбүбәкер әфәнденең язган нәрсәләре, сарыф иткән иҗтиһады бик зур булса да, мин бу урында бәгъзы берсен генә яздым. Боларны үз матбугатымызга чыгарып, үз халкымызга гарыз итү (язып аңлату, тәкъдим итү) тиеш булса да, бу этнографистымызның зур-зур хезмәтенә кул тидерүче, аны җентекләп мәйданга куючы эшлекле бер кул күренми. Егерме биш ел буена эшләнгән зур милли хезмәт, Төркестан шикелле бай вә шәүкәтле мазыйга (үткәнгә) малик булган бер хәлфәнең халык әдәбияты күптән матбугат мәйданында күренергә, төрк вә татар дөньясына гарыз ителергә кирәк өмет вә теләкне кичектерә, бөтен арзуны (теләкне) киләчәккә калдыра бара», – дип яза ул Ә. Диваевның әлеге хезмәтләренең асылын нигезләп [17]. Төрки-татар дөньясы өчен әлеге зур хезмәтнең никадәр әһәмиятле булуына, әмма, ни кызганыч, фәнни мәкаләләрнең бары тик рус телендә генә язылып, рус гыйльми даирәләрендә генә таралуына Ә.-З. Вәлиди дә басым ясый: «Әбүбәкер әфәнде безнең төрк этнографиясенә, ягъни безнең милли гыйлемебезгә никадәр күп һәм шулкадәр озын еллар хезмәт иткән кеше булса да, безнең халкыбыз аны яхшылап белми, чөнки бездә, беренчедән, Әбүбәкер әфәнде өйрәнгән гыйлем белән шөгыльләнгән кеше юк, икенчедән, Әбүбәкер әфәнденең бөтен хезмәтләре русларның үз араларында да бик аз нөсхәләр белән тарала торган фәнни журналларда рус телендә язылган» [7]. Ә-З. Вәлиди галимнең хезмәтләрен туплап, төрки телгә тәрҗемә итеп бастырып чыгаруның халкыбыз өчен бик зур әһәмияткә ия булуын ассызыклый. Ә. Диваевның эшчәнлегенә зур бәя биреп, ул: «Әбүбәкер әфәнде

җыйган нәмәләр – телебез һәм халкыбыз өчен бәһаләп бетермәслек бер хезмәттер», ди [8].

Алда искә алынган Ә. Сәрдарның 1916 елда «Шура» журналында дөнья күргән икенче бер язмасында Ташкент шәһәренең борынгы һәм Россия составына кушылганнан соңгы тарихы, «Ташкент» атамасының килеп чыгышы мәсьәләсе яктыртыла. «Хәзерге Ташкәнднең мөселман каименең зоһуры хосусында нәкыл (Әбүбәкер Диваевның этнографиягә гаид әсәрләреннән)» дип исемләнгән әлеге мәкалә [18: 76–77], исеменнән үк күренгәнчә, Ә. Диваевның шул заманның фәнни даирәләрендә яхшы билгеле «Ташкент шәһәре килеп чыгу хакында риваять» («Предание о возникновении города Ташкента»), «Үзбәкләрнең килеп чыгышы хакында риваять» («Предание о происхождении узбеков») дигән хезмәтләренә таянып язылган.

Инде әйтеп узылганча, Ә. Диваевның тормыш юлы һәм гыйльми эшчәнлеге бүгенге көндә казах галимнәре тарафыннан җентекләп өйрәнелгән. Ф. Уразаева, мәсәлән, аның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлегенә багышланган [21], Б.А. Байтанаев галимнең тарихи мирасын һәм төбәкне өйрәнү эшчәнлеген яктырткан [5] кандидатлык диссертацияләре яклыйлар. Б.А. Байтанаевның бу темага караган берничә китабы да басылып чыга [1; 4]. Казах галимнәре Ә. Диваевның «үз хезмәтләрендә казах тормышының чынбарлыктагы картинасын сурәтләү» [6: 61] белән беррәттән, Казахстанның архитектура мирасын башлап өйрәнүчеләрнең алгы сафында торуын да ассызыклыйлар [16: 15].

Ә. Диваевның гыйльми эшчәнлеге киң фәнни даирәләрдә зур яклау һәм бәя алган. Атаклы рус галимнәре В.В. Бартольд, Н.Ф. Катанов, А.Н. Самойлович һ. б. аның хезмәтләренә олы бәя биреп, бу хактагы фикерләрен язып чыгалар [16: 15].

Чыннан да, Ә. Диваев төрки халыкларның борынгыдан килгән иҗатын туплауга һәм өйрәнүгә бик күп көчен һәм вакытын сарыф итә. Халык мәкальләренә, җырларына, бәетләренә, легендаларына, әкиятләренә, аеруча күчмә казахларның тормыш-көнкүрешенә, рухи тормышына бәйле булган материалларга ул аеруча зур игътибар бирә. Галим үзенең фәнни ачышлары арасында моңарчы беркем дә өйрәнмәгән, беркайда да басылып чыкмаган этнографик материалларның булуын хәбәр итә, телдән телгә сөйләнелеп, бу көннәргә килеп җиткән әлеге кыйммәтле мирасның, хәзер өйрәнмәгән очракта, мәңгелеккә юкка чыгу ихтималы турында искәртә [10: 150]. Нәкъ шуның өчен дә ул бу бай чыганакларны җыя, туплый, һәм, шуның өстенә, революциягә кадәрге кайбер этнографлардан аермалы буларак, җентекләп өйрәнә һәм тикшеренү нәтиҗәләрен фән эшлеклеләре, киң җәмәгатьчелек белән уртаклаша – лекцияләр укый, чыгышлар ясый, гыйльми хезмәтләр яза, бик күп яңа тарихи фактларны фәнни әйләнешкә кертә. 1896–1898 елларда Диваев казах халкының күмү йолалары, халык сынамышларына нигезләнеп ел фасылларын аңлатуга һ. б. темаларга караган тикшеренүләре белән Казан университетының Археология,

тарих һәм этнография җәмгыяте утырышларында чыгыш ясый [6: 62]. Г. Вәлиханов аны казах халкы турында бай этнографик материал туплаган, бу өлкәдә иң күп эш башкарган олуг галим буларак бәяли. Дөрестән дә, Ә. Диваев хезмәтләрендә казах халкының мәдәни һәм көнкүреш тормышының бар яклары да – хуҗалык итү үзенчәлекләре (терлекчелек, игенчелек үсеше), матди мәдәнияте (милли ризыклар, кием-салым һ. б.), гаилә мәсьәләләре (хатын-кызның гаиләдәге урыны, уеннар, туй традицияләре), иҗтимагый тормышы, халык белемнәре һ. б. чагылыш тапкан [6: 61–62].

Ә. Диваев революциядән соң да фәнни-педагогик эшчәнлеген дәвам итә. Ул Ташкент шәһәрендәге Урта Азия дәүләт университетын һәм Шәрык институтын оештыручыларның берсе була, әлеге уку йортларында казах этнографиясе кафедраларын ачуда башлап йөри, студентларга дәрес бирә [6: 65]. Соңрак аңа университетта профессор дәрәҗәсе бирелә. Моннан тыш, ул Ташкентта күренекле татар педагоглары Булат Салиев, Габдулла Мостакаев, Габдрахман Сәгъди, Гариф Алпаровлар белән берлектә «Татар мәгариф институты»нда (баштарак «Белем йорты» буларак билгеле) укыта. Шәһит Әхмәдиев тарафыннан оештырылган бу уку йортының беренче директоры Г. Мостакаев була. Анда, татар яшьләре белән беррәттән, уйгур, казах, үзбәк, дүнгән студентлары да белем алган [3: 432, 433].

Ә. Диваевның төрки халыкларның бай рухи мирасын өйрәнүгә һәм гыйльми белемнәрне таратуга багышланган фәнни-педагогик эшчәнлеге үзе исән вакытта ук тиешенчә бәяләнә. Төркестан Республикасының Халык комиссарлары советы 1923 елда Төп Урта Азия музеенда галимнең исемен йөртүче этнография бүлеген ачу, Казах мәгариф институты каршында оештырылачак тарих һәм этнография кафедрасына Ә.Ә. Диваев исемен бирү хакында карар кабул итә [6: 66–67].

Әбүбәкер Диваев 1933 елның 5 февралендә Ташкент шәһәрендә вафат була. Кабере дә шунда. Бүгенге көндә кардәш төрки халыкларның рухи мәдәнияте һәм мәгарифе үсешенә биниһая зур өлеш керткән, йөзгә якын фәнни хезмәт язган Оренбург татарының исемен Шымкент, Алматы, Астана шәһәрләрендәге урамнар йөртә.

**Әдәбият**

1. А.А. Диваев – этнограф: Биобиблиографический справочник / сост. Б.А. Байтанаев. Чимкент, 1990. 47 с.

2. *Әйди Т.Р.* Тылсымлы көч // Әйди Т.Р. Сайланма әсәрләр: 4 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 396–427.

3. *Әйди Т.Р.* Мәгариф каһарманнары // Әйди Т.Р. Сайланма әсәрләр: 4 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 428–439.

4. *Байтанаев Б.А.* А.А. Диваев. Очерк жизни и деятельности. Шымкент; Алматы, 2004. 258 с.

5. *Байтанаев Б.А.* Историко-краеведческая деятельность А.А. Диваева: автореф. дис. … канд. ист. наук. Алматы, 1993. 24 с.

6. *Валиханов Г.Н.* Этнография казахского народа в трудах А.А. Диваева // Советская этнография. М., 1958. № 5. С. 61–70.

7. *Вәлиди Ә.-З.* Уфамыздан чыккан бер галимнең хезмәтенә егерме биш ел тулу мөнәсәбәте илә // Тормыш. 1915. 11 июнь.

8. *Вәлиди Ә.-З.* Уфамыздан чыккан бер галимнең хезмәтенә егерме биш ел тулу мөнәсәбәте илә // Тормыш. 1915. 12 июнь.

9. *Габдуллин И.Р.* От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006. 320 с.

10. *Диваев А.* Итъ-ала-казъ // Этнографическое обозрение. 1908. № 1–2. С. 149–150.

11. *Диваев А.* Сказки киргизов Сыръ-Дарьинской области (перевод с киргизского) // Этнографическое обозрение. 1903. № 1. С. 98–111.

12. *Диваев А.* Сказки киргизов Сыръ-Дарьинской области // Этнографическое обозрение. 1904. № 1. С. 91–114.

13. *Диваев А.* Семь сказок киргизов Сыръ-Дарьинской области // Этнографическое обозрение. 1906. № 1–2. С. 114–127.

14. *Диваев А.* Сказки киргизов Сыръ-Дарьинской области // Этнографическое обозрение. 1912. № 1–2. С. 200–208.

15. Сказки, собранные в Чимкентской и Аулиатинском уездах А.А. Диваевым // Сборник материалов для статистики Сыръ-Дарьинской области. Ташкент, 1891. С. 68–108.

16. *Елгин Ю.А.* Краткий научно-биографический очерк члена-корреспондента Национальной академии наук Республики Казахстан Бауыржана Абишевича Байтанаева // Байтанаев Бауыржан Абишевич: Биобиблиографический указатель / сост. Ю.А. Ёлгин. Алматы: ЦНБ, 2012. С. 5–56.

17. *Сәрдар Ә.* Әбүбәкер әфәнде Диваев // Вакыт. 1915. 30 сентябрь.

18. *Сәрдар Ә.* Хәзерге Ташкәнднең мөселман каименең зоһуры хосусында нәкыл (Әбүбәкер Диваевның этнографиягә гаид әсәрләреннән) // Шура. 1916. № 9. Б. 76–77.

19. Татар энциклопедиясе: 6 томда. 2 т. Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2010. Б. 261.

20. Татары Узбекистана: энциклопедический справочник / отв. ред.: Б.Л. Хамидуллин, Л.М. Айнутдинова. Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения им. М. Хасанова АН РТ, 2025. С. 158–159.

21. *Уразаева Ф.* А. Диваев – фольклорист: автореф. дис. … канд. ист. наук. Алма-ата, 1974. 28 с.

***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Муртазина Ляля Раисовна,***
*кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник*
*Центра истории и теории национального образования*
*Института истории им. Ш. Марджани АН РТ*

*lyalyamur@mail.ru*

УДК 93.94

***А.Н. Хәсәнова***

# СӘЛАХ КАМАЛНЫҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕ (тууына 140 ел тулу уңаеннан)

В статье рассматриваются этапы жизни, научная и творческая деятельность Салахетдина Камалетдинова (Салах Камала) – известного педагога, ученого, каллиграфа и общественного деятеля первой половины XX века. Особое внимание уделяется его роли в развитии татарского образования, продвижении научных знаний и сохранении культурного наследия народов Поволжья и Востока. Рассмотрены ключевые этапы его педагогической и научной карьеры, включая преподавательскую деятельность, работу в политотделе, руководство отделом редких книг и рукописей Казанского университета, а также методическую помощь в изучении редких рукописей и переводах на татарский язык. Подчеркнут вклад Камала в ликвидацию безграмотности и создание учебных пособий, отражающих национальную специфику образовательного процесса. Труды и методики Камала остаются важным источником для современных педагогов и исследователей.

**Ключевые слова:** Салах Камал, Салахутдин Камалетдинов, изобразительное исскуство, педагог, художник, каллиграф, медресе «Хусаиния», рукописи.

The article examines the stages of life, scientific and creative activity of Salakhetdin Kamaletdinov (Salah Kamala), a famous teacher, scientist, calligrapher and public figure of the first half of the 20th century. Special attention is paid to its role in the development of Tatar education, the promotion of scientific knowledge and the preservation of the cultural heritage of the peoples of the Volga region and the East. The key stages of his pedagogical and scientific career are considered, including teaching, work in the political department, leadership of the Department of rare books and manuscripts at Kazan University, as well as methodological assistance in the study of rare manuscripts and translations into Tatar. Kamal's contribution to the eradication of illiteracy and the creation of textbooks reflecting the national specifics of the educational process is emphasized. Kamal's works and methods remain an important source for modern educators and researchers.

**Keywords:** Salakh Kamal, Salakhutdin Kamaletdinov, fine arts, teacher, artist, calligrapher, madrasah «Husainiya», manuscripts.

XX гасыр башы татар халкының иҗтимагый-мәдәни тормышы шушы чор татар зыялыларының актив эшчәнлеге белән билгеләнә. Аларның күбесе мәгариф һәм мәдәният үсешенә сизелерлек зур йогынты ясаган. Бүгенге көндә әлеге эшлеклеләрнең иҗади мирасын өйрәнүгә, аларның үз заманы өчен дә, хәзерге заман өчен дә әһәмиятен билгеләүгә юнәлдерелгән киң күләмле тикшеренүләр үткәрелә. Киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган әнә шундый шәхесләр арасында талантлы педагог, рәссам, каллиграф, ташка уеп ясаучы, җәмәгать эшлеклесе, дәреслекләр һәм уку-укыту әсбаплары авторы Сәлах Камал да бар.

Камалетдинов Сәлахетдин Камалетдин улы (Сәлах Камал) 1885 елның 10 маенда Тәтеш өязе Апас (хәзер шәһәр тибындагы посёлок, Татарстанның Апас районы үзәге) авылында, Иске Шәйморза авылының 2 нче Җамигъ мәчете имамы Камалетдин Фәхретдинов (1852–1905) һәм Апас Җамигъ мәчете имамы кызы Бибимаһруй Фәхретдинова (Вәлидова; ?–1942) гаиләсендә туа. Бала чагында бабасы Җәләлетдин Вәлидов йортында тәрбияләнә. Гаиләдә Сәлахтан кала тагы ике малай һәм бер кыз үсә (абыйсы Исмәгыйль 1942 елда Бөек Ватан сугышында һәлак була, икенче абыйсы Таһир исә 1944 елда төрмәдә үлә) [1: 81–82].

Шунысы да мөһим: С. Камал – укымышлы нәсел вәкиле. Алда искәрткәнчә, аның бабасы – имам, ә әнисе ягыннан ул татар халкының күренекле тел һәм әдәбият галиме, педагог, тарихчы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Җамал Вәлидигә (Вәлидов Җамалетдин Җәләлетдин улы) барып тоташа: әнисе белән Җ. Вәлиди – бертуганнар. Шулай ук язучы, журналист, тәрҗемәче Садри Җәләл дә (Вәлидов Садрислам Хәйретдин улы) аның туганнан туган энесе булып тора.

Башлангыч белемне Буа районы Иске Шәйморза авылы мәктәбендә алганнан соң, Сәлах башта Буа шәһәрендә, ике елдан соң Казандагы Айтугановлар мәдрәсәсендә укуын дәвам иттерә. Бу елларда кадими мәдрәсәләрдә укучы шәкертләр уку программасына һәм дини схоластика укытуга карата ризасызлык белдерә башлыйлар. Укуын рус мәктәбендә дәвам итәргә теләгән Сәлахка әти-әнисе ризалык бирми, һәм ул 1900 елда Төркиягә китеп, Константинополь университетына укырга керә. 1905 елда укуын уңышлы тәмамлап, «Физик» белгечлеге буенча диплом ала. Шул ук елның көзендә, әтисе вафат булу сәбәпле, туган ягына әйләнеп кайта һәм мөгаллимлек эшенә керешә, биш ел буе Иске Шәйморза авылындагы мәхәллә мәктәбендә укыта. 1907 елның көзендә ялган донесение буенча өендә ике тапкыр тентү үткәрелә – С. Камалның барлык кулъязма хезмәтләре, документлары, шул исәптән университетны тәмамлау турындагы таныклыгы да конфискацияләнә [1: 76].

1910 елда С. Камал Оренбургка килә һәм җиде ел дәвамында «Хөсәения» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. Монда укыту чорында ул мәдрәсә каршында «Шәрык музее» булдыруга, аны җиһазлауга күп көч һәм хезмәт куя [5: 28]. Музей һәм тарих түгәрәгенә экспонатлар туплау барышында аңа байтак авыл һәм шәһәрләрне йөреп чыгарга туры килә.

Оренбургта эшләгәндә С. Камал Коллар авылы (элекке Тәтеш өязе, хәзерге Апас районындагы Кызылтау авылы) мулласы кызы – Зәйнәп Вәли кызы Камалова (Әдһәмова; 1888–1969) белән таныша [1: 82]. Тиздән алар өйләнешәләр, ике уллары – Нияз һәм Марат туа.

Зәйнәп Камалова да гомерен балалар укытуга багышлый. 1912 елда Оренбургта кызлар өчен хосусый мәктәп – «Камалия мәктәбе»н ача. С. Камал әлеге кыз балалар урта мәктәбе эшен җайга

салуга да күп көч куя. «Камалия мәктәбе» Октябрь инкыйлабына кадәр эшләп килә [2: 146]. Казанга күчеп килгәч, З. Камалова күп еллар буена Молотов районының (Казан шәһәренең хәзерге Совет районы) 18 нче мәктәбендә балалар укыта [1: 82–83].

1919–1924 елларда С. Камал «Хөсәения» мәдрәсәсе базасында ачылган Татар халык мәгарифе институтында рәсем, сызым, татар тарихы һәм мәгълүмате мәдәния (культура мәгълүматлары) фәннәрен укыта, бер үк вакытта Башкортстан педагогия институтында һәм педтехникумында эшли [1: 85].

Октябрь инкыйлабыннан соң, С. Камал күп тапкырлар укучылар өчен кыска вакытлы җәйге курслар директоры вазифасын башкара. 1918 елдан башлап Минзәлә шәһәрендә, 1919 елда Оренбург губернасының Бозаулык шәһәрендә, Казан һәм Башкортстанда педагогик курсларны оештыруда катнаша һәм укыта да [1: 91].

Гражданнар сугышы чорында, ягъни 1919–1920 елларда үз теләге белән Көнчыгыш (соңыннан Төркестан) фронтының 1 нче армиясе сәяси бүлегендә рәссам була, клубларны бизәүдә, армияне байраклар, сәяси лозунглар, декорацияләр һ. б. белән тәэмин итүдә актив катнаша [1: 66]. Сугышның беренче елларында шәһәрдән шәһәргә йөрүче агитпоездлар яки пароходта йөрүче мобиль агитбригадалар агитация һәм пропаганданың иң нәтиҗәле ысулларыннан берсе була. Мондый агитбригадалар урыннарда митинглар үткәрә, лекцияләр укый, шикаятьләр кабул итә, күргәзмәләр һәм концертлар оештыра. Шундый поездны бизәүгә С. Камал да үз өлешен кертә. 1919 елда ул бизәгән агитвагонның макеты Мәскәүдә Кызыл армия үзәк музее каршындагы күргәзмәдә 38 елдан артык тамашачыларга күрсәтелә. Бу – Гражданнар сугышы вакытында эшләнгән иң уңышлы агитвагоннарның берсе [1: 92]. Шул ук вакытта С. Камал Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясе сәяси бүлеге һәм РКП(б)ның Каспий аръягы өлкә комитеты органы булган «Кызыл Йолдыз» газетасында эшли [1: 66]. Шул чорда Урта Азия тимерьюлында Самарадан Ташкентка кадәрге бөтен станция атамалары талантлы рәссам һәм каллиграф кулы белән гарәп графикасының нәстәгълик стилендә язылган була. Гомумән, Гражданнар сугышы чорында С. Камал актив эшчәнлек алып бара, татар һәм башкорт кызылармиячеләре арасында массакүләм агитация эшен оештыра, лекция һәм докладлар белән чыгыш ясый.

С. Камал ташка уеп язучы хаттат буларак та таныла. Ул ясаган кабер ташлары (аерым алганда, татар язучысы Мөхәммәтшакир Мөхәммәдовныкы) Оренбург шәһәренең Яңа мөселман зиратында сакланып калган һәм аларның күбесе – уйма ысул белән башкарылган эпиграфик һәйкәлләрнең матур үрнәге [6: 91].

1924–1928 елларда илдә гомуми укый-яза белүне күтәрү буенча кампания башлануга, С. Камал Үзбәк ССРның Хива шәһәре халык мәгарифе бүлегенә командировкага җибәрелә. Анда ул хатын-кызлар

педагогия техникумында укыта, мәгариф бүлеге мөдире була, Совет партия мәктәбендә, ир-атлар педагогия техникумында завуч булып эшли [1: 86]. Җирле үзбәк, шулай ук таҗик, төрекмән һәм каракалпак халыклары арасыннан Урта Азиядәге совет мәктәпләре өчен укытучы кадрлар әзерләү белән шөгыльләнә.

Балачактан ук рәсем ясау һәм гамәли сәнгать техникасы элементлары белән мавыгу аңа алга таба рәсем, сызым, литография, цинкография, каучук штампы һәм басу техникаларын үзләштерергә мөмкинлек бирә. С. Камал татарлар арасында график сәнгатьне пропагандалый, татар мәктәпләрендә беренчеләрдән булып рәсем, сызым кебек предметларны укыта башлый.

XX йөз башы татар вакытлы матбугатында, шул исәптән «Шура», «Мәктәп», «Мөгаллим» журналлары битләрендә С. Камалның рәсем сәнгатенең тарихы һәм аны мәктәптә укыту, тәнкыйть эшенең куелышы, кызлар өчен аерым дәреслекләр булдыру зарурлыгы һәм башка мәсьәләләрне күтәргән беренче мәкаләләре басыла башлый. Минзәлә Мәгариф комиссариаты тарафыннан 1918 елда нәшер ителгән рәсем ясау методикасы буенча беренче кулланманы да С. Камал әзерли [3]. Оренбургта һәм Казанда эшләү дәверендә аның күпсанлы дәреслек-кулланмаларыннан: «Мохтәсар имла мөгаллиме» (дөрес язу буенча кыскача дәреслек) (1911), «Мөселманча әлифба һәм үрнәкләр № 1» (1912), «Мөкәммәл тарихе ислам. Атлас» (1912), «Гакаид. Әхкям исламия мәҗмугасыннын. 1 нче кисәк» (1913), «Мәгълүмат мәдәният вә фәнният» (1913), «Тарихе ислам атласы» (1913), «Мосаувәр тарихе ислам» (1 кисәк 1913; 2 кисәк 1918), «Тарихе ислам». 1 кисәк (1916), «Ибтидаи мәктәпләрдә кул эшләре» (1918), «Әвәләү эшләре» (1931), «Кәгазь эшләре» (1931), «Мәктәпкәчә тәрбия җитәкчеләренә һәм беренче баскыч мәктәп укытучыларына сынлы сәнгать эшләреннән кулланма» (1931), «Декоратив эшләре» (1932), «Рәсем эшләре» (1932), «Катыргы эшләре. Тартмачылык һәм китап төпләү эшләре» (1932) кебек хезмәтләре басылып чыга.

1928–1938 елларда ул Казан татар педагогия техникумында физика һәм рәсем сәнгатен укыта, читтән торып һәм кичке уку бүлекләренең мөдире буларак, аларны оештыру эше белән шөгыльләнә. Шулай ук 1938–1940 елларда Молотов районының 38 номерлы (Казан шәһәренең хәзерге Совет районы) урта мәктәбендә физика, химия һәм кул хезмәте дәресләрен алып бара. Татар педагогия институтында (кул хезмәте буенча мөгаллим), Совет партия мәктәбендә һәм Татар халык мәгарифе кадрларының квалификациясен күтәрү институтында һәм төрле кыска вакытлы педагогик курсларда белем бирә.

1940–1941 елларда яңадан Хива шәһәре педагогия училищесына читтән торып уку буенча завуч һәм укытучы сыйфатында эшкә җибәрелә.

1941–1943 елларда Яшел Үзән районындагы Олы Карагуҗа авылында завуч һәм укытучы булып эшләп ала.

Химик приборлар белән эш итү кагыйдәләрен яхшы белүе аркасында, 1943–1945 елларда «Динамо» кибетенең сәүдә залында склад мөдире һәм махсус милек буенча методист вазиваларын башкара [1: 87].

1946 елның 10 маеннан ул Казан университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегенә мөдир итеп куела. Гарәп, фарсы, төрек, үзбәк, азәрбайҗан, казах, башкорт, төрекмән һәм уйгур телләрен яхшы белгән С. Камал фәнни хезмәткәрләргә, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы аспирантлары һәм өлкән курс студентларына китапханәдә сакланган кульязмаларны, сирәк китапларны укуда һәм өйрәнүдә һәрдаим методик ярдәм күрсәтә, консультацияләр бирә. Аның КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә язган хаты игътибарга лаек: ул беренчеләрдән булып китапханәдәге иске имла белән язылган мирастан, тарихи документлардан галимнәрнең иркен файдалана алуын тәэмин итү өчен, яңа гына оешкан татар бүлеге студентларына борынгы татар телен һәм язуын гамәли юнәлештә өйрәтүне кертергә тәкъдим итә. Әлеге фикер бүенге көндә дә актуаль.

1951 елда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире Рабига Хәкимова соравы буенча, С. Камалга, Көнчыгыш телләрен яхшы белүен күздә тотып, XI–XIV гасыр гарәп кульязмаларын тәрҗемә итү эше йөкләнә. Ул М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрек» сүзлеген тикшереп, аны татарчага тәрҗемә итә һәм 3 том итеп туплый [1: 40]. Фәнни китапханәдә эшләү дәверендә аның тарафыннан 5410 берәмлек кульязма фонды тикшерелә һәм системага салына [4: 135]. Хәзерге көнгә кадәр кулланылышта йөргән картотеканы һәм гарәп телендә язылган хатларны нәкъ менә ул тәртипкә сала. Алар арасыннан Иске Шәйморза авылының 1 нче Җамигъ мәчете имамы Мөхәммәт Габдеррәшитовның хатларын аерып бирә. Шулай ук күренекле галимнәребез Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Г. Чокрый, Х. Габәши кульязмалары, фольклор материаллары һәм XVIII–XX гасыр башы татар әдәбияты кульязмалары тасвирлана һәм тәртипкә китерелә.

Сәлах Камал 1954 елның 15 февралендә эш өстәле артында вафат була.

Галимнең Әбүгалисина, Насретдин Туси, Әбүнәсыйр Мөхәммәд әл-Фәрабига һ. б. багышланган мәкаләләренең төрле караламалары һәм «Беренче карлыгач. Мөрәббияләргә юлбашчы» исеме астында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә тәрбияләү, кул эшләренә өйрәтү өчен тәрбиячеләр, ата-аналар өчен кулланма буларак төзелгән дидактик әсәренең кульязмасы, гомумән, инкыйлабка кадәр һәм аннан соң басылган барлык хезмәтләре КФУның Фәнни китапханәсендә саклана.

С. Камалның «Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре» исемле хезмәте бүген кульязма хәлендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәге архивында Сәлах Камал

фондында, 24 саклау берәмлеге астында теркәлеп саклана. Ул 1945–1946 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелеге соравы буенча языла, мәдрәсәләр тарихы аеруча киң яктыртылган, мәдрәсә тормышының күп кенә нечкәлекләрен тасвирлаган хезмәтләрнең берсе булып тора [7: 5]. Ул ниндидер бер мәдрәсә тарихын сурәтләми, гомуми тарихка мөрәҗәгать итә. Әлеге хезмәттә китерелгән материалларның фактик кыйммәте гаять зур. 2024 елда ул Язма мирас үзәге галимнәре тарафыннан басмага әзерләнеп, «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясендә дөнья күрде.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, С. Камалның мәгариф өлкәсенә керткән өлеше гаять зур. Аның күпсанлы уку-укыту кулланмаларын, дәреслекләрен, вакытлы матбугат битләрендә басылган мәкаләләрен һәм тарихи хезмәтләрен үз эченә алган иҗади мирасы бүген дә әһәмиятен югалтмый һәм алга таба өйрәнүне таләп итә. Күп еллар буе күләгәдә калып килгән галим тарихта үзенең лаеклы урынын алырга тиеш.

**Әдәбият**

1. Казан (Идел буе) федераль университеты архивы, хезмәткәрнең шәхси эше тасв. 3, сакл. бер. 254а.

2. *Камал С.* Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре / төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, А.Н. Хәсәнова. Казан: ТӘһСИ, 2024. 160 б. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 25 нче чыг.).

3. *Камал С.* Ибтидаи мәктәпләрдә кул эшләре. Минзәлә: Минзәлә Мөселман мәгариф комиссариаты, 1918. 43 б.

4. Научная библиотека Казанского университета в лицах. Ч. 1. Сотрудники библиотеки, 1806–2007 гг. / сост.: В.И. Шишкин, Ж.В. Щелыванова. Казань: Казан. ун-т, 2011. 424 с., 8 л. ил.

5. *Рахимкулова М.Ф.* Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. 2-е изд. Оренбург: Ред. газ. «Яна Вакыт», 1997. 250 с. фот.; 20.

6. *Усманов В.* Исторические памятники. Древние мусульманские надгробные камни города Оренбурга. Оренбург, 2013. 364 с.

7. *Хәсәнова А.Н.* С. Камал һәм аның «Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре» хезмәте турында // Камал С. Борынгы татар мәктәп-мәдрәсәләре / төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, А.Н. Хәсәнова. Казан: ТӘһСИ, 2024. Б. 5–6. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 25 нче чыг.).

***Хәсәнова Айгөл Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының*
*Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

***Хасанова Айгуль Наиловна,***
*научный сотрудник Центра письменного наследия*
*Института языка, литературы и искусства*
*имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*dream8708@mail.ru*

УДК 82.091(051.2)

***Н.Р. Вахитов***

## «ТӨРЕК ДӘРНӘГЕ» (1911–1912) МӘҖМУГАСЫНДА ТАТАР ӘДИПЛӘРЕНЕҢ МӘКАЛӘЛӘРЕ

Данная статья посвящена историко-литературному анализу публикаций татарских интеллектуалов в османском журнале «Тюркский союз» («Төрек дәрнәге»), который издавался в Стамбуле в 1911–1912 годах под идейным руководством Юсуфа Акчуры. Исследование анализирует его центральную миссию: научное оформление и популяризацию идеологии тюркизма посредством изучения истории, языка и культуры всех разрозненных тюркских народов. Особое внимание уделяется статьям интеллектуалов, прибывших из Российской империи. Муса Акъегетзаде опубликовал «Пословицы на казанском татарском диалекте». Эта работа рассматривается как призыв к сравнительному лингвистическому анализу, направленному на укрепление межтюркских культурных связей. Гаяз Исхаки представил «Очерк истории татарской литературы», где предпринята одна из первых попыток периодизации татарского литературного процесса, охватывающего период с момента падения Казанского ханства (1552 г.) до начала XX века. В заключении подчеркивается ключевое значение журнала «Тюркский союз» как платформы, на которой российские тюркские народы были впервые интегрированы в общеосманский культурный и политический дискурс тюркизма, что способствовало их взаимному познанию и сближению.

**Ключевые слова:** «Тюркский союз» («Төрек дәрнәге»), Юсуф Акчура, Муса Акъегетзаде, Гаяз Исхаки, тюркизм, периодизация татарской литературы, пословицы, реформа языка.

This article presents a historical and literary analysis of the publications by Tatar intellectuals in the Ottoman journal “Türk Derneği” (Turkish Union), which was published in Istanbul between 1911 and 1912 under the ideological leadership of Yusuf Akçura. The research contextualizes examines its central mission: the scholarly formulation and popularization of the ideology of Turkism through the study of the history, language, and culture of all fragmented Turkic peoples. Particular attention is paid to the articles contributed by intellectuals arriving from the Russian Empire. Musa Akyigitzade published “Proverbs in the Kazan Tatar Dialect”. This work is viewed as a call for comparative linguistic analysis. Ayaz İshaki presented “An Outline of the History of Tatar Literature”. His article undertook one of the first attempts at periodization of the Tatar literary process, covering the era from the fall of the Kazan Khanate (1552) to the beginning of the 20th century. In conclusion, the key significance of the journal “Türk Derneği” is underscored as the platform where Turkic peoples from Russia were first integrated into the pan-Ottoman cultural and political discourse of Turkism, thereby promoting mutual understanding and rapprochement.

**Keywords:** Türk Derneği, Yusuf Akçura, Musa Ayigitzade, Ayaz İshaki, Turkism, periodization of Tatar literature, proverbs, language reform.

Русиядә реакция ныклап тамыр җәя барган бер чорда, 1908 елның көзендә Госманлыда II Мәшрутият (конституцион монархия) дәвере башланып китә. Нәкъ шушы чорда Истанбулга килгән Йосыф Акчура

үзенең күптәнге идеалларын («төрекчелек») тормышка ашыру эшенә керешә. Хөррият җилләре искән шушы көннәрдә бер-бер артлы төрле җәмгыятьләр, оешмалар, берлекләр корыла башлый. Йосыф Акчура җитәкчелегендәге бер төркем зыялылар «төрекчелек» мәсләгенең беренче оешкан формасы – «Төрек дәрнәге» җәмгыятенә нигез салалар. 1909 ел башында «Сыйрател мөстәкыйм» мәҗмугасында җәмгыятьнең 21 маддәлек низамнамәсе дә басылып чыга. Беренче маддәдә үк «фәкать гыйлем белән шөгыльләнгән бер җәмгыять» икәнлеге белгертелгән «Төрек дәрнәге»нең максаты: «Төрек исеме белән аталган бөтен кавемнәрнең үткәндәге һәм хәзерге әсәрләрен, эш-хәлләрен һәм яшәгән мохитләрен өйрәнү вә өйрәтү, ягъни төрекләрнең борынгы әсәрләрен, тарихын, телләрен, һәртөрле гыйлемнәрен вә әдәбиятын, этнография һәм этнологиясен, иҗтимагый хәлләрен һәм хәзерге мәдәниятләрен, төрек мәмләкәтләренең иске вә яңа географияләрен төпченеп көн яктысына чыгару, бөтен дөньяга таныту; шулай ук телебезне ачык, садә, гүзәл гыйльми тел булырлык дәрәҗәгә җиткерү һәм имласын да шуңа муафикъ итеп төзү» – дип игълан ителә.

1911 елда җәмгыять әгъзалары тарафыннан «Төрек дәрнәге» исемле айлык мәҗмуга нәшер ителә башлый. Ләкин Йосыф Акчураның фикри җитәкчелегендә чыккан бу мәҗмуга озын гомерле булмый. 7 саны чыкканнан соң, 1912 елда оештыручы үзәге таркалу сәбәпле, тукталып кала. Шулай да бер кабынган учак сүнми. «Төрек дәрнәге»ндә бөреләнгән идеология артабан шул ук зыялылар тарафыннан «Төрек йорты» һәм «Төрек учагы» кебек җәмгыятьләр эшендә, бигрәк тә Йосыф Акчураның тагын бер мактанычы – «Төрек йорты» мәҗмугасында ныклап торып үстерелә, тармаклана.

«Төрек дәрнәге»нең беренче санында басылган 14 маддәлек «Бәяннамә» (декларация)дә белдерелгәнчә, җәмгыятьнең һәм аның нашире әфкяре булган мәҗмуганың иң төп максатларының берсе сибелеп яшәгән төрек кавемнәрен бер-берсе белән таныштыру («Чувашлар» З. Бәшири, «Турфанда археологик табышлар» Н. Гасыйм, «Төрекмән җирендә...» М.Әмин), бер-берсенә якынайту, үзара аңлашып яшәрлек дәрәҗәгә җиткерү булганлыктан, төрки телләрнең тарихы, борынгы уртак әдәбияты («Солтан Вәләд хәзрәтләренең төрекчә шигырьләре», «Төрекчә гаруз», «Татар әдәбиятының тарихчасы»), иске лөгать китаплары (Ибн Мөһәннә сүзлеге), имла кагыйдәләре, тел-алфавит реформасы («Төрки теленең язуын ислах кылу, имлясын эшләп чыгару...», «Төрекчәдә хәзергә кадәр кулланылган имла кагыйдәләре», «Төрекчәне садәләштерү», «Телебез», «Төрек саннары», «Госманлы төрекчәсендә басым», Аһәң (сингармонизм) кануны», «Яңа язма һәм әлифбасы», «Тасвиры әфкяр һәм әлифбабыз») кебек темаларга аеруча зур урын бирелә. Оешып җиткән редакциясе, даими хезмәткәрләре булмау сәбәпле күбрәк гыйльми-әдәби альманахны хәтерләткән мәҗмугада «Төрек дәрнәге» җәмгыятенең төрле декларацияләре («Төрек дәрнәге бәяннамәсе», «Төреклекне танып-белү тиеш», «Җәмгыять әгъзалары исемлеге», «Төрек дәрнәге рәсми теркәлү узды», «Шөгъбәләребезгә»), кечкенә күләмле әдәби әсәрләр, күренекле азәрбайҗан

зыялысы Мөхәммәд Әминнең ялкынлы публицистик мәкаләләре («Мәгариф җәлладларына!», «Син зар елый башлауга..»), госманлы энциклопедисты Бурсалы Мөхәммәд Таһирның әдәби биографик очерклары («Гашыйк паша», «Хибри Гали әфәнде»), Франция ориенталисты Бернар Кара де Воның Италиядә табылган этруск язмалары турындагы мәкаләләр циклы һәм башка күп кенә публикацияләр, шул исәптән, татар зыялыларының, Русия шәркыятчыларының да күзәтү-таныту характерындагы берничә мәкаләсе басылып чыга. Болар:

1. Акъегет улы Муса. Казан татар шивәсендә мәкальләр. (№ 2)
2. Владимир Гордлевский. Мәшһүр рус шәркыятчыларыннан Радлов. (№ 3).
3. Казанлы Гаяз. Татар әдәбиятының тарихчасы. (№ 5)
4. Йосыф Акчура угылы. Яңа табылган иске бер төрек шәһәре. (№ 5)
5. Русияле мишәр угылы Зариф Бәшири. Чувашлар I. (№ 7)
6. Радловның юбилее. «Төрек дәрнәге». (№ 1)

**Муса Акъегет. Казан татар шивәсендә мәкальләр.**

Мәҗмуганың 2 нче санында Муса Акъегетнең «Казан татар шивәсендә мәкальләр» исемле җыйнак кына язмасы урын алган. Мәкалә Пешт каласында басылган «Казан татар мәкальләре» китабыннан алынган бер мисал үрнәгендә мәкальләрнең тарихи-мәдәни кыйммәте, төрки халыклар арасындагы тыгыз бәйләнешне күрсәтү җәһәтеннән әһәмияте бәян ителә.

Муса Акъегет XX гасыр башында ук аерым төрки телләрне, диалектларны өйрәнү кирәклеген күтәреп чыга. Чагыштырма анализ ярдәмендә бу телләрнең үсеш-үзгәреше, үзара мөнәсәбәтләре, бер-берсенә йогынтысын ачыкларга өнди.

**Гаяз Исхакый. «Татар әдәбиятының тарихчасы».**

Мәҗмуганың 5 нче санында Гаяз Исхакыйның «Татар әдәбияты тарихчасы» исемле күзәтү-таныту характерындагы мәкаләсе урын алган. Бу – әдипнең сөргеннән качып, Истанбулга килгән чоры. 1909–1911 елларда ул «Сыйрател мөстәкыйм», «Сәнин» кебек башка матбугат органнарында да тел мәсьәләсе, Русия татарлары, милли әдәбият (хикәя-шигырь), театрның шул дәвердәге хәле турында мәкаләләр бастырып чыгара. [«Тел мәсьәләсе», Сыйрател мөстәкыйм (1909); «Тел мәсьәләсе турында», Сыйрател мөстәкыйм (1909); Русия мөселманнары: татарлар, Сыйрател мөстәкыйм (1909); «Шималь төрекләренең яңа әдәбиятында хикәя, театр вә шигырь», Сәнин (1911)] «Төрек дәрнәге» ндә басылган язмада 1552 елда дәүләтен җуйган мәлдән башлап XX йөз башларына кадәр татар әдәбиятының язмышына кыскача күзәтү ясала. Гаяз Исхакый татар әдәби тәнкыйтендә беренчеләрдән булып әдәби процессны чорларга бүлеп анализлый.

Мәкаләнең исеменнән дә күренгәнчә, Гаяз Исхакый Идел-Урал буе, Себер һәм, гомумән, эчке Русия җирләрендә таралып гомер иткән халыкның әдәбиятын бөтен төрек галәменә «татар әдәбияты» дип таныта.

Шушы ике мәкаләнең госманлы төрек теленнән хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсен тәкъдим итәбез.

**Казан татар шивәсендә мәкальләр**

Иҗтимагый, кауми, җәгърафи, тарихи һәм башка 5–10 төрле ноктаи нәзардан галәм хәлләрен тикшереп, аннан кешеләргә файдалы нәтиҗәләр чыгару өчен, мәдәниятле илләрнең һәрберсе берәр фән тармагына хезмәт итү нияте белән күпләгән гыйльми җәмгыятьләр булдырган бер чорда, һәркайсы үзенә муафикъ берәр мәсләк сайлаган галим-голәма сыйныфы да, гомум инсаният өчен файдалы казанышларга ирешеп, җиһанның гыйлем вә мәгърифәт хәзинәсен көннән-көн баетып киләләр.

Ошбу эзләнү вә тикшеренүләр җөмләсеннән «Төрек җәмгыяте» өчен иң файдалы вә мәсләгенә иң ярашлы булганы – мисье Фозет тарафыннан Пешт каласында нәшер ителгән «Казан татар мәкальләре» исемле бибаһа әсәрдер. Төрек теле шивәләренә кагылышлы әсәрләрне аеруча кыйммәтле һәм әһәмиятле иткән нәрсә исә – ул шивәләрнең төрек кавемнәре арасындагы бәйләныш вә мөнәсәбәтләрне күрсәтеп килүләрендә, әйтергә яраса, төрекләрнең тел җәһәтеннән ни төсле үзгәрешләр кичергәнлеген бәян итүләрендә.

Төрекчәнең үсеш-алгарышы да теләсә кайсы телнең үзгәреше кебек үк мәдәни аландагы тәрәккыйга бәйле һәм мәгънәне төгәлрәк вә тулырак аңлату ихтыяҗы сәбәпле барлыкка килгән киңәюдән, колач җәюдән гыйбарәттер. Шушы уңайдан, бер телнең үсеше мисалында барча телләр өчен уртак булган камилләшү канунын ачыклап килгән бик күп яңа материал китерергә мөмкин.

Инде мәкальләрнең үзләренә килсәк, Казан шивәсендәге һәрбер мәкальнең үзгә кавемнәрдәге сыңарлары кебек үк, меңьеллык тормыш тәҗрибәсеннән алынганлыгы аермачык күренеп тора.

Мәкальләрне атадан угылга, буыннан буынга күчеп килгән һәм тормышның ачы-татлы тәҗрибәләрен үз эченә алган хакыйкатьләр дип карарга кирәк. Бу хосус мәкальләрнең барысы өчен дә уртак. Асыл максатыбыз исә төрек кавеменең бер ботагы булган татарларның мәкальләрен тикшерүдән гыйбарәт. Беренче мәкалебез:

«Авылыңда ни барын башка авылдан сора, өеңдә ни барын күршедән сора».

Бу мәкальне яхшылап тикшереп карасак, иң элек казанлы бер татар белән сиваслы бер төрек арасында каумият җәһәтеннән берлек барлыгын күрәбез. Моңа тел-лөгать анализы ярдәмендә ирешәбез. Тел анализы нәтиҗәсендә ачыкланган хакыйкать исә ике икең дүрт булган кебек катгый дәлил исәбендә йөри. Мәкальнең башындагы «авыл» сүзе – иске төрекчә бер сүздер. Кыргыз вә Казан шивәсендә «köy» мәгънәсен белдерә. Иске төрекчәдә дә мәгънәсе шул. Бу хәлдә «авылыңда» тәгъбиреннән «senin köyünde» мәгънәсе чыгадыр. «Ни» «ne» дигәнне аңлата. Бу ике сүз арасында аерма юк диярлек. Казанлылар «ни» дип сөйләгәнне, госманлы төрекләр «ne» дип әйтәләр. Бу ике сүзнең бер үк кавемгә хас икәнендә бернинди шик булмаса кирәк. Шулай итеп, «köyünde ne» мәгънәсе хасил булды.

Бүген казанлыларның бер ише «вар» дип сөйләшәләр, кайсылары исә (б) авазы белән «бар» диләр. Икесендә дә мәгънә бер үк. «Ни барын» – «ne varı», ягъни «ne var, ne yok» икәнен белдерә. «Башка авылдан сора» дигәне «başka köyden sor» икәнлеге өстәмә аңлатуга мохтаҗ түгел.

Авылыңда ни барын башка авыллардан сора, үз авылдашларыңнан түгел.

«Өеңдә ни барын күршеңнән сора» җөмләсенең мәгънәсе дә күз алдында. Монда тик «күрше» сүзенә генә бераз аңлатма биреп китү кирәктер. «Күрше» – «күреш-» (күрешмәк) тамырыннан килә. Иң еш күрешелгән кеше кем булыр? Билгеле инде «komşu» булыр. Аннан да ешрак кемне күрәбез тагын? Димәк, Казан шивәсендә күрше – «komşu була. Шул рәвешле, «өеңдә булганны күршеңнән сора» мәгънәсе аңлашыла. Мәкальнең тулаем мәгънәсе: «Köyünde olanı başka köye sor, evinde olanı komşuya sor» булып чыга.

*Акъегет улы Муса*
*Төрек дәрнәге. 1911. № 2. Истанбул*

**Татар әдәбиятының тарихчасы**

1552 милади елында, руслар Казан ханлыгын идарәләре астына алган чакта, татарларның әдәбияты ни дәрәҗәдә булганы мәгълүм түгел. Руслар Казанның күпчелек голәмасын кылычтан үткәргәнгә, мәдрәсәләрен, мәчетләрен хәрабә хәленә китергәнгә һәм Казанның барча мөселман халкын шәһәрдән сөреп чыгарганга, боларның мәдәнияте вә әдәбияты хакында бүгенгә кадәр ышанычлы тарихи документлар табылганы юк. Гаскәре, сәүдәсе һәм мәдәнияте булган бер милләтнең үзенә күрә бер әдәбиятының булуы да табигыйдер.

Татарлар гыйлем эстәү нияте белән Бохара якларына сәфәр кылалар һәм шунда алган мәгълүматлары белән милләттәшләрен агарту юлына басалар. Бохарадан тәсаувыфка һәм дингә кагылышлы китаплар алып кайталар. Зыялы даирәләрдә Бохара ысулы дин белеме җәелгән шикелле, гади халык арасында да Бохарадан китерелгән «Сөбәтел гаҗизин», «Морадел гарифин» вә «Өстевани» кебек китаплар күренгәли башлый.

Бу китаплар язма нөсхәләр хәлендә йөргәнгә, аларның таралышы бик чикле даирәдә кала. Халык исә ачык аңлаешлы тел белән язылган баһадир хикәяләре, «Хан кызы» кыйссалары белән юанып яши.

XIX гасырның башында Казанда тәүге мәртәбә «Азия матбагасы», гарәп хәрефләре китертеп, Казан байларының булышлыгы белән Изге Коръәнне бастыра. Шушы вакыттан башлап, татарларның әдәбияты яңа дәвергә керә. Әкренләп матбага эше алга китә. Коръәннән башка дин китаплары, догалыклар, тылсымнар басыла башлый. Бераз соңрак Язычы угылы Мөхәммәднең «Мөхәммәдия» исемле шигырь диваны нәшер ителеп, иске төрек шигырьләре тарала. Торабара баһадир хикәяләре, пәйгамбәр, әүлия кыйссалары нәшер ителә. Китап сәүдәсе җәелеп китә. Сәүдәгәрләр Истанбул, Мисыр, Һинд илләре белән эш итәргә тотына. Бу гасыр китапларының барысы да

иске чыгтайча. Язуы госманлыча булганга, боларның күбесен халык рәтләп аңлап җиткерми иде. Шуңа күрә халык аңлаган телдә китаплар нәшер итү табигый бер ихтыяҗ булып килеп басты. Бу хәрәкәт XIX гасырның беренче яртысының ахырларына таба башланып китте. Иң әүвәл Рәхмәтулла Әмирханов исемле бер зат 1841 елда кырык еллык бер рисалә нәшер итте, аннан соң Габдрахман Ильяс угылы татар тормышы турында берничә рисалә бастырды. Ләкин халкыбыз ул чорда мондый хезмәтләрнең кадерен белмәгәнгә, яз фасылында мәйданга чыккан шушы әдәбият чәчәкләребез җаһиллек караңгылыгында шиңде. Беренче мөхәрриребез фәкыйрьлек вә юксыллык сәбәпле үпкә чиренә бирешеп, әдәбият галәменнән читләшергә мәҗбүр булды. Габдрахман урынына бөек мөхәррирләребездән Габделкаюм Насыйри әфәнде кичте. Бу зат хәлебезнең мөшкеллеген яхшы белгәнгә һәм котылу юлының Яурупа мәдәниятен кабул итүдә икәнлегендә шөбһәсе булмаганга, татар теленә урысчадан фәнни рисаләләр тәрҗемә итәргә, дәрес китаплары язарга, ел саен календарьлар бастырып таратырга тотынды. Ләкин моның хезмәте тәнкыйть ителгәнгә һәм голәмабыз арасында абруе булмаганга, кырык еллык әдәби эшендә һичбер вакыт мантымады, һичбер вакыт үзенең бөек хыялларын халыкка төшендерә алмады. Бу олуг мөхәрриребез дә язган әсәрләре белән тулы китапханәсен калдырып, фәкыйрьлек вә мескенлек эчендә вафат булды.

Габделкаюм Насыйри язган әсәрләр гаять күп булып, хәзергә боларның һәммәсен санап төшү өчен кулымда җитәрлек мәгълүмат булмаганга, иң әһәмиятлеләренә генә туктылып узам. Җәгърафия, тарих, зоология, ботаника, геология, геометрия, хисап, физика хакында аерым-аерым китаплары булган кебек, әхлактан да берничә китабы, балалар өчен уку китаплары, әлифбалары бар иде.

Моннан башка татар әдәбиятының бөтен үрнәкләрен туплаган (Фәвакиһел җөләса) исемле китабы бардыр ки, бу китапта әдәбият, шигырь, хикәя, иске кыйссалар, халык җырлары, мәзәкләре җыеп бирелгән, барысы да бик яхшы сурәттә язылган.

Габделкаюм Насыйри – телебез өчен зур хезмәт башкарган адәмнәребездәндер. Ул калдырган (Ләһҗәи татари) исемле лөгать китабы безнең әдәбиятыбызның иң беренче олы әсәре икәнендә шөбһә юк. Бу зат никадәр әсәрләр калдырган булса да, язган теле гәрчә татар теле исә дә, өслүб җәһәтеннән бик аңлаешсыз язганга һәм иске чыгтай ысулыннан аерыла алмаганга, бу мөхәрриребезнең әсәрләре әдәбиятыбызга үрнәк булачак дәрәҗәдә түгел иде. Бу сәбәптән татар әдәбиятының мөстәкыйль бер юлдан хәрәкәт итүе һәм татар теленең әдәби тел булып китүе өчен хикәяләр, новеллалар, хәтта романнар язган мөхәррирләргә вә шагыйрьләргә ихтыяҗ бар иде. Табигый булarak бу мөхәррир вә шагыйрьләр тырышлыгы белән татар теле ислах ителеп, татар әдәбияты мәйданга киләчәк иде...

«Йосыф», «Кисекбаш», «Ахырзаман», «Тутыйнамә», «Фәзаилешшөһүр», «Сөбателгаҗизин», «Сәйфелмөлек», «Мөхәммәдия» вә шуңа охшаш китаплар гасырыбызның башлыча әдәби әсәрләре иде.

Бу китаплар баһадирларның хикәяләреннән гыйбарәт булганга яки суфиларның әхлагын өйрәтү өчен язылганга, табигый инде, укучыларының зиһеннәрен иске гасырларга таба юнәлтеп, иске гасырларны күз алдына китереп бастыра иде. Яисә аларны суфилар мәйданына ташлап, чынбарлыкка тулаем капма-каршы булган бер хыял галәменә күчерә, шул дөньяда яшәтә һәм аларга башка галәмдә сәгадәтләр вәгъдә итә иде.

Яшәгән мохитләре китапларда укыган тормышка бер дә охшамаганга, хәятлары табигать белән һич тә яраша алмаганга, әдәбият күрсәткән суфи әхлагын гамәлгә ашыру мөмкин булмаганга, тормыш белән әдәбият арасында зур каршылык бар иде. Нәтиҗәдә, укучылар әдәбиятны аңламады, әдәбият аларга юл күрсәтүче була алмады.

Габделкаюм Насыйри да әдәбият белән тормыш арасындагы бу каршылыкны җиңә алмаган, хәят белән әдәбият арасындагы бушлыкны тутырудан гаҗиз калган иде. Тормышыбыздагы төрле мәсьәләләр һәрдаим җавап көткәнгә, хәятыбыз мохитебез булган Русия хәятына ияреп яурупалашуга таба йөз тотканга, шушы яшәешебездән алып язылган әсәрләргә зур ихтыяҗ бар иде.

Ул чорга кадәрге тормышыбыз буталчык, чуалчык булганга һәм укымышлы сыйныф иске әдәбият тәэсире астында яшәп, бөтен яшәешебезне иске тарафка борырга тырышканга, табигый инде, иске хәят һәм аның тарафдарлары белән яңа хәят вә тарафдарлары арасында каты низаглар, гаугалар, талашлар булачак иде. Вә табигый буларак яңа хәят тарафдарлары иң башта иҗтимагый фикеребез юлбашчылары булган дин голәмасы белән бәрелешкә керәчәк һәм аларның тормышкөнкүрешләрен, гадәт-йолаларын тәнкыйть итәчәк вә психологияләрен чеметергә, хәтта мыскыллап көләргә тотыначак иде. Чыннан да шулай булып чыкты. Татар әдәбиятының икенче дәвере тормышыбызны тәнкыйтьтән, аерым алганда голәма сыйныфына һөҗүмнәрдән башланып китте. Бу дәвердә әдәбиятыбызның психологиясе тел вә мәсләк җәһәтеннән әүвәлге дәвергә бер дә охшамаганга, шушы чордан башлап татар әдәбияты мөстәкыйль бер әдәбият хәлен алгандыр. Бу дәвер хакындагы фикерләребез башка бер мәкаләдә ачыкланачак.

*Казанлы Гаяз*
*Төрек дәрнәге. 1911. № 5. Истанбул*

*Басмага әзерләде:*

***Вахитов Наил Ринат улы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*

*К печати подготовил:*

***Вахитов Наиль Ринатович,***
*аспирант Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*bigey4052@gmail.com*

УДК 821.512.145

***Э.И. Сафина***

# ЯҢА «РУСЧА-ТАТАРЧА СҮЗЛЕК»КӘ БӘЯЛӘМӘ (авторы Ф.Ф. Гаффарова; Казан, 2025. 655 б.)

В рецензии представлен анализ «Русско-татарского словаря» Ф.Ф. Гаффаровой на уровне макро- и микроструктуры. Особое внимание уделяется микроструктуре словарных статей: переводным эквивалентам, которые в необходимых случаях уточняются с помощью кратких пояснений и толкований, и способам подачи иллюстративного материала, что наглядно демонстрируется на конкретных примерах. К ключевым достоинствам издания отнесены богатый иллюстративный материал, обилие примеров употребления слов, а также включение религиозной лексики. Эти особенности делают словарь ценным справочным пособием для учеников, студентов, а также для широкого круга пользователей, самостоятельно изучающих татарский язык.

**Ключевые слова:** лексикография, русско-татарский словарь, переводные словари, терминология, двуязычные словари.

The review analyzes F.F. Gaffarova’s “Russian-Tatar Dictionary” at both the macro- and microstructural levels. Particular focus is placed on the microstructure of dictionary entries, examining translation equivalents (which are clarified, where needed, with brief explanations and interpretations) and the methods of presenting illustrative material, as demonstrated with specific examples. Key strengths of the publication include its rich illustrative content, numerous examples of word usage, and the inclusion of religious terminology. These features make the dictionary a valuable reference resource for schoolchildren, students, and a broad audience of independent Tatar language learners.

**Keywords:** lexicography, Russian-Tatar dictionary, translation dictionaries, terminology, bilingual dictionaries.

Татар лексикографиясендә русча-татарча сүзлекләр төзелүнең бай тарихы бар. XV гасырга караган беренче кулъязма русча-татарча сүзлекләрдән алып бүгенге көндә басыла торган заманча лексикографик чыганакларга кадәр йөзләгән сүзлек дөнья күргән. Алар арасында бер үк авторлар төзегән сүзлекләрнең кат-кат бастырылганнары да, бер тапкыр гына нәшер ителгән хезмәтләр дә җитәрлек. Тәрҗемәле сүзлекләрнең даими төзелеп һәм басылып торуы мондый төр хезмәтләргә ихтыяҗ зур булуны күрсәтә. Соңгы ике дистә елда гына да үткән гасырда төзелгән русча-татарча сүзлекләрнең берничә тапкыр басылуы (2000; 2001; 2003; 2009; 2014) шуны дәлилли. 2018 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре эшләгән ике томлы, 2024 елда бер томлы «Русча-татарча сүзлек»ләр дә кулланучылар тарафыннан бик көтеп алынды.

Әлеге хезмәтләр исемлеген тулыландырып, күптән түгел тагын бер яңа сүзлек дөнья күрде. Ф.Ф. Гаффарова төзегән «Русча-татарча сүзлек» биш меңданәдә «Милләт» нәшриятында басылган. Сүзлек

турындагы мәгълүматта күрсәтелгәнчә, беренче чиратта ул мәктәп укучылары, студентлар һәм татар телен үзлектән өйрәнүчеләр, шулай ук рус телендәге текстларны татар теленә тәрҗемә иткәндә куллану өчен төзелгән.

Белешмәлек сүзлекнең төзелеше, сүз төркемнәренең ничек бирелеше һ. б. турында җентекле мәгълүмат белән башланып китә, аннан шартлы кыскартылмалар, рус алфавиты китерелә. Библиография өлешендә рус һәм татар теленең төп аңлатмалы сүзлекләре, русча-татарча һәм татарча-русча кайбер сүзлекләр бирелә. Кызганыч, анда соңгы елларда басылып чыккан русча-татарча сүзлекләр (РТС, 2018; РТС, 2024) күрсәтелмәгән.

Сүзлекнең лексик материалы хәзерге әдәби телгә нигезләнгән. Лөгатьлек киң кулланылыштагы сүзләрдән, көндәлек тормышта, төрле чараларда кирәк булырга мөмкин әйтелмәләрдән, берәмлекләрдән гыйбарәт. Моннан тыш, соңгы елларда дингә килүчеләрнең (бигрәк тә яшьләрнең) артуын күздә тотып булса кирәк, ислам диненә кагылышлы күп кенә сүзләр кертелгән.

Хезмәт русча-татарча сүзлекләргә хас структурага ия. Башта калын хәрефләр белән баш сүз, аннан грамматик һәм стилистик характеристикалар һәм сүзләрнең тәрҗемәсе, кулланылыш үрнәкләре китерелә. Төрләнгәндә төп өлеше үзгәрә торган сүзләрдә параллель сызыклар кулланыла.

Сүзлекнең кулланучылар өчен уңайлы ягы – җәяләр эчендә аңлатма буларак китерелгәннәреннән тыш, рус телендәге барлык сүзләргә дә басым куелган. Сүз төркемнәренең бирелеше, нигездә, башка русча-татарча сүзлекләрдәге кебек. Сүзләрнең вариантлары төп сүзгә җибәрелә. Мәсәлән, **дава́ть** *несов. см.* **дать**; **ка́к-либо** *нареч. см.* **ка́к-нибудь**; **карто́шка** *ж. разг.* **карто́фель**.

Татар телен үзлектән өйрәнүчеләрне күз уңында тотканлыктан, хәтта гади сүзләрдән соң да аралашу барышында кулланыла торган сүзтезмәләр, җөмләләр китерелә. Мәсәлән, **вечер** сүзеннән соң *добрый вечер!* хәерле кич! *по вечерам он бегал в парке* кичләрен ул паркта йөгерә иде, *музыкальный вечер* музыкаль кичә һ. б. Башка сүзлекләрдә тәрҗемәсез калган сүзләргә эквивалентлар бирү (орнамент – *нәкышь*, газон – *үләнлек*, гид – *экскурсия йөртүче* һ. б.) яисә уңышлырак вариантлар тәкъдим итү шулай ук сүзлекнең уңай ягы булып тора. Мәсәлән, **вечерний** сүзенең икенче мәгънәсе – предназначенный для вечера – *бәйрәм ...ы* дип тәрҗемә ителә. Башка икетелле сүзлекләрдәге «*кичке, кичә ... ы*» (*кичке күлмәк, кичке костюм*) тәрҗемәсе белән чагыштырганда, *бәйрәм күлмәге, бәйрәм костюмы* дию чынлап та уңышлырак кебек.

Сүзлек сигез меңгә якын сүзнең тәрҗемәсен бирә. Тәрҗемәдән тыш, татар сүзләренең нечкәлекләрен аңлату өчен, барлык күпмәгънәле сүзләргә җәя эчендә кыскача аңлатмалар китерелә:

**ка́ша** *ж.* 1) (*кушанье из крупы*) ботка; 2) *перен. разг.* (*путаница в мыслях*) буталчыклык, тәртипсезлек.

Бер мәгънәле сүзләргә аңлатмалар китерелгән очраклар да бар. Андыйлар, нигездә, гади кулланучыга аңлашылып бетмәгән сүзләргә яисә алынмаларга кагыла. Шул исәптән, кулланучылар мәгънәсен дөрес аңласын өчен, автор сүзлектә урын алган дини тематикадагы сүзләрнең һәрберсенә аңлатмалар китерә. Мисал өчен:

**Мигра́дж** *м. рел.* (*праздник в ознаменование чудесного ночного путешествия пророка Мухаммеда из Мекки в Иерусалим и его вознесения на седьмое небо к престолу Аллаха*) Мигъраҗ, Мигъраҗ кичәсе; ~ *произошло́ 27 раджа́ба 621 го́да* Мигъраҗ 621 нче елда рәҗәб аеның 27 сендә була;

**гушр** *м. рел.* (*вид приношения в исламе, составляющий одну десятую часть собранного урожая*) гошер (сәдакасы); *вы́делить (отда́ть)* ~ гошер сәдакасы бүлеп бирергә (тапшырырга);

**Тахаджу́д** *м. рел.* (*ночной дополнительный намаз, к-рый совершается индивидуально*) тәһәҗҗуд; *соверши́ть* ~ тәһәҗҗуд укырга.

Дини лексиканың кайберләре (*Аллах, медресе, мечеть, хадж, хаджи, харам, халяль, фетва*) рус теленең аңлатмалы һәм орфографик сүзлекләрендә теркәлгән булса, *фитр, гаит, гушр, тахаджуд, машаллах, ас-саляму алейкум, астагфируллах* һ. б. сүзләрне әле лексикографик чыганакларда урын алган дип булмый. Аңлатмалы яисә «Татарча-русча сүзлек»ләрдә татарчасы бирелгән очракта да, рус теленә тәрҗемәләре китерелми иде. Димәк, дини тематикадагы күпчелек сүзләр «Русча-татарча сүзлек»тә беренче тапкыр урын ала. Билгеле, бу – бик зур җаваплылык.

Дин белән бәйле сүзләрнең аерым вокабула итеп бирелмичә, башка сүзлек мәкаләсенә кертелгәннәре дә бар. Мәсәлән, *ночь* сүзе мәкаләсендә *ночь аль-кадр* (Кадер кичәсе), *ночь бараат* (Бәраәт кичәсе), *ночь рагаиб* (Рәгаиб кичәсе), *день* сүзеннән соң *день Арафа* (Гарәфә көне), *день Ашура* (Гашүрә көне) һ. б. турында мәгълүмат табарга була. Шул ук вакытта, ислам диненә кагылышлы бик күп лексик материал бирелсә дә, сүзлеккә *ислам* сүзе үзе кертелмәгән (чагыштыру өчен: *христианство* сүзе бар).

Моңа кадәр төзелгән кайбер тәрҗемәле сүзлекләрдән аермалы буларак, әлеге чыганакта сүзләргә шактый киң иллюстратив материал бирелә. Сүзләрнең контекстта кулланылу үрнәге буларак китерелгән мәгълүмат телне өйрәнгәндә ярдәм итә дип уйланыла. Шул ук вакытта, гади сүзләргә дә мисаллар күп. *Абитуриент, гитара, гимн, герб, кафе* һ. б. сүзләргә иллюстратив материал кирәк тә түгел кебек.

Мисаллардан соң ромб билгесе белән фразеологик әйтелмәләр, мәкаль-әйтемнәр, тотрыклы сүзтезмәләр урын алган. Алар төрле очракларда төрлечә тәрҗемә ителә: тулысынча туры килә торган эквиваленты белән; шуңа якын мәгънәдәге вариант белән; мәгънәсен тәрҗемә итеп аңлату рәвешендә һ. б.

Ромб белән билгеләнгән өлешнең укучылар, гади кулланучылар өчен эшләнүе күренә. Анда *в самом деле* чыннан да, чынлап та, *принять к сведению* исәпкә алырга, *без лишних слов* күп сөйләп тормыйча һ. б. көндәлек кулланылыштагы сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр китерелә. Төп сүз белән сүзтезмә бирелгән очраклар да бар. *Лицо* мәкаләсендә ромбтан соң *физическое лицо* – физик зат, *юридическое лицо* – юридик зат, *водный* сүзендә *водные лыжи* һ. б. шундыйлардан.

Йомгаклап әйткәндә, Ф. Гаффарова төзегән «Русча-татарча сүзлек»: 1) укучылар, студентлар һәм татар телен өйрәнүче киң кулланучылар өчен кирәкле төп сүзләрне үз эченә ала; 2) сүзләрнең тәрҗемәләрен генә биреп калмый, телне камил белмәүчеләр өчен аларның кыскача аңлатмаларын да китерә; 3) дини лексикага зур урын бирә, бу исә кулланучыларга, бигрәк тә яшьләргә, дини төшенчәләрне дөрес аңларга ярдәм итә; 4) телне өйрәнүчеләрне күздә тотып, сүзләрнең кулланылыш үрнәкләрен тәкъдим итә һ. б. Шул рәвешле, яңа «Русча-татарча сүзлек» бүгенге кулланучылар өчен актуаль лексик материалны үз эченә алган заманча лексикографик чыганак булып тора.

Дистәләгән сүзлек, шул исәптән русча-татарча, аңлатмалы, терминологик сүзлекләр авторы булган тәҗрибәле сүзлекченең әлеге хезмәте дә меңләгән кулланучыларның өстәл китабына әйләнер.

**Әдәбият**

*Гаффарова Ф.Ф.* Русско-татарский словарь. Русча-татарча сүзлек / под ред. О.Н. Галимовой. Казань: Милләт, 2025. 655 с.

***Сафина Эльвира Ирфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Сафина Эльвира Ирфатовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела лексикографии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*7idillia@mail.ru*

**2025 елның 25–27 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл» V Халыкара фәнни-гамәли семинары үтте. Семинар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылды. Чарада Казан, Мәскәү, Алабуга, Уфа, Екатеринбург, Чабаксар, Йошкар-Ола, Саранск, Ижевск һ. б. шәһәрләрдән, шулай ук чит илләрдән (Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан) эйдәп баручы белгечләр катнашты.

**2025 елның 30 сентябреннән 1 октябренә** кадәр Белоруссия дәүләт технология университетында үткән «БПЛА-2025» Халыкара форумында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов та катнашты. Чара кысаларында академия һәм университет арасында югары технологияләр өлкәсендә хезмәттәшлек турындагы килешү төзелде.

**2025 елның 2–3 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Функциональ өслекләр төшерү процессында түбән температуралы плазма» дип аталган XVII Халыкара фәнни-техник конференция узды. Конференция кысаларында яшьләр гыйльми мәктәбе эшләде, анда түбән температуралы плазма куллану буенча лекцияләр укылды.

**2025 елның 2–3 октябрендә** Казанда «Инженерлык фәннәрендә заманча алымнар һәм гамәли инициативалар» темасына Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Анда Россия, Кытай, Азәрбайҗан һәм Германия инженерлары һәм белгечләре катнашты һәм фикер алышты. Беренче көнне катнашучылар Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гамәли тикшеренүләр институты лабораторияләрендә булдылар, хезмәткәрләрнең актуаль һәм перспектив проектлары белән таныштылар.

**2025 елның 10–24 октябрендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы И.А. Бодуэн де Куртенэның тууына 180 ел тулуга багышланган VI Казан халыкара лингвистик саммиты үткәрелде.

Аның кысаларында «Российский словесник» Бөтенроссия эсселар конкурсы, «ЛингвоЭкспо: чит телләр – 2025» фестивале, «Тел трендлары һәм методик инновацияләр – 2025» лингвометодик фестивале, «Хәзерге заман тел гыйлеменең чакырулары һәм трендлары» Халыкара фәнни конференциясе, «Россия үзбилгеләнүе һәм халыкара интеграция формалаштыру чарасы буларак рус теле һәм әдәбияты» Халыкара форумы үткәрелде.

**2025 елның 15 октябрендә** Казанда «Татарстан Республикасы фәнни-мәгариф комплексы оешмалары кафедралары һәм лабораторияләре мөдирләренең республика мәктәбе» белем бирү программасы старт алды. Проект Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Казан дәүләт мәдәният институты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Проект социогуманитар юнәлештәге 500 кафедра һәм лаборатория җитәкчесен берләштерде. Алар кара-каршы сессияләр һәм дистанцион модульләрне берләштергән

72 сәгатьлек интенсив программада катнаштылар.

**2025 елның 20–22 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Лингвистика фәне үсешенең хәзерге тенденцияләре: проблематика һәм тикшеренүләр методологиясе» Халыкара фәнни симпозиумы кысаларында «Заманча фәнни тикшеренүләр яктылыгында тел белеменең актуаль проблемалары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе үтте. Чараны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырды. Конференциядә Татарстаннан, шулай ук Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән күпсанлы белгечләр катнашты.

**2025 елның 20–22 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә халыкара «Татар гыйлеме» яшьләр фәнни мәктәбе эшләде. Оештыручысы – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Анда Татарстан, Идел буе республикалары һәм Якутия фәнни оешмаларыннан студентлар, магистрлар һәм аспирантлар катнашты. Эш барышында Идел һәм Урал буе халыкларының традицион мәдәнияте хакында лекцияләр тыңланды, түгәрәк өстәл, семинарлар үткәрелде.

**2025 елның 22 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Борис Пастернакның тууына 135 ел тулуга багышланган «III Пастернак укулары» дигән Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Конференция кысаларында Пастернак тормышының һәм иҗатының Чистай чорына аерым игътибар бирелде. Чарада Кытай, Казахстан һәм Белоруссиядән әйдәп баручы белгечләр, Мәскәү, Санкт-Петербург, Татарстан, Новосибирск өлкәсе һәм Россиянең башка төбәкләреннән тикшеренүчеләр катнашты.

**2025 елның 30–31 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вәкилләре «Россия – Африка: сәясәт, икътисад, тарих һәм мәдәният» VI Халыкара фәнни форумында катнашты. Казан федераль университетында оештырылган бу чара 15 илдән 130 дан артык галимне, дипломатларны, сәясәтчеләрне һәм студентларны берләштерде, белгечләр икътисади, сәяси, тарихи һәм мәдәни өлкәләрдә Россия – Африка партнёрлыгы мәсьәләләре турында фикер алышты. Чара кысаларында шулай ук гарәп теле һәм ислам мәдәнияте буенча IX студентлар олимпиадасы, китаплар презентациясе, Катарга багышланган күргәзмә һәм RT Arabic тарафыннан төшерелгән «Return to Egypt» кыска метражлы фильмын күрсәтү үткәрелде.

**2025 елның 7 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре Пермь крае Көнгәр шәһәрендә Мулланур Вахитовның (1885–1918) тууына 140 ел тулуга багышланган «Вахитов укулары» фәнни-гамәли конференциясендә катнашты. Үз чыгышларында алар Кама буенда яшәгән татар халкының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү юнәлешләрен, шулай М. Вахитовның тарихтагы һәм халык хәтерендәге роленә кагылышлы актуаль темаларны яктырттылар.

**2025 елның 12–22 ноябрендә** Казанда «Россия – Көнчыгыш» – «Казанда Шәрык базары» Халыкара милли мәдәниятләр фестивале үтте. Фестиваль программасы үз эченә фәнни-гамәли конференцияләр, Илһам Шакиров истәлегенә багышланган гала-концерт, музыкаль

төркемнәр концертлары, гарәп мәдәнияте көне, Чечня Республикасы мәдәнияте көне һ. б. ны алды.

Быел чара ЮНЕСКО эгидасы астында узды. Анда Россиянең 20 төбәгеннән һәм дөньяның 40 иленнән вәкилләр катнашты.

**2025 елның 13–14 ноябрендә** Казанда ТР Фәннәр академиясендә «Россия – Көнчыгыш» – «Казанда Шәрык базары» Халыкара милли мәдәниятләр фестивале кысаларында «Көнчыгыш һәм Азия илләре белән мәдәни хезмәттәшлек: хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция эшендә Россиянең төрле төбәкләреннән һәм Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстан, Белоруссия, Кытай, Төркия һәм Монголиядән 200 дән артык фән вәкиле катнашты.

Тугыз тематик секциядә катнашучылар археологик фондлар, традицион костюмны өйрәнү, мәдәниятләр диалогында театр, кино һәм заманча медианың роле һ. б. мәсьәләләр буенча фикер алыштылар.

**2025 елның 21 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Меңьеллык Казан» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Чара М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан оештырылды. Конференциядә Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа һәм Россиянең башка шәһәрләреннән әйдәп баручы тарихчылар, археологлар, культурологлар һәм энциклопедистлар катнашты.

Катнашучыларны һәм кунакларны Татарстан Фәннәр академиясе президенты Р.Н. Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин, Россия Федерациясенең 1 нче класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе, «КНПО ВТИ» АҖ генераль директоры К.Ш. Исхаков, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Г.Р. Сәгыйтова сәламләде.

**2025 елның 27–28 ноябрендә** Мәскәүдә Россия Федерациясе халыкларының туган телләре укытучыларының Бөтенроссия съезды булды. Чара Россия Мәгариф министрлыгы ярдәмендә Туган телләр федераль институты тарафыннан оештырылды һәм Мәскәү дәүләт педагогика университеты базасында узды. Съездда укытучылар, тикшеренүчеләр, методистлар, хакимият органнары һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашты.

Съезд көннәрендә Россия халыкларының туган телләре өлкәсендә фәнни-мәгариф инициативаларын үстерүнең яңа этабын ачучы хезмәттәшлек турында өч килешү имзаланды. Әлеге килешүләр федераль туган телләр институтының Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Ставрополь дәүләт педагогика институты һәм Чечен дәүләт педагогика университеты белән озак сроклы партнёрлыгын ныгыта.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән килешү туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендәге тикшеренүләрне киңәйтү өчен фәнни, мәгариф һәм инновацион потенциалны берләштерүгә юнәлдерелгән. Яклар бергәләп фәнни-методик проектлар эшләү, публикацияләр әзерләү, белем бирү программаларын гамәлгә ашыру, күргәзмә һәм конгресс-фәнни чаралар уздыру, шулай ук актуаль фәнни мәгълүматларны даими алмашу турында килештеләр.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2025. № 4

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 10.12.2025. Басылды: 15.12.2025.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 100 данә. Заказ

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият һәм типография адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал Татарстан, Башкортстан Республикаларында, Самара, Ульяновск,
Оренбург, Әстерхан, Төмән өлкәләрендә бушлай таратыла

## О.Л. Улемнованың «Рәссам Р.Г. Заһидуллин иҗатында татар халкы тарихы һәм мәдәнияте» мәкаләсенә



Заһидуллин Р.Г. Иртә белән Болгарда. 2022. «Болгар илендә» сериясеннән. Киндер, майлы буяу. 45×30 см. *Автор милке*



Заһидуллин Р.Г. Казанда кышкы базар. 2015. «Безнең авыл» сериясеннән. Киндер, майлы буяу. 71×121 см. *Автор милке*



Заһидуллин Р.Г. Тиздән Сабантуй бәйрәме. 2016. «Безнең авыл» сериясеннән. Киндер, майлы буяу. 58×70 см. *Автор милке*

## Р.А. Гулиевның «Борынгы Азәрбайҗан скульптурасында хатын-кыз символизмы» мәкаләсенә



Терракотадан хатын-кыз статуэткасы. Азәрбайҗан, Молла-Исаглы, Исмаилла, I гасыр



Антропоморф фигура фрагменты. Кыпчак шәһәрлегеннән керамик материал



Терракотадан фигурка. Азәрбайҗан, Мингячевир, I–II гасырлар



Терракотадан хатын-кыз статуэткасы. Тепе-Сараб, Көньяк Азәрбайҗан, неолит



Балчыктан ритуаль фигуркалар, күмү һәм авыл җирлеге инвентаре һәм Ананьино мәдәни-тарихи өлкәсе Постмаклашеевка культурасының өченче чорына караган очраклы табылдыклар



ТР Актаныш районы Татар Суыксуы авылында разведка шурфында табылган фигурка



Кулларына бала тоткан стильләштерелгән хатын-кыз сурәтле терракотадан ясалган уңдырышлылык фигуркасы. Тимер гасыры, Идел буе Городец культурасы

А.Н. Хәсәнованың «Сәлах Камалның тормышы һәм эшчәнлеге (тууына 140 ел тулу уңаеннан)» мәкаләсенә



Сәлах Камал шәкертләре белән

Л.Р. Мортазинаның «Педагог һәм шәркыятчы галим Әбүбәкер Диваев» мәкаләсенә



Әбүбәкер Диваев сурәте төшерелгән открытка

И.С. Насиповның «Алмас Галимҗан улы Шәйхулов – чагыштырма-тарихи тел белеменең күренекле вәкиле (галимнең тууына 80 ел тулу уңаеннан)» мәкаләсенә



## Яңа китап



## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗГА ФОТОКҮЗӘТҮ



«Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл»
V Халыкара фәнни-гамәли семинары кысасында түгәрәк өстәл утырышы. ТР ФА. 2025 ел, 25 сентябрь




«Лингвистика фәне үсешенең хәзерге тенденцияләре: проблематика һәм тикшеренүләр методологиясе»
Халыкара фәнни симпозиумында катнашучылар. ТР ФА. 2025 ел, 20 октябрь




«Көнчыгыш һәм Азия илләре белән мәдәни хезмәттәшлек: хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары»
II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе. ТР ФА. 2025 ел, 13 ноябрь




Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Меңьеллык Казан» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе.
ТР ФА. 2025 ел, 21 ноябрь



Институт директоры И.И. Халиков Россия Федерациясе халыкларының туган телләре укытучыларының Бөтенроссия съездында.
Мәскәү. 2025 ел, 28 ноябрь

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре «Вахитов укулары» фәнни-гамәли конференциясендә.
Пермь крае, Көнгәр шәһәре.
2025 ел, 7 ноябрь

